www.madanizhomga.ru

Мәдәни җомга

1995 елның июленнән башлап чыга

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 1 (1417) 13 гыйнвар 2023 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga
madanizhomga
madani_zhomga



8

Тарихчы Таһир Кәримов тикшеренүләре Азнакай төбәгенең үткәнен барлап, башкорт галимнәренең хаксызлыгын күрергә юл ача.

12

Рәссам Миләүшә Нуруллина сурәтләгән чәчәк-гөлләрдә буяу төсмерләре аша бирелгән сихри серлелекне тоймый мөмкин түгел.

24

Бөек Тукай әсәрләренә нигезләнеп куелган яңа спектакль шагыйрь иҗатының һәр чорда да кызыклы, мәгънәле яңгырашын раслады.

Күкрәгемнән тулып, ташып чыккан Йөрәк җырым калды сызылып...

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллинның төрле елларда иҗат ителгән публицистик язмаларыннан гыйбарәт «Элгәреләр, бүгенгеләр...» исемле яңа китабы дөнья күрде.
- Милли китапханәдә Нижгар яклрыннан Финляндиягә күченгән татарлар турындагы «Туңган як: Суоми» документаль фильмы күрсәтелде.
- Кукмараның Комсомол мәйданында «Итек фест» киез итекләр фестивале булды.
- Омск өлкәсендәге шифаханә-профилакторийда балалар һәм яшьләр өчен «ТАТСАМР» IV Төбәкара этномәдәни тел лагере узды.
- Әфганстан, Пакьстан һәм Иран татар җәмгыятьләре Бердәм татарлар советын оештырырга планлаштыра.
- Питрәчтә Казанның танылган рәссамы, халык сәнгать һөнәрчелеге техникумы укытучысы Резеда Йосыпованың күргәзмәсе узды.
- «Идел-Урал тикшеренүләре» төрек фәнни журналының 2022 елгы соңгы саны күренекле галим Надир Дәүләт истәлегенә багышланды.
- Башкортстан Башлыгы Радий Хәбиров Мәдәният һәм сәнгатьне үстерү советының беренче утырышында республикада башкорт, рус һәм татар драма театрларына, яңа зур спектакльләр әзерләү өчен, ел саен унар миллион сум бүлеп бирелләчәген хәбәр итте.
- Төркиядә Евразия Язучылар берлегенең «Бәнгү» китап нәшрияты Галимҗан Ибраһимовның сайланма әсәрләрен төрекчә чыгарды.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Рөстәм МИҢНЕХАНОВ, Татарстан Президенты:

«Хәзер Казанда Җәмигъ мәчете проектын сайлау процессы бара. Ике вариант бар – заманчарак һәм классик. Якын арада барлык кирәкле карарлар кабул ителәчәк. Җәмигъ мәчете өчен яңа мәйданчык сайладык, ләкин анда әле яңгыр сулары белән бәйле инженер эшләрен уздыру кирәк. Бу эшне башладык инде. Проектка килгәндә, без ике вариант арасыннан сайлыйбыз. Бу эштә ялгышырга ярамый. Сайлау җиңел түгел».

СЫНАМЫШЛАР

Искечә 1 гыйнварда (хәзер 14 гыйнвар) көн җылы булса – арыш уңар; җил дуласа – тары уңар; томан төшсә – солы уңар ● Ел башында җилле булса, ел буена җил-давыл тынмас ● Гыйнвар салкын булса, июль коры һәм эссе була ● Гыйнвар җылы килсә, март салкын була.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **8 сәгать 07 минутта** чыкты, һәм ул **15 сәгать 38 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **7 сәгать 31 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **21 минутка озынаячак** һәм киләсе җомгада, ягъни **20 гыйнварда 7 сәгать 52 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

13 гыйнвар – драматург, шагыйрь, публицист Фәтхелислам Закир улы Бурнашевның (Фәтхи Бурнаш) тууына 125 ел (1898–1942);

– шагыйрә, драматург, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Гөлшат Хисам кызы Зәйнашеваның тууына 95 ел (1928–2005).

15 гыйнвар – җырчы, Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Әлфия Авзал кызы Авзалованың тууына 90 ел (1933–2017);

– җырчы, Татарстанның халык артисты Нәфисә Василованың (Анастасия Петровна Васильева) тууына 80 ел (1943–2006).

16 гыйнвар – балалар язучысы, шагыйрь, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Хәкимҗан Шәяхмәт улы Халиковның тууына 90 ел (1933–2002).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Гыйнварның магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көннәрне исегезгә төшерәбез: 16, 17 гыйнвар.**

* * *

Гадәттә, айның соңгы чирегеннән яңа айга кадәр **(15-21 гыйнвар)** организм киңәюгә бара. Мондый көннәрдә юан эчәклекне чистартуга бәйле процедуралар үткәрү файдалы.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1444 ЕЛ

Бүген җөмәдел ахир аеның 21 нче көне

ҖАН АВАЗЫ

Әгъзам ФӘЙЗРАХМАНОВ

ҖӘМГЫЯТЬ ЧИРЕ



Коррупция бүгенге тормышыбызга нык үтеп керде. Җитәкчеләрнең һәр чыгышларында диярлек коррупция телгә алына, җәмгыять үсешенә ул китергән зыянга басым ясала. Әмма коррупциянең моңа әллә ни исе китми, тамырларын һаман да тирәнгәрәк җибәрә. Татарстанда тугыз айда коррупция юнәлешендәге 993 җинаять эше ачылган. Алар күбрәк вазыйфаи затлар эшчәнлеге белән бәйле. Китерелгән зыян 323 миллион сумны тәшкил итә. Күчемсез милек белән эш итү, сәламәтлек саклау, социаль яклау, мәгариф өлкәләренә коррупция аеруча киң үтеп кергән. Бу тармаклар бүген дәүләт тарафыннан яхшы финанслана. Шуңа да карамастан халык бу оешмаларга һаман да «күчтәнәч» кыстырып бара.

Коррупциянең тамырлары тирәндә. Россия тарихында ришвәт, бүләк бирү төшенчәләре XIII гасырга кагылышлы материалларда да очрый. Коррупциягә каршы беренче законнар Иван III (1462-1505) тарафыннан чыгарыла. Аның оныгы Иван Грозный зур күләмдәге ришвәт өчен Россиядә беренче булараk үлем җәзасы кертә. XVII гасырда акча кытлыгын сәбәп итеп, хөкүмәт чиновникларының хезмәт хакы нык киметелгән. Җитмәсә ул вакытында да түләнмәгән. Билгеле инде, мондый «тәртип» ришвәтчелекнең киң таралуына китергән.

Петр I җитәкчелек иткән чорда дәүләт хезмәте системасында коррупцияне кисәтү буенча шактый уңышка ирешелә. 1699 елда ул «Бурмистрлар палатасы оештыру турында», «Шәһәрләрдә җир йортлары булдыру турында» указлар чыгара. Бу указлар нигезендә шәһәрләр гаскәр башлыгы (воевода) карамагына күчерелә һәм үзләренең оешмаларын сайларга тиеш була. Чыгымнарны каплау өчен, салымнар бермә-бер арттырыла. Гражданлык хезмәткәрләренең яңа уставлары, норматив хокукый документлар кабул ителә. Аларның барысы да дәүләт хезмәткәрләрендә югары әхлак нормалары тәрбияләүне максат итеп куя. 1714 елда Петр I «Ришвәтне тыю турында» указ чыгара. Контролерлар гына түгел, чиновниклар эшчәнлеге, кимчелекләр хакында теләсә кем патшага җиткерергә хокуклы була. Моның өчен бүләк карала.

Екатерина II патшалык иткәндә, барлык дәүләт хезмәткәрләренең эш хакыннан тыш барлык керемнәре ришвәт булып исәпләнгән. Шулай да коррупция бетмәгән, чөнки коррупция белән көрәшергә тиешле чиновниклар үзләре дә еш кына ришвәт алган. Россиядә капитализм чорында коррупция тагын да ныграк чәчәк ата. Эшкуарлар акционерлык җәмгыятьләрен оештыра, шәхси фирмалар белән идарә итүче байлар да күп була.

Хакимияткә большевиклар килгәч, ил белән идарә итү системасында зур үзгәрешләр була. Әмма ул коррупцияне читләтеп уза. Бизнес закон нигезендә тыелса да, чиновниклар бик уңайлы юл уйлап таба: теге яки бу мәсьәләне хәл итү нык сузыла. Эшне тизләтү өчен ришвәт бирергә туры килә.

Сталин чорында җитәкчеләрнең сүзе эштән нык аерыла. Бөтен халык мәнфәгатьләрен кайгыртабыз дип сөйләсәләр дә, большевиклар илнең икътисади һәм сәяси тормышын тулысынча үзләренә буйсындыра. Контроль булмагач, дефицит продукция җибәрү, җиһазлар һәм материаллар бирү, план күләмен киметү, җаваплы урыннарга утырту өчен эреле-ваклы җитәкчеләр зур күләмнәрдә ришвәт ала.

Дөнья тәҗрибәсеннән чыгып, ил җитәкчеләре коррупцияне тулысынча бетереп булмый, аны бары тик мөмкин кадәр кимәтә төшәргә кирәк, дигән карашта тора. Әлбәттә, көрәшне законнарга таянып алып бару мөһим. Бүгенге көндә законнар аз түгел, 2006 елда «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәш турында» махсус закон кабул ителде. Бераз алдарак, 2005 елның 5 апрелендә президентның «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәт стратегиясе турында» Указы да дөнья күргән иде. «Коррупциягә каршы көрәш турында» федераль законы да бар.

Шулай да гамәлдәге законнарның камил булмавы үзләрен нык сиздерә. Бу хакта чыгышларында Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин да даими искәртеп килә. Әйтик, Җинаять кодексында бер үк җинаять өчен төрле күләмдәге җәза каралган. Судлар берәүгә биш елга, ә икенчеләрне ун елга төрмәгә җибәрә ала. Нәтиҗәдә законны бозмыйча ришвәт алуга һәм бирүгә урын кала. Шундый ук җитешсезлекләр Гражданлык һәм Административ хокук бозулар турындагы кодекслар да бар. Хокук саклау, бюджет, банк эшчәнлеге, милекне хосусыйлаштыру, теге яки бу эшчәнлек өчен лицензия бирүгә багышланган хокук актларында да кимчелекләр җитәрлек.

«Борын-борыннан килә торган бу яман чир патша Россиясендә, аннары СССРда һәм бүгенге Россия Федерациясендә гадәттән тыш көчле тамырлар җибәреп, асылда бик күп җинаятьләрне каплауга һәм йомып калдыруга хезмәт итә торган бер криминаль факторга әйләнде», – дип язды күренекле публицист Адлер Тимергалин. XIX гасыр урталарында Казан университетында укыткан профессор Д.И.Мейер ришвәтчелекне рус тормышына хурлык тамгасы сала торган яман шеш дип саный. Аның бу сүзләре бүген тагын да актуальрәк яңгырый. Чөнки ришвәтчелеккә каршы көрәшергә тиешле органнарда һәм оешмаларда эшләүче чын мәгънәсендә мошенниклар үзләре үк ришвәт хисабына типтереп яши һәм авыру җәмгыятьчелек каршында эш майтарган намус ияләре булып кылана гына.

Берничә ел элек Татфондбанк тирәсендә дә җәнҗал купты. Арбитраж суды банкны банкрот дип игълан итте. Банк идарәсе рәисе Роберт Мусинга карата җинаять эш кузгатылды. Тикшерүчеләр дәүләткә һәм клиентларга ул китергән зыян 24,6 миллиард сум дип исәпли. Кулга алынганчы Р.Мусин Татарстан Дәүләт Советы депутаты иде. Декларациясеннән күренгәнчә, аның еллык хезмәт хакы 31,1 миллион сум булган. Димәк, аена 2,5 миллион сумнан артыграк. Мондый акчалар көне-төне станок артына басып заводта деталь кыручының төшенә дә кермәс.

Мусинның декларациясендә алты җир кишәрлеге булуы, аларның берсенең 20 гектар икәнлеге (башкаларының мәйданы күрсәтелмәгән), фатирының – 520, бакча йортының – 315, машина кую урынының 39 квадрат метр булуы, мотокөймәсе, прицепы булуы күрсәтелә.

Депутатларның декларацияләре белән танышканда берәүнең еллык хезмәт хакы 163,5 миллион сум икәнен күргәч, чәчләр үрә торды. Торак йортының 894 квадрат метр, 52дән 539 квадрат метрга кадәрле торак булмаган алты бинасы булуы да күрсәтелгән иде генераль директор депутатның. Мөнә шуларныкына безнекен дә кушып исәпләгәч, республикада уртача хезмәт хакының 50-60 мең сумга җитүенә гаҗәпләнәсе дә юк.

Матбугатта Татарстанның элеккеге транспорт министрының да, башка түрәләрнең дә коррупциядә гаепләнүе турында хәбәрләр чагылды. Әмма гадәттә ришвәтнең кемнән алынуы да, күләме дә күрсәтелмәгән иде.

Ноябрь ахырында НТВ каналы «Яңалыклар» программасында ел дәвамында республика буенча 2,5 меңнән артык коррупция очрагы теркәлүе хәбәр ителде. Яңа Чишмә, Алексеевский районнарында хәл бигрәк тә катлаулы икән.

Ришвәтчелеккә каршы көрәшне көчәйтү зарур. Шунысы көн кебек ачык: ришвәтчелеккә каршы көрәштә шөрепләрне әкрен-әкрен борып тыгызлау, ягъни эволюцион юл тиешле нәтиҗәне бирмәячәк, революцион чаралар кирәк.

МӘҖ Җидегән вакыйгалар хәбәрләр яңалыклар

Хокук нормалары белән санлашмау

Татар һәм Татарстан халкы яңа елга шөбһәле вә тәшвишле кичерешләр белән керде. Борчулы күңел халәте исә бүген ил-көндә бара торган хәтәр вакыйгалар белән генә түгел, ә иң элек Татарстанның Төп Законына кизәнү, анда 1992 елның 21 мартында республиканың хокукый вә сәяси статусы буенча халыкара нормаларга туры китереп үткәрелгән референдум нәтиҗәләре нигезендә салынган юридик нормаларны юкка чыгару буенча башланган сәяси максатлы һөҗүм белән дә билгеләнә. Сүз, асылда, милли берәмлекләрнең төп законнарында беркетелгән хокукый нормаларны «РФ субъектларында гаммәви хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» дигән федераль законның яңа редакциясенә тәңгәлләштереп үзгәртү турында бара. Мәгълүм булганча, хакимият органнары, гадәттә, түбәннән югарыга корыла. Илаһият кануннары буенча да бу шулай. Чөнки беренчел хокуклар (әйтик, яшәүгә, ирекле үсешкә хокук һ.б.) Хак Тәгалә тарафыннан кешеләргә тигез дәрәҗәдә бирелә. Ә алар, яшәү ихтыяҗларыннан чыгып, кабилаләргә, аерым халыкларга һәм дәүләтләргә дә берләшә.

Россиядә исә, дөньяда аналогы булмаган ил буларак (чөнки геосәяси яктан ул дөнья тотучыларның «сәясәт коралы» һәм Кытай белән Көнбатыш арасында буфер дәүләт буларак формалаштырыла), һәммәсе дә нәкъ киресенчә эшләнә. Бу җәһәттән, табигый сораулар туа: төп халыклар беренчелме, әллә алар корган дәүләтме? Россиядә сайлау системасы, асылда, имитациягә корылуын исәпкә алганда, күбрәк тыюларга корылган законнар кабул итә торган парламентның легитимлык дәрәҗәсе нинди? Ул илдә яшәүче төп халыкларның ихтыярын вә ихтыяҗын чагылдырамы? Ни өчен илдәге төп халыкларның язмышы, аларның ихтыярын чагылдырмаган, әмма парламентта һәр чакырылыш саен «законнар» әвәләп утыра торган затлар карамагына тапшырыла? Мәгәр, сорауның геосәяси әһәмияткә ия булганы да бар. Зур сәясәттә Көнбатыш һәм Россиянең, капма-каршы яктан, әмма уртак максатларда (дөнья тотучыларга кирәкле яңа дөньяви тәртип урнаштыру) эш итүе инде күпләр өчен сер түгел. Россиядә милли берәмлекләрне бетереп, Көнбатыш үрнәгендәге агломерацияләр кору планы – шуның әчке сәясәттәге бер чагылышы. Тик, бүгенге хәтәр вакыйгалар фонында милли хокукларга синхрон рәвештә оештырылган бу һөҗүм илдә әчке вәзгыятьне дә какшатуга юнәлдерелгән адым була түгелме соң?

Инде Татарстандагы хәлләргә дә бераз тукталып үтик. Мәгълүм булганча, узган ел ахырында Дәүләт Советы анда, Мәскәү таләпләренә туры китереп, суверенитетның соңгы атрибутлары – ТР Конституциясудын һәм «президент» атамасын бетерде. Бүгенге президент исә, 2025 елда вазыйфасы чыкканчыга кадәр, үз атамасында калачак. Ә аннан соң сайланган республика җитәкчесе инде «глава – рәис» дип аталачак. Югарыда телгә алынган федераль законга туры китереп, ТР Конституциясенә тиздән башка төзәтмәләр дә кертелә. Нәтиҗәдә, анда 22 норма үзенең юридик көчен югалтачак. Әйтик, Татарстан рәисе булып сайлану өчен татар телен белү инде мәҗбүри булмаячак. Россия президентының ышанычын акламаган очракта, Татарстан рәисен ул вазыйфасыннан да мәхрүм итә алачак. Формаль яктан сакланган ТР гражданлыгы турындагы норма да юридик көчен югалтачак. «Суверенитет» төшенчәсе бары 1 нче маддәдә генә кала. Чөнки бу маддәне үзгәртү өчен яңа референдум үткәрү кирәк. Ә анда: «Татарстан Республикасы суверенитеты, Россия Федерациясе карамагындагы мәсьәләләрдән һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча Россия Федерациясе вәкаләтләреннән тыш, дәүләт хакимиятенең (закон чыгару, башкарма һәм суд) бөтен тулылыгына ия булуда чагыла һәм Татарстан Республикасының аерылгысыз хасияте була», – диелә. Ә бүген инде Россиянең үз язмышы сораулар тудыруын да онытмыйк.

Игътибарны Татарстанның бүген үз Конституциясен 1992 елның 21 мартында үткән референдум нәтиҗәләренә таянып яклый алмавы да җәлеп итә. Чөнки, беренчедән, аның Конституция суды инде бетерелгән. Икенчедән, хокукый нигездә аны яклау республиканың бүгенге хокуксыз хәле өчен кемнәрнеңдер җавап тотарга тиешлеген дә искәртер иде. Ә алар моңа әзер түгел. Кызганычка, илдәге хәлләр бүген бар яктан да катлаулана гына бара һәм, хокукый чишелеш табылып, дөрес карарлар вакытында кабул ителмәсә, эшләр ватандашлар конфликтына кадәр дә барып җитәргә мөмкин. Ә бу инде барлык халыклар өчен дә зур фаҗига булыр иде. Мондый вәзгыятьтә бүген зур җаваплылык, илдәге башка халыклар белән бергә, илаһи миссияле татар халкына да йөкләнә. Ә ул – Урталык җирләрендә тотрыклылык вә рухи яңарыш факторы булу. Бу исә аннан, үз миссиясен метасәяси (илаһи яшәешкә кучүне максат иткән) югарылыкта аңлап һәм зур оешканлык вә тырышлык күрсәтеп башкаруны таләп итә.

Фоат УРАЗАЙ.

Өченче «Илһам чишмәсе»

Узган ел декабрь аеның соңгы көннәрендә «Илһам чишмәсе» республикакүләм җыр бәйгесе игълан ителде. Бөтендөнья татар конгрессы матбугат хезмәте хәбәренчә, конкурс РСФСРның һәм Татарстанның халык артисты, Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе Илһам ага Шакировның иҗатын хөрмәтләү ниятеннән үткәрелә һәм легендар җырчының иҗатын яшьләргә таныту, аның исемен мәңгеләштерү, яшь буынны бөек шәхесебезнең җыр сәнгатенә булган мөнәсәбәте нигезендә тәрбияләүне максат итә.

Җыр иҗатына сәләте булган яшьләрне барлау, таныту һәм үстерүне дә бурыч итеп куйган республикакүләм бәйге беренче тапкыр игълан ителә. Җыр конкурсы «Ялгыз вокал» номинациясендә узачак. Бәйгедә катнашучылар иҗатына бәя биргәндә, алар 6-9 яшь, 10-12, 13-16, 17-21 яшькә кадәр төркемнәргә һәм категорияләргә бүлеп караладак.

Шуңа да мәктәпләрдә, балалар бакчаларында, көллиятләрдә Илһам ага башкарган җырларны өйрәнүгә аеруча әһәмият бирү сорала. Катнашучылар татар телендә 2 җыр башкарыр, дип уйланыла. Аның берсе – И. Шакиров репертуарыннан татар халык җыры. Икенчесе – халкыбыз композиторлары иҗат иткән җыр (И.Шакиров репертуарыннан).

Бәйге ике этапта уздырыла һәм гала-концерт белән тәгәлләнә. Беренче сайлап алу турында жюри әгъзалары онлайн режимда эшли, ягъни бәйгедә катнашучылар чыгышын видеодан карап бәяләячәк. Икенче этапка узучылар исемлеге конкурсны оештыру комитетының социаль челтәрләрдәге рәсми сәхифәләрендә урнаштырылачак.

2 нче этап 2023 нче елның февраль аенда Сарман районы җирлегендә оештырыла. Финалны үткәрү вакыты һәм урыны бәйгенең оештыру комитетының социаль челтәрләрдәге рәсми сәхифәләрендә һәм Бөтендөнья татар конгрессының рәсми сайтында (www.tatar-congress.org) күрсәтеләчәк.

Бәйгедә катнашу бушлай. Гаризалар һәм конкурс материаллары 2023 елның 25 гыйнварына кадәр ilham1935@mail.ru электрон почта адресы буенча кабул ителә.

Сөембикә КАШАПОВА.

Чыршыларда милли бизәкләр

Милли мирасны, халык сәнгате һөнәрчелеген популярлаштыруга һәм аларны заманча интерьерга, шәһәр мохитенә яраклаштыруга юнәлдерелгән «Россия чыршылары» дип аталган яңа федераль проект 2022 елда илебез күләмендә игълан ителгән иде.

2022 елның ноябрендә Красноярскида ачылган «Россиянең Креативлык атнасы – Себер» чарасында өч меңнән артык дизайнер, кино сәнгате эшлеклеләре, архитекторлар, фотографлар да катнашты. Һәм Себер федераль университетының Конгресс-холлына бәйрәмчә бизәлгән берничә дистә чыршы урнаштырылды. Алар Мәскәү дизайнеры, һөнәри флористика буенча Россия һәм Европа чемпионы, дөнья вице-чемпионы Наталья Жижко җитәкчелегендә бизәлде. Конгресс-холлдагы «Татарстан чыршысы» да башка чыршылардан ким бизәлмәгән иде. Халык аңа эленгән күн мозаикалы алтын чигешле эшләнмәләргә, каюлы кечкенә күн сумкаларга, тамбур чигешләренә, милли орнаментлы мендәрләргә һ.б. үз соклануын белдерде. Чарада күн мозаикасы буенча осталык дәресләре үтте. Милли моң яратучылар курайда, гармунда башкарылган татар көйләрен ишетеп тәэсирләнде.

«Татарстан көйләре» дип аталган чыршы Мәскәүнең Горький исемендәге мәдәният һәм ял үзәк паркы павильонына куелды. Аңа да традицион чыршы уенчыкларыннан кала күн һәм текстиль мендәрләр, сумкалар, татар түбәтәйләре эленгән. Мәскәүлеләр өчен татар гамәли сәнгате буенча осталык дәресләре дә оештырылды.

16 декабрьдән алып Санкт-Петербург каласындагы Мария театры тамашаларына килүчеләр дүрт бәйрәм чыршысын күреп сокланды. «Татарстан чыршысы» исә бу мәшһүр театрның Рахманинов залы фойесын бизәде.

Казан дәүләт мәдәният институты, аның инжиниринг үзәге әлеге проектка иң беренчеләрдән булып кушылды. Аларның нәтиҗәле эше 27 декабрьдә, М.Җәлил театрында «Россия чыршылары» кысасындагы «Татарстан чыршылары» проектын тәкъдим итү тантанасында тагы бер кат расланды. Институт студентлары, укытучылары, Татарстан осталары белән берлектә 2022 елда җиде чыршы бизәде.

Үзенчәлекле проект чыршылары Казандагы берничә мәйданда урнаштырылды: Татарстан Министрлар Кабинетында, М.Җәлил театрында, К.Тинчурин театрында һәм Милли китапханәдә.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

Олуг дирижерны яд иттеләр

Мәскәүдә Татарстанның Россиядәге тулы вәкаләтле вәкиллек хезмәткәрләре ТАССР-ның, Россиянең халык артисты, дирижер, педагог Фуат Мансуровның каберенә чәчәкләр салды. 10 гыйнвар көнне бөек музыкантка 95 яшь тулган булыр иде.

Әлеге чарада Татарстан Премьер-министры урынбасары – Республиканың Россиядәге тулы вәкаләтле вәкиле Равил Әхмәтшин дә катнашты.

Дирижерга кабер ташы 2014 елда Татарстанның тулы вәкаләтле вәкиллеге инициативасы һәм ярдәме белән куелды. Проектның авторы – Казан скульпторы Фәнил Вәлиуллин.

1 нче биттә – Татарстанның халык шагыйре Илдар Юзеев. Зөфәр Гыймаев эше.

Җанисәптән тәүге нәтиҗәләр

Росстат җанисәп нәтиҗәләрен игълан итте. Саннардан күренгәнчә, Россиядә татарлар 596 980 кешегә кимегән. 2010 елгы җанисәптә 5310649 кеше милләтен татар дип күрсәткән булса, 2020 елгы җанисәптә (пандемия сәбәпле 2021 елда үткәрелде) – 4713669.

«Мишәр» дип күрсәтүчеләр саны бергә арткан. 2010 елда 786 булса, 2020 елда – 787 кеше.

Милләтен «Себер татарлары» дип күрсәтүчеләр кимегән – 2010 елда 6779 булса, 2020 елда – 6297 кеше.

«Әстерхан татарлары» өч тапкырга артса да, абсолют саннарда бу күп түгел – 7 (2010 елда) һәм 29 кеше (2020).

Керәшеннәр саны кимегән. 2010 елда 34822 булса, соңгы җанисәптә – 29978 кеше.

Башкортлар саны да кимү күзәтелә. 2010 елда 1584554 булса, 2010 елда – 1571879 кеше. Дистә ел эчендә башкорт халкы вәкилләре 12665 кешегә кимегән.

Җанисәптә Идел буенда яшәүче башка халыкларның да шактый кимүе күренә.

Марилар – 547605 һәм 423803;
Мордва – 744237 һәм 484450;
Чуашлар – 1435872 һәм 1067139;
Удмуртлар – 552299 һәм 386465 кеше.

2010 елгы җанисәптә руслар 111016896 булса, 2020 елда – 105579179 кеше.

2010 ел белән чагыштырганда, 2020 елда Россия халкы 5 миллионга арткан. Бу Кырымның һәм Севастопольнең кушылуы (2014 ел) һәм Көньяк төбәкләрдә, Төньяк Кавказда халык саны арту белән бәйле. Әйтик, чеченнар 1431360 булса, соңгы җанисәптә – 1674854 кеше. 444 мең булган ингушлар саны да 517 меңгә җиткән.

Россиянең үзәк төбәкләрендә һәм Себердә халык саны бик нык кимегән.

2010 ел белән чагыштырганда, 2020 елгы (чынлыкта 2021 елда үткәрелде) халык санын алуда Татарстанда татарлар саны 78 604 кешегә арткан. 2010 елда 2012571 булса, соңгы җанисәптә 2091175 кеше үзенең милләтен татар дип күрсәткән.

Ә процентлар белән караганда, татарлар саны бер процентка кимегән дип әйтеп була. 2010 елда республикада татарлар 53,15 процент булса, 2020 елда бу сан 52,21. 2010 елда Татарстанда 3785488 кеше яшәсә, ун ел эчендә бу сан 218 мең 312 гә артыграк.

Руслар 73435 кешегә арткан – 1501369 һәм 1574804. Идел буе төбәкләрендә яшәүче халыклар санының Татарстанда да кимүе күзәтелә. Чуашлар (116212 – 90474), марилар (18848 – 15666), удмуртлар (23454 – 21327), мордва (19156 – 12065), керәшеннәр (29962 – 25189), башкортлар (13726 – 11029).

Урта Азия халыкларының артуы күренә. Үзбәкләр (8881 – 14970), таҗиклар (5859 – 12541), кыргызлар (1156 – 2406).

Рәмис ЛАТЫЙПОВ.

Мәчет-мәдрәсәләр яңара

2022 елда Татарстан күләмендә 14, шул исәптән башкалабыз Казанда ике яңа мәчет үз ишекләрен ачты. Алар арасында берничә дистә кеше сыйдырышлылары да, йөзәрләгән кеше кереп намаз укый торганнары да бар. Республикабызның Арча һәм Питрәч районнарында икешәр, Мамадыш, Яңа Чишмә, Әлки, Чирмешән, Актаныш, Баулы, Яшел Үзән, Әлмәт, Казанның Киров-Мәскәү һәм Совет районы мөхтәсибәтләрендә берәр иман йорты ачылды. Шунысы игътибарга лаек: мәчетләр комплекс рәвешендә, үзендә намаз уку мәйданчыкларын гына түгел, ә уку сыйныфларын, мәҗлесләр үткәрү өчен заллар, ашханәләр, никах үзәкләре, кибетләр, корбан чалу урыннары, мәетханәләр, имам йортларын да сыйдыртып төзелә башлады.

Татарстанда җәмәгатьчелек тагын ике мәчетнең ачылуын көтә. Берсе – Кукмара районы Мәчкәрә авылында мәдәни мирас объекты булып саналган, 1791-1793 елларда сәүдәгәр Габдулла Үтәмешев тарафыннан салынган Беренче Җәмигъ мәчете. Бинада реставрация эшләре башланып китте һәм бу эшләрне башкару өчен акча җыю игълан ителде. Акча җыю шулай ук тагын бер мәчеткә – Казанда яңа Җәмигъ мәчете төзелешенә дә башланды. Мәчет төзеләсе җирдә тантаналы рәвештә истәлекле таш куелды.

Татарстанда 2022 елда 3 мәгърифәт үзәге дә үз ишекләрен ачты. Арчада Габдулла Тукай исемендәге рухи-мәгърифәт үзәге, Кукмарада «Һидәят» тәрбия үзәге һәм Яңа Чишмә мөхтәсибәте Үзәк мәчетенең укыту-тәрбия бинасы ачылды.

Татарстан Президенты Р.Н.Миңнеханов ярдәме белән Казанның тарихи «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе комплексында ике яңа бина төзелеп бетте. Мәдрәсәнең административ корпусы һәм тулай торагы аның 140 еллыгына өлгертелгән зур бүләк булды. Шәкертләр өчен төзелгән тулай торак – 3 катлы, гомуми мәйданы 2174,45 кв.м. тәшкил итә. Биредә торак урыннарыннан тыш, мөстәкыйль уку сыйныфлары, медпункт, спортзал һәм башка техник бүлмәләр урын алды. Тулай торак җир өстендәге кичү аша мәдрәсәнең яңа административ корпусы белән тоташкан. Әлеге бинаның гомуми мәйданы – 2798,67 кв.м. Корпус 3 уку сыйныфы, 118 кешелек конференц-зал, ашханә, мәдрәсә җитәкчелеге һәм хезмәткәрләре кабинетларын һәм башка ярдәмче мәйданнарны үз эченә алган.

Казан мөселманнары өчен төрле җәмәгать урыннарында намаз бүлмәләре күбәю дә зур бүләк булды. Үзган елда алар РФ Мөселман эшмәкәрләре ассоциациясе тырышлыгы белән 3 мәйданчыкта – Балалар республика клиник хастаханәсенең Балалар онкологиясе, гематология һәм хирургиясе үзәгендә, «Казанский ЦУМ» сәүдә үзәгендә һәм Түбән Каманың «Рамус-Молл» сәүдә үзәгендә ачылды.

Эльмира СИРАҖИ.

Мәгарифкә күпме акча тотыла

Былтыр Татарстанда «Мәгариф» илкүләм проектын гамәлгә ашыру өчен 2,8 миллиард сум акча бирелгән. Шул исәптән федераль бюджеттан – 2,3 миллиард, республика казнасыннан 500 миллион сум бүленгән.

«Төзелеш һәм ремонт эшләренә – 2,4 миллиард, җиһазлар сатып алуга – 383 миллион, «Авыл укытучысы» программасы буенча авыл торак пунктларына эшкә кайткан мөгаллимнәргә бер тапкыр түләү өчен 10 миллион сум бүленгән», – дип белдерделәр министрлыкта.

Моннан тыш, «Мәгариф» илкүләм проекты буенча 117 авыл мәктәбе, шулай ук сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар белем ала торган ике мәктәпнең матди-техник базасы яңартылган. 46 мәктәпкә һәм алты һөнәри белем бирү оешмасына компьютер җиһазлары сатып алынган.

Алты урта һөнәри белем бирү учреждениесендә 12 остаханә, Бөгелмә районының 2нче лицеенда «Кванториум» балалар технопарклары һәм «Алабуга» махсус икътисади зонасында «IT-куб» балаларга цифрлы белем бирү үзәге ачылган.

Татарстанның Апас һәм Баулы районнарындагы авыл мәктәпләрендә ике спорт залын ремонтлау эшләре тәмамланган.

Россиядә илкүләм проектлар РФ Президенты Владимир Путин күрсәтмәсе белән 2019 елдан гамәлгә ашырыла.

Россиянең Фән һәм югары белем министрлыгы Татарстанның югары уку йортларына 2023 елда абитуриентлар кабул итү өчен 20 844 бюджет урыны бүлеп бирде. Аларның 60 проценты бакалавриат программаларына, 30 проценты – магистратурага һәм 10 проценты белгечлеккә туры килә.

«2024 елга бюджет урыннарын югары белем дәрәҗәсе буенча бүлү пропорцияләре якынча шул ук дәрәҗәдә саклана чак», – дип сөйләделәр ведомствода.

Моннан тыш, «Фән һәм университетлар» илкүләм проекты гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә, узган ел Татарстанга федераль бюджеттан Иннополис Университетының торак корпусларын төзүгә 2,5 миллиард сум акча бүлеп бирелгән иде.

Фәнни тикшеренү офыкларны киңәйтә

Төркиянең Ататөрек исемендәге университетының төрки дөнья тикшеренүләре институтында татар язучысы Галимҗан Гыйльмановның иҗаты турында фәнни диссертация якланды.

«Галимҗан Гыйльмановның повестьләренә фәнни анализ»ны әлеге университетның докторантура студенты һәм Чордаш төрки телләр һәм әдәбиятлар кафедрасы укытучысы Фатих Экиҗи язган.

Фәнни хезмәттә Г.Гыйльмановның иң популяр саналган 18 повесте тикшерелгән, алар дөньякүләм танылган әдәбият белгече, профессор Шломит Риммон-Кенанның аңлату типологиясе теориясе нигезендә анализланган.

Беренче бүлектә Г.Гыйльмановның тормышы, әдәби әсәрләре тикшерелгән. Язучы белән бәйле мәкаләләр, әңгәмәләр дә анализланган. Галим икенче бүлектә теманың фәнни методларын билгеләүгә тукталган.

Фәнни хезмәт галим профессор Седат Адыгүзәл җитәкчелегендә язылган. Аны яклау чарасына онлайн катнашу мөмкинлеге бирелгән. Фатих Экиҗи әйтүенчә, диссертацияне яклау комиссиясе әгъзалары һәм тыңлаучыларында Г.Гыйльманов иҗаты зур кызыксыну уяткан, алар аның башка әсәрләрен дә укырга теләвен белдергән.

«Галимҗан Гыйльманов әсәрләрен төрекчәгә тәрҗемә итү – хәзерге татар әдәбиятын Төркиягә таныту, дип исәплим. Татар әдәбиятының шундый көчле каләмен төрек укучыларына танытмый калу дөрес түгел. Киләчәктә мин аның башка әсәрләрен дә төрекчәгә тәрҗемә итеп, китап булярак бастырам», – дип, яшь галим үзенең киләчәк планнары турында сөйләде.

Фатих Экиҗи – татар-төрек галимәсе Чулпан Зариф-Четинның Мугла университетында укыткан чордагы бакалавр студенты. Аның татар әдәбияты белән кызыксынуы әнә шул елларда башланган.

Рушания АЛТАЙ.

● Татарстанда ана капиталы алган гаиләләрнең 86 проценты аны торак шартларын яхшыртуга тоткан, 35 мең кеше балаларына белем бирүгә, 113 хатын-кыз тупланма пенсия формалаштыруга, 10 меңнән артык гаилә ай саен билгеле бер күләмдә акча баруга тәгаенләгән.

● Татарстандагы Республика балалар клиник хастаханәсе базасындагы Балалар онкологиясе, гематологиясе һәм хирургиясе үзәгендә арка миен күчереп утырту буенча операцияләр ясый башлаганнар.

● Казанда җир өсте кичүләрендәге эшләми торган лифтларны төзәтү өчен 442 миллион сум акча таләп ителә – аларның шахтасын күп катлы йортлардагы кебек җылытыла торган итеп ясарга кирәк. Салкынга чыдам булмаганга, әлеге лифтлар куйгач ук сафтан чыккан һәм инде ун елдан артык шулай эшләмәгән килеш тора. Хәзер житештерүченең кирәкле детальләрне әзерләп бирүен көтәләр.

Рәшә генә булып калган «Рәшә»

Әмирхан Еники әсәре буенча спектакль куелганны күпләр түземсезлек белән көткәндер, чөнки язучы повестенең Камал театрында беренче куелуы. Теле «җырлап тора», өтек-төтек SMS-хатлар заманында халык камил телгә сусаган. Режиссер Айдар Җаббаров әле генә япон драматургы буенча «Күл» исемле спектакле белән хәзерге заманда цензура мәсьәләсен күтәргәннән соң, бу юлы да хәйран калырлык берәр гамәл майтарыр кебек иде. Әмма өметләребез рәшә сыман эреп югалды.



Премьера алдыннан театр фойесында «Яңа татар пьесасы – 2022» бәйгесендә җиңгән авторларга диплом-бүләкләр тапшыру символик мәгънәгә ия, чөнки бу бәйге нәкъ заманча драма әсәрләренә кытлыкны бетерүнең бер ысулы буларак оештырылган иде. Бүгенге тамашачыны кызыктырырдай пьесалар булмаганлыктан, режиссерларыбыз проза әсәрләре нигезендә инсценировка язарга керешә, нәтиҗә буларак, ара-тирә матур спектакльләр иҗат ителде. Ә.Еникинең «Рәшә» повесте буенча куелган бу спектакль дә заманча драматургия мәсьәләсен чишү юлында бер адым иде.

Ә.Еникинең «Рәшә» повесте Бөек Ватан сугышы чоры вакыйгаларын үз эченә ала. Дөнья халкы бүген дә сугыш афәтен баштан кичерә. Өстәвенә, режиссер А.Җаббаров спектакльнең заманча яңгырашын көчәйтеп, Ә.Еникинең бик аз гына вакытка туган йортына, әти-әнисе янына сугылып чыккан һәм кабат фронтка китәргә мәҗбүр булган солдат турында «Бер генә сәгатькә» хикәясен кертә. Филармониянең артистлар бригадасы авылдан-авылга йөреп, концерт-тамашалар күрсәтә, берочтан шушы спектакльне дә уйный, имеш. «Рәшә»нең иң башында кулланылган спектакль эчендәге спектакль алымы тамашачы игътибарын үзенә җәлеп итә. Артистлар Зөлфирә Зарипова, Олег Фазылҗанов, Фәннүр Мөхәммәтҗанов, Гөлчәчәк Хәмәдинурова, Гүзәл Гөлвердиева, һәм әлбәттә, баш роль Рәшидәне гәүдәләндерүче Гүзәл Шакированың талантлы уены бу үзенчәлекле алымны көчәйтте.

Вакыйгалар Казанда бара. Сәхнәдән яңгыраган һәрбер урам исеме йөрәккә якын. Спектакльдә һәрнәрсәдән үзенә файда гына эзләүче, мин-минлекле сәүдә кешесе Зәфәр (Алмаз Борһанов) һәм мәхәббәт, назга сусаган эчкерсез табигать баласы, Казан филармониясе җырчысы Рәшидә мөнәсәбәтләре аша тасвирланган коры, кырыс, кешелексез прагматизм һәм сафлык, эчкерсезлек, хыял каршылыгы бүген аерата актуаль.

Сәхнәләрдә өч-дүрт актерлык спектакльләр ишәйде, «Рәшә» исә мул актерлар ансамбле белән истәлекле. Фирая Әкбәрова, Рузия Мотыйгуллина, Әсхәт Хисмәт, Зөлфирә Зарипова, Илдар Хәйруллин, Люция Хәмит, Миләүшә Шәйхетдинова, Олег Фазылҗанов шул ансамбльдә торт өстендәге авыз сулары китерерлек чияләр сыман.

Татарстанның атказанган артисты Гүзәл Шакированың мондый тирән кичерешле, катлаулы психологик рольләрдә күренгәне юк иде кебек. Актриса җылы мөнәсәбәт күреп, балаларча ышанган, ахырдан үзен өч ел буе сөяркә итеп файдаланулары аңлап гайрәте чиккән, эчке дөньясы чәлпәрәмә килгән эчкерсез Рәшидәне җитмеш җиде төрле төсмергә төреп ышандырды. Г.Шакирова – «Рәшә» спектакленең сүнмәс нуры, суынмас җылысы булып хәтергә кереп калды.

Яңа бу тамашаның уңай сыйфатлары байтак җыелса да, ни өчен өметләр рәшә сыман эреп югалды соң? Кызыклы гына башланып, тора-бара, ягулыгы беткән машина сыман, сүлпәнәеп, тәнәфес белән дүрт сәгатькә сузылгангамы? Хәзерге тизлек заманында өч сәгать ярым бер урында кузгалмыйча сәхнәгә төбәлеп кемнең утырасы килсен? «Бер генә сәгатькә» хикәясе кергән өлештә геройларның уены тирән, хисле булып, тора-бара, рәссамның каралама рәсемендәге кебек, персонажлар схема рәвешендә аннан-моннан гына сурәтләнгәнгәме? Режиссер тирән психологизмны ахыргача тарта алмады. Нәтиҗәдә, алыпсатар һәм иҗат иясе каршылыгы тиешле югарылыкка ирешә алмыйча, гап-гади көнкүреш вакыйгасы булып калды. Андый хәлләр телевидение экраннарында һәр сериал саен очрый. Дөрес, ахырдан Рәшидә утырган көймәнең томан эченә кереп югалуы һәм буш көенчә әйләнеп кайтуын күрсәтеп, режиссер трагизм, лирика аша спектакльнең башындагы югарылыкка кайта алган. Әмма эш узган, тамашаны бу эпизод кына коткарырлык түгел иде инде...

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Иске елны нинди хисләр белән озаттыгыз, яңасыннан ни көтәсез?



Эльмир Низамов, композитор:

– 2022 ел минем өчен иҗат яссылыгында бик кызык, бай ел булды. Быел минем «Ла Примавера» оркестры белән беренче иҗат кичәм үтте. Илүсә Хуҗина белән бергәләп уртак альбомыбызны чыгардык. Без аның белән күп еллар бергәләп иҗат итәбез, ул минем күп әсәрләремне тамашачыга җиткерүче талантлы җырчы. Һәм ниһаять, «Кара пулат» операсын изге Болгар җирендә күрсәттек. Бу спектакльне 7 ел элек махсус Болгар өчен язган идем һәм әсәрне нәкъ менә шул изге җирдә яңгыратырга дигән хыялым бар иде, ниһаять, хыялым чынга ашты. Мин 2022 елга бик рәхмәтлемен. Яңа ел да яңа әсәрләр, яңа премьераларга бай булыр, дип өметләнәм. Иң мөһиме, барыбыз да исән-сау булыйк!

Гөлүсә Баттал, шагыйрә:

– Узган ел бик зур тетрәнүләр елы булды. 2022 елда мин олыгайдым, балигъ булдым дип әйтсәм дә була, чөнки моңа кадәр әле дөньяны алсу күзлекләрдән генә күреп йөргән бер бәләкәй кызчык булганмын… Дөньяны идеал итеп күрү иллюзиясен югалттым… Шул ук вакытта дөньяда нинди генә хәлләр булса да, кешелекле булып кала белә торган кешеләр барлыгын үзем өчен ачтым. Шул кешеләрне табуым, аларны яңа яктан ачуым, кешелеклелекнең әле бу җирдә югалмавына яңадан инануым минем быелгы иң зур табышым булды. Яңа елдан нәрсә өмет итәм? Өметләрнең аклануын, дөньяларның имин, якыннарымның исән-сау булуын...

Лилия Мәхмүтова, К.Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театры актрисасы:

– 2022 елга кергәндә өметләр бик зурдан иде, әлбәттә, әмма ул өметләр акланмады… Ел уртача узды, шөкер. Улыбыз Ришат кече лейтенант званиесе алыр дип көткән идек, чынга ашмады… Яңа спектакльләрдә рольләр дә уйнап булмады. Дөньяның тынычлыгы бетте, анысы да бар. Уртача гына узды дип әйтик… Инде быел дөньяларыбыз тынычлансын, күкләребез аяз булсын иде, Ходаем. Хәзер иң куркыткан нәрсә – илнең иминлегедер… Яңа спектакльләр чыксын иде, матур, әйбәт, мәгънәле спектакльләр… Театрыбызга тамашачы йөреп торсын иде. Бу яңа елда театрыбызның 90 еллыгы да әле, 2023 елга бик зур өметләр белән керәбез, Аллага тапшырдык.

Эльмира СИРАҖИ әзерләде.

Башкаланы гөрләткән декада

● Делегация Мәскәүгә килеп җиткән мизгел.

● ТАССРның Дәүләт җыр һәм бию ансамбле артистлары.

1957 елның май-июнь айларында ТАССРның колхоз театрлары, җырларга яраткан эшчеләр, югары сәнгать кешеләре – барысы бергә Мәскәүне гөрләтә. 24 май-4 июнь көннәрендә башкалада Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы уза. Ул елда мәдәният тармагына шаккатмалы зур акчалар бирелә.

1957 елгы декада чынлыкта икенче омтылу була. Бу чара 1941 елның август аенда узарга тиеш була, әмма сугыш башлана. 1955 елда СССРның Министрлар Советы «1957 елда Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате декадасын уздырырга» дигән карар чыгара. Шул ук елның декабрь аенда КПССның Татар обкомы бюросы декадага әзерлекне башлау турында карар кабул итә. Әзерлекне контрольдә тоту өчен махсус комиссия төзелә.

Шунысы кызыклы: татар декадасына кадәр Мәскәүдә башкорт декадасы уза. Декаданың 65 еллыгына багышланган фәнни конференциядә тарих фәннәре кандидаты, Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты хезмәткәре Елена Камаева бу чараларга киткән суммаларны һәм катнашучылар санын чагыштырды.

Башкорт декадасында 800 кеше катнашкан. Чыгымнар 4 млн сум булган. Бу зур сумма түгел. Без 1955-1957 еллар турында сөйлибез. Акча реформасы әле булмаган чор. Күз алдына китерү өчен берничә мисал: 1955 елда комсомол обкомы беренче секретаренең хезмәт хакы 250-300 сум була, опера һәм балет театрында билет сатучы аена 410 сум ала, театр директоры ай саен 1500 сум ала. Спектакльгә иң кыйммәт билет 40 сум була.

Сүз уңаеннан, ул вакытта пропаганда һәм агитация бүлеген җитәкләгән Камил Фасиев Башкорт әдәбияты һәм мәдәнияте декадасында милли теманың аз бирелүенә игътибар итә, миллилеккә басым ясарга кирәк, дигән фикергә килә.

– Татар декадасында нәтиҗәдә 1200 кеше катнаша, чыгымнар 9 млн сум тирәсе була, – дип аңлатты тарихчы. Ягъни башкорт декадасына тотылган чыгымнардан 5 млн сумга күбрәк.

Гомумән, мәдәният тармагына 1957 елда 32 млн сум акча сарыф ителгән. Тарихчы сүзләренчә, андый сан башка еллардагы документларда очрамый икән.

Татарстан декадасында катнашкан 1200 кеше арасында интеллигенция дә, гади авыл кешеләре дә була. Декадага әзерлекне беренче чиратта авыл мәдәнияте йортларында, китапханәләрдә үзешчәннәр башлый. Профессиональ союзлар соңрак кушыла. Ике ел дәвамында бөтен кеше бер дулкында йөзә. Бу вакыт мәдәният өлкәсендә булган проблемалар турында аваз салу өчен кулай була. Халык вәкилләре обкомга, Министрлар Советына мәдәният йортлары, китапханәләр төзүне сорап хатлар яза, ягъни кешеләр өчен мәдәни туплану урыннары сорый.

Тарихчы әйтүенчә, бу – бик уникаль вакыт, чөнки ул хатлар укыла, аларга җавап кына түгел, ә финанслар да килә. Акчаны мулдан өләшүләренең дәлиле – ул вакытта төзелеп калган кайбер биналар әле дә эшли.

Декаданың төп темасы - нефть. Декадада тәкъдим ителәсе эшләрнең бер өлеше шул темага багышланган булырга тиеш. Бу яктан рәссамнар берлеге белән эшләве иң җиңеле, чөнки алар нефть темасын отып алырга өлгерә. Татарстан нефтьчеләренә багышланган картина серияләре дә әзерләнә. Аларга Татарстанның табигать күренешләре, шәһәр манзаралары кушыла. Махсус декадага дип берничә эш кенә язылә.

Ә менә композиторлар һәм язучылар берлеге белән эшләр алай җайлы бармый. Язучылардан «заманча темага» яңа әсәрләр сорала. 1954 елда КПССның Татар обкомы секретариаты утырышында Нәкый Исәнбәт һәм Әхмәт Фәйзи тәнкыйтьләнә, шуңа да язучылар арасында курку барлыкка килә. Шуңа да карамастан, яңа әсәрләр, яңа исемнәр туа. Мария Елизарованың «Юность Буревестника», Риза Ишморатның «Үлмәс җыр» әсәрләре алына. Минзәлә мәктәбе укытучысының нефтьче хезмәтенә багышланган китабы да Мәскәүдә тәкъдим ителә. Ул вакытта Муса Җәлилгә багышланган әсәрләр дә күп туа.

Композиторлар берлеге рәисе Нәҗип Җиһанов декадага дип партия турында әсәр язудан баш тарта. Тарихчылар әйтүенчә, ул: «Булган шигырьләр илһамландырмый, илһамсыз яза алмыйм», – дип аңлата. Иҗади интеллигенция белән партия арасында бәхәсләр кызу була ул вакытта.

«Архивта аноним хатлар бик күп. Иҗади берлекләр җитәкчеләре өстеннән шикаять язучылар күп булган. Аны хезмәттәшләре оештырган бит инде. Ул хатларда бик әшәке сүзләр язылган. Шулай да җитәкчелек рәисләр составын үзгәртми. Декаданың нәтиҗәсе ул кешеләрнең эшне югары дәрәҗәдә башкаруын күрсәтә», – дип сөйләде тарихчы ханым.

Әйтеп узганча, Мәскәүгә колхоз театрлары да, җыр-моңга оста булган сыер савучылар, гади эшчеләр дә бара. Күбесенең Мәскәүгә беренче тапкыр барулары. Тарих фәннәре кандидаты, Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге Тарих институты бүлеге мөдире Илнара Хәнипова бу чарада катнашкан үзешчәннәр турында сөйләде.

Авыллардагы иң яхшы үзешчән иҗат коллективлары ТАССРны Мәскәүдә тәкъдим итә. Әтнә, Минзәлә, Бондюг (Менделеев) районнары мәдәният йортының җыр һәм бию ансамбльләре, Балтач, Тукай районнары хорлары, Чаллы мәдәният йортының бию ансамбле катнаша.

Тарихчы сүзләренчә, ул коллективлар 500, 600, 1000 кешене җыярлык залларда чыгыш ясый. Иҗади үзешчән коллективларга декаданың иң соңгы зур концертында чыгыш ясау мөмкинлеге бирелә. Балтач районы курайчылары, самавыр белән бию, Бондюг районы коллективы чыгышлары, сөлгеләр белән бию тамашачыларга хуш килә. Иң яхшы коллективларга орден, медальләр бирелә. Декадада катнашкан барлык коллективларга концерт баяннары тапшырыла.

Бүләкләргә килгәндә, декада нәтиҗәләре буенча, Камал театры – Ленин ордены, Качалов театры Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнә. Камал театры ул көннәрдә Мәскәү тамашачысына 14 спектакль күрсәтә. Алар арасында Кәрим Тинчуринның «Зәңгәр шәл», Нәкый Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин», «Зифа» спектакльләре була. Мәскәү халкын профессиональ булмаган театрлар да шаккатыра. Минзәләнең колхоз-совхоз театры чыгышы башкала халкы өчен ачыш була.

Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры Мәскәүдә 12 спектакль күрсәтә. Алар арасында – Нәҗип Җиһановның «Алтынчәч», «Муса Җәлил» опералары һәм Фәрит Яруллинның «Шүрәле» балеты.

Декаданың нәтиҗәләре турында Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Рәсем һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге мөдире, сәнгать фәннәре докторы Рауза Солтанова бәян итте. 1958 елда К.Тинчуринның «Җилкәнсезләр» спектакле өчен рәссам А.Тумашев Тукай премиясен ала. 20 елдан соң К.Тинчурин исеме афишаларда күренә башлый. Декада көннәрендә уңышлы чыгышлар, бүләкләр булуга карамастан, шул елларда тамашачының театрга игътибары кими. Бу – театрда көнкүреш темалар артып, фәлсәфи темалар җитмәү белән дә бәйле. Камал театрының баш режиссеры Ширияздан Сарымсаков репертуарны киңәйтү, көнкүрештән китеп, экспериментлар, яңа формалар эзләү максатын куя. Театрга төрле рәссамнарны чакыралар. Шулай да бу юлда иң уңышлысы Бакый Урманче эшләре аерылып тора. Ул «көнкүрештән» образлылыкка күчә.

Бу масштаблы чараның сугыш елларын соң булуын да истә тотарга кирәк. Декада Бөек Ватан сугышы башланганчы узса, мөгаен, анда катнашучылар саны күбрәк тә булыр иде. Шулай да, нинди ел булуга карамастан, мәдәни чаралар һәрвакыт кабатланып торган.

Гөлүзә ИБРАҺИМОВА.
intertat.tatar

* * *
Кукларбамны тартып узган чакта
Бөкерәеп, алга сузылып,
Икешәр дә өчәр машиналы
Күршеләрем кала кызыгып.
Берни дә юк, дисәм ышанмаслар:
Нәрсәдер бар минем арбамда.
Бизнесменнар кызыгып карап кала,
Мин урамнан үтеп барганда.
Ике-өчәр дачалары булган
Танышларым туктап юл бирә,
Халык арасында очрашканда,
Илбашлары хәтта кул бирә.
Эшкуар да, җилкуар да түгел,
Хәерче дә түгел, мескен дә...
Миллиардерлар, минем хәлдә булса,
Яши алмас иде өч көн дә.
«Мерседес»та йөргән танышларга
Хәерле юл теләп каламын,
Урам чатындагы ятимнәргә
Хәлкадәри хәер саламын.
«Арган, ахры», – диеп уйлыйлардыр,
Адым саен туктап калганда,
Бик авыр да, бик җиңел дә түгел, –
Нәрсәдер бар минем арбамда.

Сез өмет иткән кеше –
Ул да Казанның билгеле
Рухи бай хәерчесе.
Кесәләр буш... Күңелем хуш...
Акчасыз-нисез җырлыйм.
Гармун уйнап, бүрек тотып,
Урамда гына тормыйм.
Юбилейга бүләк булган
Тунымны киеп йөрим.
Салкында туңып утырган
Баланы сөеп йөрим.
Мин дә заман байларына
Кызыгып карап калам.
Кил әле, кер тун эченә,
Кил, җылын, таҗик балам...
Бу бабагыз – пенсиядә.
Йөрергә вакыты бар.
Илдән, Җирдән куылмаган, –
Бер генә бәхете бар...

* * *
Таныш, үземнең җырымны
Ишеттем әллә каян...
Баласы түгелмендер...
Рәхмәт, Тәнрем, әле дә мине
Бу җирдә Адәм иттең.
Тик кызганыч, гомеремне
Заяга әрәм иттем.
Үкенсәм дә артта калган
Имансыз елларыма,
Сыялмыйм шул Мөхәммәднең
Катгый кануннарына.
Указлы шагыйрь булганчы,
Указлы мулла булсам,
Бәлки, деннән язмас идем,
Гел изге юлда булсам...

ИЯЛӘШТЕК

Ияләштек илне-җирне
Талауга,
Үзебезне кол түгел дип
Санауга.
Ияләштек налогка йә
Ясакка,
Туган җирен ташлап киткән
Качакка.

Илдар ЮЗЕЕВ

Җырым минем һич бетәрлек түгел, Кукларбамда гына бер капчык!..

(Татарстанның халык шагыйре Илдар Юзеевнең тууына 90 ел)

Өметләнеп карап кала миңа
Ачлар, ялангачлар салкында:
«Нәрсә икән серле ул арбада?»
Юк, көмеш тә түгел, алтын да...
Урам ташларыннан әкрен атлап,
Тоеп барам заман агышын.
Сыгылам да кайчак, бөгеләм дә, –
Тояп барам заман сагышын.
Кукларбамны тартып узган чакта,
Ник калалар, дисәм, кызыгып.
Күкрәгемнән тулып, ташып чыккан
Җырым кала икән сызылып...
Үз юлымнан читкә каерылмам! –
Кая юнәлсәм дә – юл ачык.
Җырым минем һич бетәрлек түгел,
Кукларбамда гына бер капчык!

* * *
Ычкынырмын акылдан дип,
Уйланудан куркам,
Газапланып йоклап китсәм,
Уянудан куркам.
Соңгы сулышымдыр, бәлки...
Тын алудан куркам,
Вөҗданым керсез булса да,
Сыналудан куркам.
Хәерлегә булмас бу дип,
Куанудан куркам,
Ширпы уты күргәндә дә,
Гел янудан куркам.
Мактап тәмам исертүдән –
Сыйланудан куркам,
Нахак сүзләр ишетүдән –
Кыйналудан куркам.
Дөреслектән читкә таба
Юл алудан куркам,
Аклау өчен сәбәп табып,
Юанудан куркам.
Куркуымнан курыкмыйм һич, –
Кыланудан куркам,
Үз юлымнан каерылып
Югалудан куркам...

* * *
Мин фәрештә түгел, бераз
Шәрабын да каптым,
Яшьлегемдә адашып та йөрдем,
Гөнаһка да баттым.
Юк, шайтан да түгелмен мин, –
Әйттем исә кайттым,
Аның коткысыннан китеп,
Үз юлымны таптым.
Язмыш мине авыр юлда йөртте,
Уттан суга салып,
Үрнәк түгел, миннән була –
Бары гыйбрәт алып...

КИТҮ

Кирәк сүзебезне,
Йөрәк сүзебезне
Әйтеп китик, аннан соң була...
Кояш нурын сибәр,
Күздән яшьләр кибәр,
Без китәрбез әкрен, тын гына...
Күзгә карап куллар кысышканда
Әйтелгән сүз ихлас, чын була.
Таңнар сызылып калыр,
Җаннар өзелеп калыр,
Без китәрбез әкрен, тын гына.
Юксынсагыз безне,
Суытмагыз эзне,
Йөрәк сүзе бары шул гына.
Кырлар, җир-су калыр,
Җырлар моңсу калыр,
Без китәрбез әкрен, тын гына...

* * *
Бәла-каза арттан ияреп йөри,
Кайчак көтеп тора алда ук...
Гомер буе мин яшәгән булдым
Бәхет килер диеп алданып...
Гел ышанып, гел алданып яшәү
Газапларны бераз киметкән.
Шул чорымны кайчак сагынып куям...
Тик үзем дә белмим... нилектән?
Хәсрәтләрем бераз кимер иде,
Үзем генә булсам бәхетсез,
Ничә гасыр буе күрәшеп тә,
Милләттәшләр һаман тәхетсез.
Ышанмыйм да инде, алданмыйм да...
Газапларым шуңа артадыр,
Бабамнарның ватык тәхетләре
Аның саен ныграк тартадыр...

* * *
Хәерче, гарип-гораба...
Кем генә юк урамда...
Хәер бирергә омтылып,
Кесәмә тыгылам да...
Кулны кире тартып алам.
Ватан сугышы гарибе...
Кулына тоткан баян.
Күкрәгендә – медальләре,
Алдында – кәләпүше.
Синме соң бу иң-иң явыз
Дошманны җиңгән кеше?!
«Без көчле!» дип язган шагыйрь
Ярдәм итәлмим мин дә.
Җырым да мохтаҗ ярдәмгә
Шушы хәерче илдә.
Берни юк... Заман җилендә
Чайланган ак башым бар.
Шушы хәлләрдә калуда
Минем дә катнашым бар...

БУРЛАКЛАР

Идел буендагы бурлаклардай,
Тормыш йөген тартып барасың.
Хәлдән таеп арып каласың да
Сүгенәсең туктап: «Анасын!..»
Бар да, бар да халык җилкәсендә:
Кемнәр генә анда менмәгән...
Миллион – өзелә-сузыла аркан тарта,
Кәеф-сафа кора мең адәм.
Мин дә тарттым алар пароходын,
Мин дә бераз гына бурлакмын.
Гамьсезлегем шулай арта-арта,
Яшьлегемне иртә югалттым.
Бар да, бар да халык җилкәсендә,
Бик соңарып шуны аңладым.
Мин акчарлак булып күтәрелдем,
Бурлаклардан һаман калмадым.
Акчарлакның ачы авазлары
Тыңлый-тыңлый, халкым, уйлап бар:
Өзелерме аркан йә түземлек, –
Булырбызмы мәңге бурлаклар?..

* * *
Указлы шагыйрь булганчы,
Указлы мулла булсам,
Бәлки, деннән язмас идем,
Гел изге юлда булсам.
Соң аңладым илһамымның
Күкләргә бәйләнгәнен,
Илаһи шагыйрь икәнен
Мөхәммәд пәйгамбәрнең.
Шик ярала иң-иң тирән
Җирендә күңелемнең:
Табигатьнең бик үк камил
Ияләштек җимерүче
Хакимгә,
Урамдагы кулын сузган
Ятимгә.
Ияләштек туп атуга,
Кан, утка,
Әнкәсенә кайткан кургаш
Табутка.
Ияләштек тешне кысып
Дәшмәүгә...
Ияләштек әнә шулай
Яшәүгә.
«Йом күзеңне, күрмә күпне,
Бул тыныч...»
Менә шулай яшәү үзе
Куркыныч...

АБЫЙЛАРСЫЗ КАЛГАН ЮЛЛАРДА

Ләис Зөлкарнәйгә

Фәиз үткән юллар, нигә миңа
Үпкәләгән кебек карыйсыз?
Ләис энем, сиңа килдем әле,
Син дә, мин дә калдык абыйсыз.
Без дә юлда, без әлегә исән,
Гомер уртасында калабыз.
Фәиз кебек, без дә әкрен генә
Туган җирдән китеп барабыз.
Юл буеның зәңгәр чәчәкләре,
Нигә шулай боек карыйсыз?
Ләис энем, без энеләр идек,
Син дә, мин дә хәзер абыйсыз.
Фәиз үткән юлдан узәк өзеп,
Тимер ташкын уза тезелеп,
Авыл белән кала арасында
Без абыйсыз калдык өзелеп.
Үзебез дә сизми калдык, энем,
Тормыш руле безнең кулларда.
Барулары бик үк җиңел булмас
Абыйларсыз калган юлларда.
Көтә булыр, бәлки, һәлакәт тә.
Кайберәүләр кайтмый бер киткәч...
Йөрәк барыбер хәтәр юлга тарта!
Киттек әйдә, Ләис энекәш!

АЗНАКАЙ АВЫЛЫ

Азнакай җирләренә ясаклы татарлар ике төркем булып килеп утыра. Аларның кайсыдыр 1743 елның 1 июнендә Юрмый волосте биләмәчеләре (вотчинниклары) белән килешү төзегән (Малоизученные источники по истории Башкирии. Уфа, 1986. С. 90.). Әлеге документ ясаклы татарларга мондагы җирләргә хокук бирә, соңыннан аларның типтәр сословиесенә күчерүләренә сәбәп була.

1743 елны Азнакай тарихында иң әһәмиятле даталарның берсе итеп карарга кирәк, әмма авыл аңарчы да яшәп килгән. Соң булса да уң булсын дигәндәй, Азнакай 1762 елда нигезләнгән дип язудан туктарга кирәк.

1748 елгы ревизия документы сакланмаганлыктан, Азнакайда кемнәр яшәвен беренче тапкыр 1762 елгы исемлекләрдән беләбез. Аның халкы бу чорда Байлар волостена караган ике командада күрсәтелә. 16 ир-ат – старшина Мәсәй Хәсәнов, тагын 56 ир-ат старшина Сөендек Тукбаев командасы исемлегендә бирелә. Шул ук документта авылның Мәнәвез елгасы буенда урнашканлыгы турында да әйтелә (РБАДА, 350 фонд, 2 тасв., 3801 сакл. бер., 527-528, 937-941 б.).

1762 елда старшина Мәсәй Хәсәнов командасында теркәлгән Азнакай ир-атларын атап үтик. Болар – Айдагол Аднаголов (81 яшь; уллары Мөстәкыйм һәм Сәгыйть; оныклары Сәлимжәүһәр, Габдессәлам, Сөендек (барысы да Мөстәкыймнең уллары)), Биктимер Кошумбаев (35; уллары Йөзәй һәм Хөсәен), Сарманай Миңлебаев (42; уллары Миңлегол һәм Юмагол).

Исемлектә беренче булып күрсәтелгән Айдаголның атасы Аднагол (Азнагол) булган. Шул исемдәге Азна (атна – җомга) сүзенә «ка» иркәләү-кечерәйтү кушымчасы ялганып, Азнакай дигән диалекталь исем барлыкка килгән. Мондый исем атна көнне туган ир балага кушыла торган булган.

● **Азнакай авылының 1762 елгы исемлегендә беренче булып Айдагол Аднаголов теркәлгән.**

Айдагол 1681 елда дөньяга килгән, димәк, аның атасы Азнакай (Азнагол) бу якларга XVII гасыр ахыры-XVIII гасыр башларында килеп утырган була.

Азнакайлыларның икенче төркеме 1762 елда старшина Сөендек Тукбаев командасына керә. Болар түбәндәге ир-атлар: 1) Котлымәт Исмәгыйлов (50 яшь; уллары Котлы, Йосыф); 2) Йөзәй Ишмәкаев (45; уллары Абдул (30; аныкы Әмин, Хәлил), Илмәт (16) һәм Рәфикъ); 3) Балтай Ишмәкаев (64; уллары Габдүкәй, Габдрахман (31; аныкы Мөэмин, Әмин), Габдерәззак (25), Габдерәшит (27; аныкы Габдерәхим)); 4) Гадел Ишмәкаев (мәрхүм; уллары Колшәрип (27; аныкы Ягъфәр, Ярмөхәммәт), Бакый (25; аныкы Ишмөхәммәт), Якый (21), Сәлим (4)); 5) Тукташ Тукаев (75; уллары Бикбау, Ибрай); 6) Биккол (57; уллары Бикчура, Сәгыйть, Салих, Хәмит, Вәлит) һәм Юлдаш (10) Кадермәтовлар; 7) Гомәр (40; уллары Госман, Әхмәр, Тимеркәй) һәм Бакир (16) Мәмәтәевләр; 8) Хәлил Бохаров (37; уллары Җәлил, Рәфикъ, Рамай, Аднагол); 9) Бикенә Чәмкәев (45; улы Бикмөхәмәт); 10) Ишбулат Ишмәтов (85); 11) Юлдаш (33; улы Мәвлүкәй), Кинҗә (24), Хәсән (18) Мерәсовлар; 12) Габдүкәй (30; уллары Габделкадыйр, Габделҗәлил, Габделваһап), Мәвлүкәй (26), Мәвлүм (?14) Хәсәновлар. Ревизия исемлегенең соңгы битенә староста Котлымәт һәм үз араларыннан сайланган («выборной») Габдүкәй Хәсәнов тамгаларын салган (РБАДА, 350 фонд, 2 тасв., 3801 сакл. бер., 937-941 б.).

Шулай итеп, 1762 елда Азнакайда барлыгы 72 ир-ат ясаклы татар исәпләнә. Моннан соңгы халык санын алу документларында алар бары тик типтәр сословиесендә теркәлә.

Е.Пугачев җитәкчелегендәге Крестьяннар сугышы (1773-1775) төбәкне читләтеп үтми. 1775 елның февралендә Уфа провинциаль канцеляриясеннән Оренбург губерна канцеляриясенә җибәрелгән ведомостьта баш күтәргән күп кенә авыллар санап үтелә. Араларында Азнакай үзе һәм дистәләгән татар авыллары бар.

1795 елда Азнакайда 46 хуҗалык исәпләнә. Өч сословиегә бүленгән халыкның төп өлешен типтәр сословиесендәге татарлар (161 ир-ат һәм 163 хатын-кыз) тәшкил итә. Башкорт сословиесендәге (6 ир-ат һәм 18 хатын-кыз) һәм ясаклы (4 ир-ат, 4 хатын-кыз) татарлар бик аз санда була. Беренчеләре «типтәр»ләрдән соң килеп утырган дип уйларга кирәк.

5 нче ревизия (1795 ел) документы Азнакайга әлеге ясаклы татарларның кайчан күчеп утыруына ачыклык кертә. Сәйфелмөлек Мөслимов (44 яшь) һәм Гапсәлам Мостафин (28) гаиләләре (4 ир-ат, 4 хатын-кыз) монда Уфа казна палатасы указы (1795 ел, 11 июль) нигезендә Бәләбәй округының Кинҗәкәй (хәзерге Туймазы районындагы Райман) авылыннан килеп утыра. Азнакайга терәлеп торган Мәнәвезтамак (чыганакта «Араслан Мелеус Тамак тож») авылында 8 ир-ат һәм 10 хатын-кыз яши. Болар берара сәүдәгәрлектә йөреп яңадан ясаклы татар булып язылган («из купцов в ясашные татары») Мәди (1716-1786; уллары Габделкәрим (55), Саткол (40), Мөхәммәт (33)) һәм Даут (1717-1794; улы Мөхәммәт) Имангуловларның гаиләләреннән тора (БР МА, И-138 фонд, 2 тасв., 23 сакл. бер., 67, 159-160 б.).

1816 елга халык саны тагын да арта. Типтәр сословиесендәге татарлар 82 хуҗалыкта 223 ир-ат һәм 219 хатын-кыз булып яши. Ревизия исемлегендә беренче булып Котлы Котлымәтов (1814 елда мәрхүм) һәм Ибраһим Котлыев (27 яшь) хуҗалыклары теркәлгән (Шунда ук, 168 сакл. бер., 656-671 б.). Башкорт сословиесендәге татарлар нибары 13 ир-ат һәм 3 хатын-кыз (3 хуҗалык) тәшкил итә.

1816 елда шулай ук лашман бурычын башкаручы ясаклы татарлар да (11 ир-ат һәм 8 хатын-кыз; 4 хуҗалык) яши. Болар Сәйфелмөлек Мөслимов (64 яшь), Габделбәшир (41) һәм Габдерәшит (37) Сәйфелмөлековлар, Гапсәлам Мостафин (46) гаиләләреннән тора. Соңгысы бу мәгълүматны тапшыручы буларак ревизия документына татарча кул куйган. Азнакайга терәлеп торган Арыслан (Мәнәвезтамак) авылында 8 ир-ат һәм 7 хатын кыз (2 хуҗалык; Габделкәрим Мәдиев һәм Мөхәммәт Давыдов гаиләләре) яши. Алар да лашман бурычын башкаручы ясаклы татарлар була.

1855 елгы реформа буенча типтәр сословиесендәгеләрне «Башкорт» гаскәренә кушалар. Шул чордан Азнакай «типтәр»ләре дә «башкорт» дип атала башлый һәм Кәкре Елга, Кәтем, Зур Сукаеш, Түбән Сукаеш, Банки Сукаеш, Арыслан (Мәнәвезтамак) авылларының шул сословиеләрдәге татарлары белән 23 нче кантонның 6 нчы юртасына керә.

1859 елның 16 маендагы ревизия документы буенча, Азнакайда югарыда әйтеп үткән «Башкорт» гаскәре карамагына караучы 477 ир-ат 497 хатын-кыз (76 хуҗалык) исәпләнә. Халыкның күпчелеген типтәр сословиесендәге, әмма 1855 елдан «башкорт» саналган татарлар тәшкил итә. Болар исәбенә Исхак Исмәгыйлов (46 яшь), Фәррукша Габбәсов (31 яшь), ике хатынлы Йосыф Габделвахитов (57 яшь; аның улы Шаһимәрдан, чыганакта «урядник, в должности старшинского помощника»), Якуп Әминов (50 яшь; ике хатынлы), Дәүләтбай Тимербаев (41 яшь; «отставной солдат»), указлы мулла Габделгалим Зәйнелгабидинов (52; өч хатынлы) һәм башкалар керә. Башкорт сословиесендәгеләр 25 ир-аттан һәм 21 хатын-кыздан (5 хуҗалык), Габделгафар Габделваһапов (39 яшь), Гыйззәтулла Хисмәтуллин (27 яшь), Хисаметдин Исхаков (65 яшь), Төхвәтулла Исхаков (52 яшь) һәм Гайнулла Исхаков (48 яшь) гаиләләреннән тора. «Типтәр» сословиесендәгеләр бу ревизия документында «типтәрдән башкорт» дип язылган (БР МА, И-138 фонд, 2 тасв., 757д. сакл. бер., 52-90 б.). Азнакайда яшәүче дәүләт крестьяннары (элеккеге ясаклы татарлар) аерым исәпләнә, шуңа күрә бу документтагы 76 хуҗалык исәбенә керми.

«Типтәр»ләрнең 1855 елдан «башкорт» булып китүе Самара губернасы буенча белешмә әдәбиятта да чагыла. Шуның иң беренчесенә күз салсак, 1859 елда Азнакайда 549 ир-ат һәм хатын-кыз (213 хуҗалык) «башкорт»лар һәм дәүләт (казна) крестьяннары яши булып чыга (Список населенных мест Российской империи. Т. 36. Самарская губерния. – С.-Петербург, 1864. г. – С-П.). Шулай итеп, «типтәр»ләр бөтенләй телгә алынмый: 1855 елда «Башкорт» гаскәре карамагына күчерелгәнлектән, статистик чыганакларда боларның сословиеләрен дә «башкорт»дип яза башлыйлар. Хуҗалыклар саны ике тапкырдан артык булу, 16 майда ревизия булып үткәч, яшь гаиләләрнең яңа хуҗалыклар булып теркәлүе белән аңлатыла.

Ревизия документына кайтыйк. 1859 елның 16 маенда Азнакайдан соң Арыслан (Мәнәвезтамак) авылы теркәлгән. Монда «Башкорт» гаскәре карамагындагы нибары бер хуҗалык – Габделнасыйр Габделкәримовның варислары

(уллары Исмәгыйль, Миңлегали һәм кызы Таженниса). Аларның сословиесе шулай ук «типтәрдән башкорт» дип язылган.

1885 ел ахыры - 1886 ел башына караган мәгълүматлар буенча, волость үзәге Азнакайда 293 хуҗалык, 746 ир-ат һәм 765 хатын-кыз була. Азнакай волостена тагын алты татар (Әсәй, Сәпәй, Уразай, Балтач, Әгерҗе, Туйкә) һәм бер рус (Холмовка) авылы кергән.

Азнакай авыл җәмгыятенең бу чорда 3830,4 дисәтинә – эшкәртергә уңайлы, 151,6 дисәтинә уңайсыз җирләре була. Сөрүлекләр – 995,6, урман-куаклыклар – 979,2, печәнлекләр – 349,1, йорт яны җирләре һәм көтүлекләр 332,6 дисәтинәне алып тора. Күренгәнчә, авыл җәмгыятенең биләмәсе зур. Әмма, сословиеләргә карап, аның күләме шактый аерыла. 16 яшьтән 60 яшькә чаклы һәр ир-ат «башкорт»ка – 25, дәүләт крестьянына, ягъни элеккеге ясаклы татарга – 10,9, «типтәр»гә – 10 дисәтинә туры килә.

1889 елда Азнакайда 315 хуҗалык булып, 1610 кеше яши. Монда 2 мәчет эшли. Гыйбадәтханәнең икенчесе 1873 елда салына. Авыл җәмгыятенең 3891 дисәтинә – уңайлы, 45 дисәтинә уңайсыз биләмәләре була.

Гасыр ахырына Азнакай шактый зурая. 1897 елда андагы 371 хуҗалыкта 960 ир-ат һәм 972 хатын-кыз яши. Бу күрсәткечләр буенча ул волостьта беренче урында тора. Әсәйдә – 279 хуҗалык (719 ир-ат һәм 731 хатын-кыз), Сәпәйдә – 254 (705 һәм 687), Уразайда – 233 (630 һәм 606), Балтачта – 202 (531 һәм 516), Әгерҗедә – 156 (443 һәм 451), Туйкәдә 154 хуҗалык (429 һәм 393) исәпләнә. Волостьтагы бердәнбер рус авылы Александровкада ул вакытта 15 хуҗалык булып, анда 50 ир-ат һәм 55 хатын-кыз яши.

Әйтеп үтелгән Александровка – хәзерге Холмовка авылы ул. Холмовка атамасы документларда еш телгә алына. Әмма, бу кечкенә авылга нигез салган Александр исемле алпавыт булганлыктан, кайбер очракта Александровка атамасы да кулланышта йөри. Авыл чама белән 1858-1860 елларда барлыкка килгән.

Авыллардан тыш, Мәнәвез (чыганакта Мәнәүс) елгасында бер утар (усадьба) һәм хуторлар була. «Шкаповка» дип аталган утар хуҗасы – дворян Ильин. Монда 32 ир-ат һәм 26 хатын-кыз гомер итә. Алпавытның 470 дисәтинә җир биләмәсе була. «Шкаповка» атамасы Азнакай төбәгендә яшәүче өлкән буын кешеләренә яхшы таныш. Әмма аның ничек барлыкка килүен күпләр белмидер. Шуңа ачыклык кертик.

1867 елда Самарада басылган бер китапта А.И. Шкапский телгә алына. Аның Бөгелмә өязендә өч урында биләмәләре булган. Берсе – 192, икенчесе – 444, өченчесе 462 дисәтинә зурлыкта. Әлеге биләмәләр еш кына аның исеме белән йөртелгән. Азнакай янындагы «Шкаповка» утары анык булып, ул аны дворян Ильинга саткан булуы мөмкин. Ильин үзе китапта күрсәтелми, димәк, ул бу тирәгә соңрак килеп төпләнә (Список гг. дворян, владеющих землею в Самарской губернии в 1867 г. – Самара, 1867.– С.130.).

Хуторларга тукталыйк. Дворянка Герасимова биләгән хутор Шкаповкадан зуррак – 550 дисәтинә. Әмма монда нибары 11 кеше яши.

Герасимова хуторыннан соң, зурлыгы буенча икенче урында Шонкаров биләмәсе (431 дисәтинә). Стәрле елгасы буендагы ул хуторда бер йорт булып, анда хезмәтче яшәгән. Монда ул тегермән дә тоткан.

Пискунов хуторы да (311 дисәтинә) Стәрле буенда урнашкан. Әмма, башкалардан аермалы буларак, җир аның үз милке түгел, аны ул казнадан арендага алган. Пискунов шул җирләрнең бер өлешен тирә-як авыл кешеләренә арендага биреп, калган мәйданда, эшчеләр яллап, иген иккән.

Бу чорда Азнакай волостенда барлыгы 17 су тегермәннәре була. Алар волость аша агучы өч елгада (Мәнәвез, Стәрле, Тегермән Елга) урнашкан. Авыллар буенча алганда, Азнакай һәм Балтачка – дүртәр, Уразай һәм Әсәйгә – өчәр, Туйкә һәм Әгерҗегә икешәр тегермән туры килә.

Азнакайда игенчелек торышын тасвирлаган мәгълүматларга тукталыйк. 1900 елның 28 сентябрендә төзелгән документтан күренгәнчә, авылда арыш, солы, карабодай, борай, бодай һәм тары иккәннәр. Балчыксыл кара туфраклы басуларда төп культура – арыш уңышы бер дисәтинәдән 40 (начар), 90 (уртача) һәм 150 (яхшы) потлап чыккан. Ә менә шундый ук туфракта, әмма тирес кертелмәгән басуларда яхшы уңган арыш 100 пот тирәсе генә чыга.

Икенче төп культура – солы – уңышы белән дә шундый закончалык күзәтелә. Беренче очракта уңышның түбәне – 40, уртачасы – 80, яхшысы 150 пот тәшкил итә. Икенче очракта исә шундый ук тәртиптә 35, 70 һәм 100 пот.

Калган культуралар (карабодай, борай, бодай, тары, ясмык, борчак), арыш һәм солы белән чагыштырганда, шактый аз игелә. Карабодайны, яхшы уңганда, 1 дисәтинәдән 80 пот алганнар. Начар уңыш 25-30 пот тирәсе була.

Борай һәм бодай уңышы бертигез дәрәҗәдә. Начар уңыш – 40, уртачасы – 70, яхшысы 130 пот булган. Тарыныкы шундый ук тәртиптә 30, 60 һәм 90 пот.

Азнакай тирәсендәге җирләрнең бер өлеше чуерташлы кара туфрактан тора, монда уңыш та түбәнрәк. Мәсәлән, тирес кертелмәгән урыннарда арыш, солы һәм карабодайның чагыштырмача яхшы уңышы 80 пот булган...

1900 елда Азнакайда 348 хуҗалык исәпләнә. Аларның барлык җирләре 3981,8 дисәтинә. Биләмәләрнең шактый өлешен сөрүлекләр (995,5 дисәтинә), урман (979,2), йорт яны җирләре һәм көтүлекләр (332,6) алып торган.

Мең дисәтинәгә якын сөрүлекләр Азнакай кебек зур авыл өчен аз, билгеле. Шуңа күрә күп хуҗалыклар вакыт-вакыт казна җирен арендага алган. Мәсәлән, Мөхәммәтсадыйк Сиражетдинов – 10, Габдерәшит Фазуллин – 8, Василий Астафьев – 8, Мөхәммәтвәли Сиражетдинов – 7, Миргали Әхмәтҗанов – 7, Мөхәммәди Искәндәров – 7, Мостафа Ибәтуллин – 7,5, Галиулла Гомәров – 6 дисәтинә җирне арендага ала. Калган хуҗалыкларның мондый җирләре азрак. Казнадан арендага алган барлык җир участогы 150 дисәтинәдән арта. Арендага алган җир исәбенә хуҗалыклар чәчүлекләр яисә печәнлекләр мәйданын киңәйткәннәр.

Умартачылык аерым игътибарга лаек. Аның белән шөгыльләнүчеләр Азнакайда шактый. Статистик мәгълүматлардан күренгәнчә, авылда 32 хуҗалык 122 баш умарта тота.

XIX гасыр ахырында Азнакай ике мәчет тота. 1900 елда авылның указлы муллалары булып Мөхәммәтшакир Фәттахетдинов һәм Мөхәммәтфатыйх Шакиров тора. Мөхәммәтшакир хәзрәт типтәр сословиесендәге 46 яшьлек татар. Ул Уфа губернасы Бәләбәй өязе Сарсаз авылыннан (хәзер Шаран районына керә) күчеп килгән. Гаиләсе зур түгел – хатыны (30 яшь) һәм ике кыз баласы. Хуҗалыгында 5 эш аты, 4 сыер һ.б. вак-төяк маллар асрый. Имана һәм арендага алган җирләре була. Ул 20 дисәтинәгә якын мәйданда иген игә. Хәзрәтнең умарталыгы 28 баш була.

Мөхәммәтфатыйх Шакиров (35 яшь) – төп Азнакай кешесе, типтәр сословиесендәге татар. Ул хатыны (27 яшь), улы һәм 2 кызы белән яши. Хуҗалыгында 4 эш аты, 6 баш мөгезле эре терлек (шуның икесе сыер) һәм 4 сарык асрый. Аның да имана һәм арендага алган җирләре зур, иген мәйданы 15,67 дисәтинә тәшкил итә. Йортында 2 хезмәтче эшли.

Ике хәзрәт тә Зәкиҗан Шаһгәрәевнең «Төрмәләр хатирәсе» исемле китабында телгә алына. Безне кызыксындырганы – З.Шаһгәрәевнең Бөгелмә төрмәсенә этап белән барганда Азнакайда тукталуы. Бу хакта китабында ул болай яза: «Юлда Азнакай авылында туктап, үтенечем буенча кардәшем Фатыйх әфәнде ханәсенә төштек. Кардәшләрем мәсьәләне аңлап, байтак кына мөтәәссир (кайгы-хәсрәтле.– Т.К.) улмышлар иде. Бигрәк тә икенче мәхәллә имамы карт хәзрәтнең (Шакир хәзрәтнең) хис вә мәрхәмәт илә кызгануы, йөзендән вә хәрәкәтендән мәгълүм булуы илә бергә доносчик А ... ны (архив документларын өйрәнү аның Тымытык мулласы Адылов Шаһиморат булуын раслый. – Т.К.) кылуында илә мәгълүм булмакта иде».



● Азнакайлыларның икенче төркеме (1762 ел).

Бу юллардан Мөхәммәтфатыйх хәзрәтнең – беренче, Мөхәммәтшакир хәзрәтнең икенче мәхәллә имамы булуы аңлашыла. Өстәвенә, икенчесен автор белән кардәшлек җепләре дә бәйләгән. Бөгелмә төрмәсендә ятканда һәм этап белән барганда З.Шаһгәрәев аның һәрдаим ярдәмен тоеп яшәгән. Хәер, бер Мөхәммәтфатыйх хәзрәт кенә түгел, бик күпләр Зәкиҗан хәзрәткә теләктәшлек белдерә, кулдан килгәнчә ярдәм итә. Моның шулай икәнлеге китапның 22 нче битеннән алынган түбәндәге юлларда ачык чагыла: «Бу көн ахшамнан соң минем ихласлы дусларымнан Һади әфәнде (монда Һади Атласи турында сүз бара.– Т.К.) килде. Миңа булган ихласны, мине кызгануны күзеннән мөлдер-мөлдер туктаусыз аккан яшьләре тәгъриф итмәктә иде. Безне иптәшләр илә бергә ашка чакырды, безнең иптәш солдатлар «Бу көн кич инде, иртәрәк булса, барган булыр идек» диеп йомшак сүз […] илә юатып җибәрделәр. Берәр ярты сәгать үтмәде, әлеге Һади әфәнде ярты каз, ике булки, әллә никадәр акмай-коймак китерде».

Документларга кайтып, мәәзиннәр турында әйтеп үтик. Аларның өлкәне – Шиһабетдин Зәйнелгабидинов (57 яшь). Аның гаиләсе хатыны (45 яшь), 4 улы, бер кызы, туганының кызы һәм килененнән тора. Ул күп мал-туар (5 эш аты, 4 сыер һ.б.) асрый, 21,72 дисәтинә мәйданда иген игә. 20 баш умартасы да була. Хуҗалыкта шактый эшне хезмәтчесе башкарган.

Мәәзиннәрнең икенчесе – Габдрахман Фазуллин (44 яшь). Ул хатыны (33 яшь), 2 улы һәм 2 кызы белән яши. Эш аты, 8 мөгезле эре терлек һәм 24 сарык асрый. Имана һәм арендага алган җирләрнең 10,27 дисәтинәсендә иген иккән.

Азнакайда мәктәп тә була. 1900 елгы мәгълүматлар Закирҗан Галимовның (30 яшь) елга 6 ай укытучылык белән шөгыльләнүен күрсәтә. Ул Азнакайда туып-үскән, гаиләсе һәм хуҗалыгы зур түгел.

Авылда сәүдә эшчәнлеге киң үсеш ала. Азнакай сәүдәгәрләрне волость үзәге буларак та җәлеп иткән. Аларның кайберләре монда лавка тоткан. Мондый сәүдәгәрләрнең барысы диярлек – Бөгелмә мещаннары. Алар монда кайчаннан яши башлагандыр, билгесез.

Лавка тотучылар арасында Хәмидулла Дәминов (40 яшь) – төп Азнакай кешесе. Аның гаиләсендә хатыны (30 яшь), 3 улы һәм кызы була. Ул 2 эш аты, 5 мөгезле эре терлек (шуның икесе сыер), 9 сарык һәм 3 кәҗә тота. Хәмидулла сәүдәгәр 10 дисәтинәдән артык иманадан файдаланган. Шуның 6,87 дисәтинәсендә ул иген иккән, 4,65 дисәтинәсен парга калдырган. Моннан тыш, 1,13 дисәтинә арендага алган чәчүлекләре була. Сәүдә эшен үзе алып бара. Бары кыр эшләре вакытында гына эшчеләр яллаган.

Сәүдәгәрләрнең икенчесе – Хәсәнша Баязитов (25 яшь). Ул үзенең һәм абыйсының гаиләсе белән бер хуҗалык булып яши. Әлбәттә, һәрберсенең монда зур йортлары була. Баязитовларның хуҗалыгы сәүдәгәрләр арасында гына түгел, гомумән Азнакайда иң эре хуҗалык санала. Аларның сатып алган җир участогының 164,5 дисәтинәсен – сөрүлекләр, 8 дисәтинәсен – печәнлекләр һәм 9 дисәтинәсен урман алып тора. Калган 43,5 дисәтинә җир эшкәртелми, шуның 7 дисәтинәсен алар арендага биргән. Баязитовлар арыш (15 дисәтинә), бодай (4,5), солы (4), тары (2), борай (1,5), карабодай (1,5) һәм борчак чәчкән. Хуҗалыкларында 4 эш аты, 5 сыер, 30 сарык һәм 5 кәҗә асраганнар. Көндәлек эшләрне 2 ир-ат хезмәтче башкарган. Кыр эшләре вакытында аның басуларында көнлекчеләр дә бил бөккән.

(Дәвамы киләсе санда).

Таһир КӘРИМОВ,
тарих фәннәре кандидаты.

Бирәсе килми читләргә

(«Яшьлегемне эзлим» повестеннан)



Әхсән БАЯН

Чит җирләр хәтердә, ничектер, биеклек рәвешендә калган. Ихтимал, таулы урыннарда йөрү шулай тәэсир иткәндер. Ә биектә куркыныч: егылып төшсәң, сөякләреңне дә җыярлык түгел. Ә мин туган җиргә кайтып егылдым, һәм исән калдым. Аннан да ышанычлырак урын юклыгына инандым. Туган җир! Ничә кабат кайтып егылдым сиңа мин үз гомеремдә, ничә кабат?!. Ничә кайтсам да кабул итәсең. Шуңадыр күңел үзен монда тынычрак хис итә.

Кайткач та беренче ишеткән хәбәр шул булды: Сафуан абзыйны җирләгәннәр. Әлбәттә, минем өчен яңалык түгел бу, шулай булачагын сизеп киткән идем ич.

...Снарядлар яумый, ләкин кешеләр үлә.

...Сугыш дәвам итә... Геройларсыз, романтикасыз...

Икенче хәбәр — анысы менә минем кулда: Ленадан хат. Көтеп яткан.

Хатны ачарга ашыкмадым. Өстәл артында якын киләчәк турында баш ватып утырдым. Ихатага чыктым, бакчага кердем.

«Җәмгыятькә нәрсә дә булса бирмисең икән, синең аңардан үзеңнең дә таләп итәргә хакың юк». Дөрес сүз, килешәм. Дөресрәге: килешәм һәм килешмим. Ни өчен? Җавап әзер түгел.

Бакчада орлыктан тишелеп чыккан алмагач үсентеләре бар, күптән аларны күчереп утыртырга вакыт, әмма кемнең дә кулы тимәгән. Алар рәтләп үссеннәр өчен, берәү кайгыртырга тиеш. Ни өчен шул берәү мин түгел? Димәк, үсентеләргә урын сайларга кирәк. Бу урында элекке бакчаны бетереп, бәрәңге утырта башлаганбыз. Бәрәңгесез – көн юк. Әнә тегендә, өй түрендә, күпме җир буш ята, шунда киртә корып, ник бакча ясамаска?

Иске-москы агачлардан көнозын киртә тоттым. Икенче көнне алмагачларга урыннар казый башладым. Көзгә кояш үзенә күрә җылыткан була. Тирләп маңгайларны сөртеп куям. Үзем эшлим, үзем уйланам.

Бу агачларны күчереп утыртмасам, су сипмәсәм, терлек ашамасын өчен хәстәрен күрмәсәм, койма тотмасам, алардан нинди уңыш көтәргә мөмкин? Җимеш бирми дип аларны тиргәргә кемнең хакы бар? Бакча гына түгел, басу да шулай. Ашламагач, карап үстермәгәч, уңыш юк. Ә миннән уңыш көтәләр...

Өй янында тәрәзәләргә каршы бакча барлыкка килде. Алмагачлар үсәр, шомыртлар... Алардан рәтле җимеш көт инде син: ялганмаган агачлар, вакытында кул җитмәгән. Хәзер соң инде. Шулай да үссеннәр, әче булса да, җимеш бирсеннәр — безнең кичерешләр әчелеге аларда калсын. Кемнәрдер аны татып караячак бит әле! Татып карарлар һәм, ихтимал, безне дә аңларлар...

Кесәдә хат һаман йөри — Лена хаты. Таушалып беткән инде, ә минем ачканым юк. Нәрсә язуы мөмкин икән? Ачсам, романтик рухта язылган төче сүзләр укыйм:

«Әнис бәгырем!

Син минем белән серләреңне бөтенләй уртаклашмый башладың. Мин моның сәбәбен аңлыйм, әлбәттә. Ләкин чарасын таба алмыйм. Мин сине һаман үз янымда гына тотар идем, иң ышанычлы киңәшчең булыр идем. Тик син моны теләмәдең һәм теләмисең. Синең күңелең

башкада иде һәм хәзер дә тынычлана алганың юк. Шулай да мин сиңа ачуланмыйм. Теләсә ничек кенә булса да, әллә нинди авыр хәлләрдә калсам да – барыбер мин сине яратачакмын. Сине миннән беркем дә тартып ала алмас.

Сине көтеп арыгач, үзеңне эзләп авылыгызга килгән идем. Син инде киткәнсең икән. Кая, ни өчен? Синең миңа бу хакта әйтерлек тә якынлыгың калмагандыр шул инде. Яратуыңны таләп итмим, гади дус, таныш буларак, үзең хакында белдерүне дә хәзер артык күрәсеңме?

Син бу хатны укый алырсыңмы, белмим. Минем өчен барыбер. Миңа эчтә җыйналган ярсуымны тышка чыгарырга кирәк. Бары шуның өчен генә язам, чөнки язмыйча булдыра алмыйм, түзә алмыйм.

Авылыгызга килгәндә урмандагы үзебез генә белгән, кайчандыр янында үзебез кичләр уздырган каенга синең исемеңне уеп яздым. Каенның яралары төзәлгәч тә, ул исем барыбер танырлык булып калачак. Ул исем минем күңелдә дә үзенең эзен җуймаячак. Аерылсак та, бөтенләй очрашмас булсак та.

Хуш, минем бәхетсез мәхәббәтем! Лена».

Хат, бер карасаң, йөрәк каны белән язылган, анда үлеп баручы мәхәббәтнең соңгы әче зары ишетелгән сыман тәэсир итә. Икенче минутта, әллә ничек, ышанмау, шик туа — бу сүзләр аның үз йөрәгеннән чыккан сүзләр түгел, ә күпләргә таныш, гомуми сүзләр, ятланган фразалар төсле тоела.

Ләкин бер нәрсәгә ышанам: ул инде өметен өзгән һәм башкалар белән чуала башлаган. Бу җылы сүзләр мине рәнҗетмәскә, хәлемне җиңеләйтергә тырышудан гына язылган. Кирәкмәгән төчелекнең шулай максаты була – моны гына аңларлык хәлдә бит әле мин. Шушы кырыс нәтиҗәне раслар өченме, шикләнү тойгысын басарга теләпме, үзебез генә белгән теге каен янына ашыктым. Шигем монда тулысынча өстенлек алды – анда минем исем язылмаган, каен тузы чип-чиста. Ленаның кулы бөтенләй кагылмагандыр да, бәлки. Эх, Лена, Лена! Мәхәббәт турында, үлемсез мәхәббәт хакында сөйлисең бит. Исемемнең синең күңелдә күпме сакланачагын инде ахырынача төшенгәнмен ич. Йә, хуш инде. Мин сиңа ачуланмыйм. Минем сиңа бернинди дәгъвам юк, аерылсак та, бөтенләй очрашмас булсак та. Минем белән бернәрсә дә чыкмасына ышангач, үз тормышың хакында уйларга тиеш ич син, ниһаять!

Шулай да безгә тагын очрашырга туры килде. Ишкарга кино килгән иде. Авылда сирәк була торган вакыйга бу, бармый ничек каласың.

Караңгы күптән төшкән. Халык клубка шулай һаман соң җыела. Мин барып кергәндә, алдагы урыннарның күбесе буш иде әле. Ни өчендер, арттагы урыннарның берсенә утырдым да тагын бер кешелек урын калдырдым.

Әллә Лена өчен... Гаҗәп... Лена!

Озакламый керерсең, гадәтеңчә якты итеп бер елмаерсың, нечкә, җиз калай тавышың белән көләрсең... бәлки, бераз күңел дә күтәрелеп китәр әле. Белмәссең. Кергән бер кешегә күтәрелеп карыйм, уңайсызланып, караганымны сиздермәскә тырышам. Шулай азакка хәтле диярлек көткәч, күңел сине күрергә ашкына башлады. Теләк – ярсынуга күчте. Без һәрвакыт шулай, үз-үзебезне нәрсәгә дә булса ышандыра алабыз, алдый алабыз һәм кичерә башлыйбыз. Кино башланырга санаулы минутлар гына калды. Урамда мотор гөрелди башлады, пленка тәгәрмәчләрен аппаратка якын китерделәр, берсе әнә куелды да.

Ут сүнәр һәм... Шул минутта ишектән син күрендең... Йөрәк шатлыгыннан сикереп, дөпелдәп куйды. Син күрсен өчен, мин урынымнан торып бастым. Менә күрерсең дә таныш елмаюың белән... Син елмайдың... башыңны түбән идең һәм алга атлый бирдең. Синең арттан тагын бер кеше – ир кеше килә иде. Нишләп мин аны күрмәгәнмен әле?

Менә ул сине култыклап алды, нинди чибәр хатынны эләктердем бит дигән сыман, горур гына басып, алдагы рәтләрнең берсендә сиңа урын тәкъдим итте һәм... ут сүнде. Экранда ниндидер сурәтләр барлыкка килә, кемнәрдер нәрсә хакындадыр сөйләшәләр, бәхәсләшәләр, тиргәшәләр, сугышалар... Ә мин аңламыйм. Нәрсә соң бу? Лена, кем белән син? Аңладым, якында гына берәү күршесенең колагына иелеп пышылдады:

— Лена кияүгә чыккан.

Әйе, ул кияүгә чыккан. Табигый. Минем аңа бернинди дәгъвам юк, ул шулай булырга тиеш. Ниһаять, бервакыт хәл үзгәрергә, төгәлләнергә тиеш ич! Бары шул гына, бик примитив дәрәҗәдәге табигый хәл. Ә ник син шушы хәтле югалып калдың? Сиңа нәрсә?

Кино бетте, кешеләр кузгала, мин дә ниндидер инстинкт белән кузгалып киттем. Төнге караңгы урамнан ялгызым гына барам. Япа-ялгыз... Менә шушы минутта инде мин чынлап та ялгыз... Кап-караңгы...

Мине үзебезнең авыл кешеләре утыртып кайттылар. Нәрсәдер әйтәләр — ишетмим. Эндәшеп-эндәшеп җавап ишетмәгәч, кул селтәделәр бугай, бөтенләй сүз кушмас булдылар. Үзара юл буе гәпләшеп, бәхәсләшеп, көлешеп, тиргәшеп кайттылар. Сүзләре колакка кермәде. Үз хәлемне соңыннан тикшереп карагач, мин тагын бер ачыш ясадым: күңелең белән аерылышырга һәр минут әзер торсаң да, яратмасаң да, һичнәрсә дәгъва итмәсәң дә, үзең белән бәйләнештәге кешеңнән аерылу – барыбер фаҗига, син аны барыбер көнлисең... Үзеңә кирәк түгел, ә читләргә бирәсең килми. Кеше күңеле бөтен дөньяны кочарга омтыла, һәрвакыт шулай, һәркем шундый. Сынап карагыз, әгәр ышанмасагыз. Уйлап карагыз. Кешегә бервакытта да җитеп туктамый...

Тора-бара үзем өчен бер нәрсәне ачыкладым: әйтерсең, мин озак кына вакыт авырып яткан һәм хәзер терелеп урамга чыкканмын. Югалтулар ачысыннан һәм ихтыярымны бәйләп торган, ярыйсы ук азгын мәхәббәттән терелеп чыгуым иде бу. Авылны, үз хәлемне шунда үз төсендә күрә алдым.

Сугыш дәвам итә. Сафуан абзыйлар гомерләрен дә кызганмый, ә син? Дезертирмы? Хакың юк бу көрәштән читләшергә. Сафуан абзый юк, бер кеше кимеде. Буш урынны кем алырга тиеш? Үз хакыңда гына кайгыртырга хакың юк. Сафуан абзыең, Килмитов, үзе өчен үлмәде. Хакың юк!

Йөгән тоттым да иртән иртүк атлар утарына кердем. Миңа «Гани аты» дигән кара-туры атны бирделәр. Тояклары чабата кебек җәелгән, яндырганнар. Яхшы ат идең шул син, дус, начар ат янмый ул. Кешеләр дә шулай... Әйдә яңадан яши башлыйбыз, безгә үзебезнең нәрсәгәдер сәләтле икәнебезне күрсәтергә кирәк хәзер.

КЫРЫМ ТАТАРЛАРЫНА БЕР ӘЛӘК

Украина Компартиясе беренче секретаре Николай Подгорныйга Кырым партия өлкә комитеты беренче секретаре Василий Комяховтан доклад язмасы

Симферополь, 1958 елның 25 августы.

Партиянең Кырым өлкә комитеты Украина КП Үзәк Комитетына соңгы вакытта кырымтатар чыгышлы кайбер затлар һәм төркемнәрнең милли эшчәнлеге көчәя башлавы турында хәбәр итү зарур, дип саный. Әйтик, УССР МС каршындагы Дәүләт Иминлеге Комитеты (КГБ) идарәсе мәгълүматлары буенча, Ташкент шәһәрендә рәсми булмаган «инициатив төркем» оешкан, ул кырымтатар халкының үз ватаннарына кире кайтарылуын дәгъвалый, шул максаттан депортацияләнүчеләрдә Хөкүмәтнең Кырым буенча карарына ризасызлык тудыру һәм «петиция» астына имзалар җыю буенча актив эшчәнлек алып бара.

Әлеге эшчәнлек нәтиҗәсендә 1957-1958 елларда Кырым өлкәсенә шактый кырымтатар килеп киткән һәм элек үзләренеке булган йорт-корылмаларны карап йөргән, тиздән кире әйләнеп кайтачакларын белдергән. Аларның кайберләре, ялган документлардан файдаланып, Кырым өлкәсендә яшәп калырга да маташкан, әмма милиция органнары тарафыннан кабат куып җибәрелгән.

«Инициатив төркем» эшчәнлегенең активлашуын түбәндәге фактлар раслый.

Быел июнь аенда Ташкенттан Кырымга Кадиева кайткан, Симферопольдә ул биредә яшәү рөхсәт ителгән абыйсы Мамут Гаффар улы Умәровта тукталган. Ачыклanганча, Кадиева татарларның Кырымнан куылуына канәгатьсезлеген белдергән һәм Үзбәкстанда кырымтатарларны кире ватаннарына кайтару буенча зур эш башкарылуын хәбәр иткән. Әлеге эшне җитәкләгән «инициатив төркем» составына кырымтатар интеллигенциясе дә керә икән.

Кадиева әйтүенчә, Ташкентта кырымтатар язучылары студент татар яшьләре белән очрашкан һәм аларны Кырымга кайтуны дәгъвалау эшчәнлеген көчәйтүгә өндәгән, шуннан соң студентлар «петиция» астына имзалар җыюга актив кушылган. Үзбәкстанда һәм Советлар Берлегенең башка төбәкләрендә яшәүче кырымтатар халкы «инициатив төркем»нең Кырымны кире кайтаруны дәгъвалап Мәскәүгә һәм башка шәһәрләргә йөрүләре өчен акча җыя икән.

Вәлиулла Мортазаев.

Әшрәф Шәмьи-Задә.



Шамил Аләдинов.

Шул ук Кадиева әйтүенчә, «инициатив төркем» эшчәнлеген инде озак вакыт буе Мәскәүдә мәрхүм татар язучысы Ыргат Кадыйровның тол хатыны өендә яшәүче кырымтатар хатыны көйләп тора. Төркемдә катнашучыларның кайберләре Кырым өлкәсендә яшәүче танышлары белән хат языша һәм әледән-әле алар янына кайтып йөри.

Мәсәлән, «инициатив төркем» составына керүчеләрдән берсе, Сәмәрканд педучилищесында тарих укытучы Вәлиулла Мостафа улы Мортазаев югары инстанцияләр рөхсәте белән Симферопольдә яшәүче Фатыйма Сәфәр кызы Нигъмәтуллаева, Николай Бражников һәм башкалар белән язышкан хатларында «инициатив төркем» казанышларын мактый, татарларның Кырымнан куылуын исә хөкүмәт тарафыннан кылынган «законсызлык» дип бәяли. 1957 елның июлендә Мортазаев Симферопольдә Нигъмәтуллаева белән очраша һәм аны төркемнең эшчәнлеге белән таныштыра.

Мортазаев Кырымнан киткәннән соң Нигъмәтуллаевага: «Мин безнең делегациягә тәвәккәлрәк булырга киңәш итәр идем – көннәрдән бер көнне кырымтатарлар бернинди санкцияләрсез барысы бергә Кырымга әйләнеп кайтырлык булсын. Мин бернәрсәдән дә курыкмыйм, безнең интегүләребез турында 50 данә листовка язып, аларны Мәскәү урамнарына элеп чыга алам. Татарларга автономия дәгъваларга кирәк», – дип белдергән.

1958 елның июль башында Кырымга үз автомашинасында отставкадагы подполковник, КПСС әгъзасы, Мәскәүдә Энтузиастлар бульварындагы 9 нчы йортта яшәүче кырымтатар Сөләйман Әсәнов килгән һәм җитештерүдәге эшен ташлавы, гомерен «үз халкына», милләттәшләрен ватаннарына кайтару эшчәнлегенә багышларга теләве турында белдергән. Ул якын арада «татар мәсьәләсе» уңай хәл ителер дип ышана. Аның кулындагы өч зур папкада «инициатив төркем»нең татар халкын Кырым өлкәсенә кире кайтару буенча хөкүмәткә мөрәҗәгатьләре тупланган.

Әсәнов әйтүенчә, «инициатив төркем» Ватан сугышы чорында Кырымда немец-фашист гаскәрләре атып үтергән кырымтатарларның тулы исемлеген төзегән һәм «Кырым өчен гомерләрен биргән» патриот милләттәшләре ярдәмендә хөкүмәткә бөтен бер халыкны гаепләүнең нигезсезлеген дәлилләмәкче була.

Әсәновны тиз арада Кырымнан җибәрү өчен чаралар күрелде.

Быел июньдә Язучылар берлегенең ял йортына Ташкенттан кырымтатар язучылар Шамил Сәед улы Аләдинов һәм Әшрәф Шәмьи-Задә килеп төшкән. Аларның беренчесе «инициатив төркем»дә актив катнашучыларның берсе булып тора. Алар үзләренең ялын өлкә китапханәсенә, дәүләт музеена һәм Бакчасарайдагы Хан сарае музеена барып, аларда сакланып калган һәм Кырымның борынгы татар җире булуын дәлилли торган тарихи архив материалларын эзләп табуга багышларга ниятли. Аләдинов әйтүенчә, әлеге материаллар аларга «инде өч ел буе алып барган уртак эшләре» өчен кирәк икән. Кырымтатар халкының күпчелеге тупланган Үзбәкстанда хәл киеренке, барысы да түземсезләнеп кире үз ватаннарына кайтуны көтә. Моңа ирешә калсалар, алар, автономия төзеп, Кырымдагы дәүләт органнарын үз кулына алырга җыена, руслар партия органнарында гына калырга тиеш, дип саный.

Аләдиновның Үзбәкстан Язучылар берлеге идарәсе язган хаты да бар иде: әлеге республикада якын арада кырымтатар әдәбияты һәм сәнгате декадасы үткәрү планлаштырыла, шунлыктан милләттәшләре турында Кырымда басылган нәфис әдәбият белән танышу зарур. Сөйләшү барышында Аләдинов Кырымнан куылган татар халкының бик зур фаҗига кичерүен шәхес культына бәйләп аңлата; Үзбәкстанда яшәү дәверендә кырымтатар халкының тормышта үзен гел уңай яктан гына күрсәтүе һәм хөрмәт яулавы хакында горурланып сөйли; кырымтатар язучыларына Үзбәкстандагы җитәкче оешмаларның хәерхаһ булуын әйтергә дә онытмый.

Моннан Аләдиновның үз шәхси фикерен генә әйтмичә, гомумән, кырымтатар интеллигенциясе караш һәм омтылышларын белдергәндер дип нәтиҗә ясарга була, алар үзләренең Кырымга кабат әйләнеп кайту теләгенең җәмәгатьчелектә дә яклау табуына өметләнә.

Икенче вәкил – Шәмьи-Задә: «Мин Кырымга кайту турында Үзбәкстандагы бер кырымтатар белән сөйләшкән идем. Ул миңа, әгәр кайтырга рөхсәт итсәләр, һичшиксез, үз йортын эзләп табачагын һәм шунда кабат үзе хуҗа булачагын әйтте. Һәм мондый теләк биредәге кырымтатарларның күпчелегенә хас», – дип белдерә.

Аләдинов һәм Шәмьи-Задәнең эшчәнлеген чикләү, ә ял вакыты тәмамлангач, тиз арада Кырым өлкәсеннән җибәрү өчен чаралар күрелде.

Кырым татарлары үз мәнфәгатьләрен кайгыртуга ТАССРда яшәүче интеллигенциянең бер өлешен дә җәлеп итә.

Күптән түгел болгар-татар архитектурасы һәм гамәли сәнгатенә кагылышлы материалларны өйрәнү сылтавы белән Казаннан Кырымга ике архитектор килеп төште. Алардан берсе – Фуат Хәсән улы Вәлиев әйтүенчә, Татарстан республикасы кырымтатарларның юкка чыгу янаган мәдәниятен коткару эшенә керешкән. Шул җәһәттән ул Бакчасарайдагы, Куйбышев һәм Иске-Кырым районнарындагы һәм, гомумән, Кырым өлкәсендә булган бөтен татар ядкәрләрен теркәү белән шөгыльләнәчәк. Бу эш күп көч таләп иткәнгә, аны 1958 һәм 1959 елларда да дәвам иттерергә туры киләчәк. Вәлиев әйтүенчә, кырымтатарларга кагылышлы мәсьәләләрдә ул Мәскәү тарих музее гыйльми хезмәткәре иптәш Смирнов белән киңәшеп эшли.

1958 елның 15 августында Казаннан Бакчасарайга пединститутның гарәп теле укытучысы Зәйнәб Габделҗәмил кызы Максудова килгән, ул кырымтатарлар турында нәфис әдәбият һәм язма документлар эзләгән – 1958 елның октябрендә Ташкентта үтәчәк Азия һәм Африка язучылары съездында кырымтатарлар да катнашырга әзерләнә һәм әлеге чыгышларны дәлилләү өчен әдәби әсәрләр дә күрсәтелергә тиеш икән.

Үзбәкстан язучылар оешмасы составында кырымтатар әдәбияты секциясе булу безгә гайре табигый тоела, аның әгъзалары һәм бигрәк тә җитәкчесе Аләдинов татар халкын Кырым өлкәсенә кайтару өчен «инициатив төркем»дә актив эшчәнлек алып бара.

Боларны хәбәр итеп, Украина Коммунистлар партиясенең Кырым өлкә комитеты Үзбәкстанда кырымтатарларның «инициатив төркеме» эшчәнлеген туктату буенча кирәкле чаралар күрүне, шулай ук Азия һәм Африка язучылары съездында кырымтатар интеллигенциясен чыгыш ясатмауны үтенә.

(Украина Үзәк Дәүләт архивы. - Ф. 1. - Ис. 24. - Бел. 4740. – Бит. 73-80.)

Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА
тәрҗемәсе.

Киндердәге чәчәкләр

Рәссам Миләүшә Нуруллина иҗаты чәчәкләрдән аерылгысыз. «Чәчәкләр гомере – ул кеше гомере чагылышына тиң. Чәчәкләр аша кеше тормышының этапларын күрсәтеп тә була. Аларның да бөреләнү, чәчәк ату чоры һәм сулу вакытлары бар бит!» – ди ул.

Миля (Миләүшәне иҗат дөньясында шушы исем белән беләләр) Нуруллина – күренекле язучы Вакыйф Нуруллинның кызы. «Әти-әнием исән-сау, мин бик бәхетле!» – диде Миләүшә ханым әңгәмә башында. Алдагы елларда да шулай булсын, иншаллаһ!

Булачак рәссам 1961 елның 18 мартында туган. Әти-әнисе кызларын Казан университетында укып, соңрак журналист һөнәрендә булыр дип күзалласа да, ул башка юлны сайлаган: Казан инженерлык-төзелеш институтын тәмамлаган. Моңа, бәлкем, балачакта Казанның 1 нче балалар сынлы сәнгать мәктәбендә белем алуы да тәэсир иткәндер... Яшь белгеч буларак үз һөнәре буенча эшкә билгеләнгәч, ул проектлау контораларында 10 ел хезмәт куйган. 1990 еллар кемнең генә язмышын үзгәртмәгәндер, менә Миләүшә дә, эшләгән оешмасы ябылу сәбәпле, 1992 елда Казанның Яшь тамашачылар театрында реклама буенча рәссам булып эшкә урнаша. «Анда очраклы рәвештә генә эшли башласам да, нәкъ менә театрда чакта чын иҗатка кереп киттем дә инде, – дип искә ала әңгәмәдәшем. – Һәр театрның күтәрелеш чоры була. Мин дә шушы елларга эләктем. Театрдагы унай мохит, янәшәмдәге иҗатчылар, дус коллектив, зур остаханә булу, буяулар муллыгы... барысы да картиналар ясауга этәрде. Ничек итеп иҗатка кереп киткәнемне дә сизми калдым! Аннары эшкә бару сәгатьләрен дә көйләп була иде. Әгәр дә рәссам төнлә ясарга теләсә, аңа беркем бер сүз дә әйтмәде. Рәхим ит, тулы бер цех синең карамакта! Дөрес, мин башта катыргыга майлы буяулар белән ясадым. Шунысы да бар: иҗатка 32 яшемдә, инде төпле фикерле кеше буларак килдем. Рәссамлыкка һәркем укый ала, әмма иҗатка үз дөньяви карашларын формалашкач кына килергә мөмкин дип саныйм. Башкаларга иҗаттагы үз йөзеңне, үз юлыңны күрсәтә алачагыңа ышангач кына...»

– Сез иҗат башында ук импрессионизм юнәлешен сайлап алгансыз...

– Чыннан да, беренче әсәрләремне үк импрессионизм жанрында иҗат итә башладым. Минем өчен Ван Гог, Клод Моне иҗаты да кызыклы тоела иде. Алар бит күренешләр охшашлыгына омтылмаган, ә аларның үзләренә нинди тәэсир калдыруын тотып алырга ашыккан. Ә мондый картиналар өчен бик тиз, төгәл итеп башкару таләп ителә... Минем өчен Н.И.Фешинның даһилеге дә бәхәссез! Аның беркем дә кабатлый алмас энергетикасы, үз ясау рәвеше бар!

Җитди сәнгатькә килгәч, мин музейларга барып, Б.Урманче, Г.Рахманкулова әсәрләрен дә өйрәндем. Ул елларда йөгерек интернет юк иде бит әле. Уку йортларында академик сәнгатькә өстенлек бирелә, анда көне-төне импрессионизм рухында ясарга өйрәтелми. Шунлыктан әлеге сәнгати юнәлеш күпләр өчен теория буларак кына истә кала. Рәссам сурәтне фотога ошатып ясарга тиеш түгел, ул табигать күренешен үзенчә үзгәртә ала, әмма бу үзгәртү башкалар күңеленә барып ирешә алса, тере булса гына уңышка китерә. Аннары рәссам тамашачысыз була алмый. Мин дә иң беренче шәхси күргәзмәмә җитәрлек картиналар туплагач та, аларны 1993 елның февралендә М.Горький дәүләт музеенда тамашачылар игътибарына тәкъдим иттем. Ни сөенеч, әсәрләремне тамашачылар да, сәнгать белгечләре дә җылы кабул итте. Иҗат юлым җайлы башланды, дия алам. Һөнәри рәссамнар да мине мактадылар гына. Шуңа икенче шәхси күргәзмәмне 1998 елны «Казан» милли-мәдәни үзәгендә ачтым. Ул вакытта күргәзмәгә ризалыкны тулы бер комиссия, башка рәссамнар бирә иде әле... Мин Татарстан Рәссамнар берлегенә 1997 елда ук кабул ителдем.

– Сез һәрчак чәчәкләр ясауда булдыгызмы? Кайсы әсәрегез аеруча да уңыш казанды дип саныйсыз?

– Юк, иҗат башында мин беraз абстракция юнәлеше белән дә мавыгып алдым. Ләкин бу юлдан ары китмәдем. Чыннан да, чәчәкләр ясауга өстенлек бирдем. Аларны Аллаһ Тәгаләнең кешеләргә биргән бүләге дип кабул итәм, шуңа күрә дә киндерләрдә еш сурәтлим. Кемдер: «Чәчәкләр – алар Җир елмаюы», – дигән. Минемчә, илһам шушы дөньяның матурлыгын күрү бәхетеннән килә. Безгә шушындый ямьле дөньяны күрү бәхете тигән бит!

Рәссамнар үзләре иҗат иткән бар әсәрен дә ярата ул. Тик һәммәсен төрле дәрәҗәдә. Кайбер картиналарның язмышы бик уңышлы дәвам итәргә мөмкин, мәсәлән, «Яңгыр астындагы настурцияләр» картинамны башкалар да ошатты. Әлеге әсәрдәге төсле тапларның үзара уңышлы бәйләнеше, гомуми мозаикасы кешеләр күңеленә бер үк вакытта куаныч та, моңсулык та өсти төсле. Бу картина минем тарафтан бихисап мәртәбә язылса да, сәнгать сөючеләр аңа һәрчак мөкиббән. Гадәттә, яңа күргәзмә алдыннан – «Яңгыр астындагы настурцияләр»нең берсен, күргәзмә барышында – икенчесен, соңрак калганнарын да сатып алалар. Һәрчак шулай кабатлана.

Күпләр чәчәкләрнең чәчәк ату чорын язарга ярата. Ә мин аларның шиңә барган мәлләрен дә теләп сурәтлим. Менә Ван Гог та бит көнбагышларның шундый чакларын тасвирлаган... Киндердәге чәчәкләрем барысы да төрле. Аларны ясаганда, төрледән-төрле төсләр кулланып була. Ә төсләр – сүзсез көйләр. Төсләр һәрчак кешегә тәэсирле. Кеше иртән торгач, үзенә ни өчендер нәкъ менә берәр төсткә кием сайлый, йә ул алсу күлмәк кия, йә сары, йә кара... Чөнки кешедә кайбер төскә карата чын ачлык хисе туа. Арт-терапия дә төсләр белән дәвалануга корылган. Без бит мәгълүматның иң күп өлешен күзләребез белән кабул итәбез. Менә минем осталык дәресләремә килүчеләрнең дә һәркайсы үзе өчен якын төсләрне генә сайлый. Моны хуплыйм гына.

– Дәресләрегез Казандагы иң беренче осталык дәресләре булган икән...

– Нәкъ шулай! Әүвәл картиналарымны сатып кына алдылар. Аннары сатып алучы ханымнарның үзләренең дә берәр нинди картина ясап карыйсылары килә башлады. Алар миңа шундый үтенечләрен әйткәч, җөрьәт иттем. Картина ясау өчен мөһим кирәк-яракны җыйдым да, 2004 елда беренче осталык дәресемне бирдем. Шуннан бары да яхшыга таба үзгәрде. Картина ясап карарга теләүче туташ-ханымнар саны көннән-көн арта гына барды. Дәресләремне әле дә дәвам итәм. Укучыларым ясаган чәчәкләр төрле, бу төр сурәттә сюжет булу мөһим дә түгел.

Мин – колорист. Аннары башкаларга аңлаешлы итеп сөйли дә алам. Бу талантым, мөгаен, әтиемнән күчкәндер... Осталык дәресләрен ул елларда Казанда әле беркем дә үткәрми иде. Смартфоннар да юк чак. Аларны беренче булып мин башлап җибәрдем. Үзем белгәннәрне башкалар белән уртаклашу теләге уема очраклы рәвештә генә килде дисәм дә дөрес булыр. 2004 елларда ук кешеләр үзләрен нинди дә булса башка өлкәдә сынап карарга тели башлады: берәүнең җырларга, икенчесенең биергә, ә кемнеңдер рәсем ясарга өйрәнәсе килде. Үземнең дә җыр сәнгатенә төшенү өчен осталык дәресләре алганым булды. Сынлы сәнгатькә, гадәттә, эшлекле, актив

ханымнар тартыла. Хуҗабикә булганнарның моңа вакыты юк. Укучыларымның күбесе: «Балачакта рәсем ясарга өйрәнәсем килгән иде, ләкин...» дип сүз башлый. Һәркемнең теләге булган, әмма һәркайсы өчен нинди дә булса каршылык туган... йә мәктәп бик еракта булган, йә аларны башка түгәрәккә йөрткәннәр... Казанда да бит балалар өчен биш кенә сынлы сәнгать мәктәбе эшләде.

Мин осталык дәресләремне дәүләт музейларында гына үткәрдем. Алар төрле елларда Татарстанның дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Милли музейдә, «Хәзинә»дә дә уңыш белән барды. Менә 2020 елдан башлап аларны Г.Тукай музеенда алып барам. Мин бар музейларыбыз җитәкчеләренә һәм андагы хезмәткәрләргә бик рәхмәтле. Осталык дәресләремне алар да шатланып кабул итте, дәресләр өчен уңай шартлар тудырдылар. Гомумән, музей хезмәткәрләре – бу дөньяда иң мөлаем, зыялы һәм һәрчак булышырга әзер шәхесләр. Алар безнең нәрсәләр ясавыбыз белән һәрвакыт кызыксынды, үз фикерләрен җиткерде, мактадылар да... Күбесе безнең белән бергә рәсемнәр дә ясый башлады. Бу бүген дә шулай дәвам итә!

2006 елда мәскәүле бер психолог ханым, осталык дәресләремне бик ошатып, аларны яңалыкка тиңләп, башкалага чакырган иде. 2007-2013 елларда, аена бер тапкыр Мәскәүгә барып та белем бирдем. Мәскәүдә дә бит осталык дәресләре тиз генә башланып китмәдә. Ә аннары инде алар һәр почмакта диярлек ачылды.

– Кешенең рәсем ясауга сәләте әллә ни юк очракта да, ул үз тырышлыгы бәрабәренә яхшы рәссам булып танылa ала дип саныйсызмы?

– Иҗат үзенә тарту көченә ия. Сигез йөздән артык картина язган француз рәссамы Вильям Бугро да бит: «Мин һәркөн шатлык тулы үз студиямә барам, кич белән, караңгы төшеп, туктап торырга мәҗбүр булгач, мин иҗатымны дәвам итәр өчен иртәгәсе көнне көч-хәл белән көтеп алам», дип язган... Мәшһүрлекне төрлечә кабул итеп була: тарихта күп рәссамнар иҗат иткән, әмма аларның һәрберсенең дә исеме – тарихта, ә картиналары музейларда сакланып калмаган. Төпле академик белем алучыларның кайберләре, мәсәлән, үз әсәрләрен шактый дәрәҗәдә гадиләштереп, әмма үз йөзен табып, иҗат итә. Алар да үз юнәлешләрен, үзенчәлекле сәнгати телне таба алулары белән мәшһүр. Алар син моңа кадәр ирешә алмаган нота югарылыгын ала алган, димәк. Шундыйлар да бар: алары чит иҗатчы җилкәсендә булып, атаклы картиналарны бозып, әйтик, мәгълүм образның йөзе урынына песи яки эт йөзе ясап куеп, халык арасында мәшһүрлек казана, андыйларны да истә калдыралар... Болар инде – эшмәкәрлекне яхшы белүчеләр. Хәзер күп хезмәт куючы яхшы рәссам булып танылу өчен кайберәүләр (шул исәптән һөнәри рәссамнар да), күчермә ясау үзәкләренә барып, киндерләргә кеше фотосыннан күчермә генә бастыра да, шул киндер өстен майлы буяулар белән сыпырып, майлап кына чыга. Бу, билгеле, кемнеңдер тырышлыгы белән чагыштырырлык гамәл түгел. Кыскасы, данга омтылу күп иҗат кешесенә хас, тик чын иҗатчы шөһрәт хакында уйлап та утырмый, ул бары тик үз стилен табу хакында фикерли. Тапталган сукмактан бармаган тырыш, чыннан да, танылa ала.

– Осталык дәресләренең төп нәтиҗәсе нәрсәдә?

– Алар аша кешенең үз-үзенә бәяләмәсе арта. Ул үзендәге башка төр сәләтне ача. Мәсәлән, диварга бернечә картинасын элеп куйган ханымнар җәмәгатенең, балаларының аларны бары мактаулары, сәләтләре белән горурланулары хакында искәртә. «Гаилә атмосферабыз уңай якка үзгәрде», – диләр. «Без сәнгатьтәге гармониягә тартылдык, үз-үзебез хакындагы фикерләребезнең яхшы якка үзгәрүен тойдык», – дип тә сөенәләр. Бу шулай ук тәсләрнең, иҗат шатлыгының уңай йогынтысы. Аллаһ Тәгалә миңа насыйп иткән йөкләмәмне таптым һәм аны тиешенчә итеп үтим дип саныйм. Ихлас күңелдән әйтелгән рәхмәтләрне ишетүемне бәхеткә тиңлим! Ә бит баштарак үз иҗатым барыннан да мөһимрәк дип саныйм идем. Бу алай түгел. Белем бирү шатлыгы кешене тулырак бәхеткә илтә. Шушы эшчәнлегемне үз иҗатыма карaганда да өстен куям, чөнки шушы эшчәнлегем аша башкаларга күбрәк файда китерүемне аңлыйм. Бүгенге дөньям менә шундый!

– Белем бирү дигәннән, бу илларда балаларга тәрбия бирү эше күбрәк мәктәпләрдә алып барылырга тиеш, дигән фикер алга сөрелә. Сез дә – ике ир бала әнисе, бу сезнеңчә дә шулаймы?

– Мин мондый фикер белән тулысынча ук килешмәс идем. Мәсәлән, әнием Назәхәт Нуруллина Актаныш районының Такталачык авылында туып үскән. Ул гомер буе Татарстанның Милли китапханәсендә эшләде, китапханәчедән алып комплектлаштыру бүлеге җитәкчесенә кадәр күтәрелде. Ул минем күбрәк белемле булуымны теләп, тулы бер исемлек төзи иде. Әниемә рәхмәт яусын, шул исемлек буенча мин күпме җитди әдәби әсәрләр белән таныштым! Әнием мине китаплардан өзмәде. Аннан үрнәк алып, мин дә үз улларыбызга китап ташыдым, алар да зыялы инсаннар булып үсте. Шуңа күрә башкаларга да балаларының игътибарын дөньяви әһәмияткә ия китапларга юнәлтүләрен теләп калам!

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

Нәзарәт китапханәсе байый

2013 елдан бирле Татарстан мөселманнар Диния нәзарәте тарафыннан гамәлгә ашырыла торган Darul-Kutub.com электрон китапханәсенең фонды 2022 елда шактый баеды – күпчелеге 1913 елга кадәр Казанда, Оренбургка, Уфада нәшер ителгән 249 иске хезмәт, сканер аша уздырылып, китапханә сайтына урнаштырылды. Шулай итеп, бүгенге көндә Darul-Kutub.com электрон китапханәсе 1471 исемдәге борынгы китапны (1826 томга якын) үз эченә ала, алар арасында татар галимнәре һәм дин әһелләренең инкыйлабка кадәрге классик хезмәтләре дә бар.

Сайтта сирәк, моңа кадәр очрамаган басмалар урнаштырылган. Аларның 80% – иске татар телендә. Китаплар арасында тәфсирләр, хәдис җыентыклары, әхлак, ислам нигезләре буенча басмалар бар. Шулай ук сайтка 20 нче гасыр башында чыккан «Ислам мәҗәлләсе» һәм «Дин һәм мәгыйшәт» журналлары җыентыклары куелган. «Ислам мәҗәлләсе» журналында шул вакытта яшәгән татар мөселманнарына кызыклы булган темаларны чагылдырган язмалар урын алган.

Борынгы китаплар Татарстан Фәннәр академиясенең Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтыннан, Казанның Ислам кабул итүгә 1000-еллык исемендәге мәдрәсәсе китапханәсеннән, «Ярдәм – Помощь» гомуммилли хәйрия фондыннан, шулай ук шәхси коллекцияләрдән килеп ирешкән. Darul-Kutub.com проекты, Диния нәзарәтенең «Хозур» нәшрият йорты көче белән татар дини мирасын саклау һәм аны өйрәнү, радикаль идеологияләргә мәгълүмати яктан каршы тору, шулай ук мөселманнарны Хәнәфи мәзһәбенең абруйлы чыганаклары белән тәэмин итү максатыннан актив үстерелә. Сайт кыйммәтле хезмәтләрне табып укырга һәм бушлай йөкләп күчереп алырга мөмкинлек бирә. Сайтның бизәлеше барлык шәхси компьютерлар, смартфоннар һәм планшетлар өчен җайлаштырылган. Электрон китапханәдәге хезмәтләрне авторлар, китап исеме һәм категорияләре буенча эзләп була.

КАФЕДРА – илһам чыганагы

Татар телен гамәлгә кертүдә, әдәбиятыбызны үстерүдә 1925 елда Казан Көнчыгыш педагогика институтында татар теле һәм әдәбияты кафедрасының оештырылуы да зур этәргеч ясады. Без бу очракта кафедра эшчәнлегенең бер генә юнәлешен – аның яшьләрдәге иҗади омтылышка юл ачу гамәлләрен, 85 ел буена бу хәрәкәттә халкыбызның рухи дөньясы илһам чыганагы булуын күрсәтергә телибез.

Әлеге изге юл башында күренекле галимнәр Г.Сәгъди, Җ.Вәлиди, Г.Рәхим, Г.Шәрәф, Н.Мөхетдинов, бераз соңрак Г.Нигъмәти һ.б. тора. Беренче айлардан ук алар татар бүлегендә иҗади мохит булдыруны максат итә. Бу яктан Гали Рәхим аеруча тырышлык күрсәтә. Әдәби түгәрәк оештырып, күбесе авылдан килгән егет һәм кызларның иҗат эшенә тартылуын тәэмин итәргә тырыша. 1926-1929 елларда татар бүлеге иҗтимагый-сәяси һәм әдәби журнал да чыгара. Ул «Яшь педагог» дип атала. Басмада Г.Кутуй, Г.Кашшаф, Ә.Еники, Ф.Даутов, М.Богданова, М.Кашафетдинова үз әсәрләрен бастыра. 1928-1929 уку елында, мәсәлән, биредәге фәнни-әдәби түгәрәктә иллегә якын студент шөгыльләнә. 1926-1927 уку елында институтта Һ.Такташ, Г.Бакир белем ала. Такташ кулларына иҗат каләме алган яшьләр белән очраша, Г.Кутуй да әлеге түгәрәктә бик еш чыгыш ясый.

Әмма утызынчы елларның икенче яртысында, репрессияләр көчәйгәч иҗади мохит әкренләп юкка чыга. Аннары сугыш еллары. Ниһаять, илленче еллар башында биредә иҗат эшләре яңадан тернәкләнә. Алдымда 1954 елда педагогика институтының татар әдәбият-иҗат түгәрәгендә катнашучылар чыгарган кулъязма альманах – «Яшьлек тавышы». Аның тышына №5 дип куелган. Димәк, әле монысына кадәр дүрт сан чыккан. Бәлки, алтынчысы, җиденчесе дә булгандыр. Әмма табылганы бердәнбер. Ул уку йортының татар теле һәм әдәбияты кабинетында сакланган. Укырга теләгән кешегә аны, китапханәдәге кебек, формуляр белән биргәннәр. Шушы нөсхәнең битләре арасында бер формуляр да сакланган. Ул «Яшьлек тавышы»ның 3нче санының. Аннан күренгәнчә, бу сан 1951 елда чыккан булган. Аны шушы кабинеттан 1952 елның 26 октябрендә, укырга дип, икенче курс студенты Илдар Юзеев алган. Формулярда Илдар абыйның бик тә таныш имзасы бар. Күрәсең, ул да иҗат түгәрәге эше белән кызыксына башлаган.

Аның каруы, өченче сан белән бишенчесе арасында без И. Юзеевнең шагыйрь буларак шактый таныла башлавын күрәбез. Байтак шигырьләр белән бергәттән, шушы ике-өч елда ул инде «Тормыш җиңә» дигән поэма да язып өлгергән. Аны «Яшь сталинчы» газетасының 1953 елдагы 132, 134, 135 нче саннарында һәм «Үсү юлы» альманахының 6 нчы санында бастырып чыгаруга да ирешкән. «Яшьлек тавышы» кулъязма альманахының без сүз алып бара торган санында исә поэмага карата Марс Шабаевның бәяләмәсе урнаштырылган. Ул шәриктәшенең әсәре турында үз итеп, яратып, шул ук вакытта таләпчәнлек күрсәтеп яза. Киләчәктә үзе дә шагыйрь булып китәчәк М.Шабаев И.Юзеевнең күренекле әлгәребез Һ.Такташ шигъри мәктәбенең дәвамчысы икәнлеген дә әйтә. М.Шабаевның шигъри сиземләве көчле булган икән, чыннан да, И. Юзеев иҗатында такташчалык нык сизелә торды.

«Тормыш җиңә» әсәре, кинәт авырып китеп, хастаханәгә юлыккан студент егет Равилнең уй-хисләрен бирү белән башлана.

●Педагогика институның татар әдәбияты кафедрасы укытучыларыннан бер төркем. 1987 ел.

Институт!
Синнән аерылуга
Ике көн дә әле булмады,
Сагындым да сине...
Күңелемне
Әллә нинди уйлар чорнады.
Сагындым мин
Якын дусларымны,
Институт, якты залларыңа
Кайчан кайтырмын соң
Тагын мин?

Бу шигъри юллардан үзе укый торган институтның яшь кеше тормышында нинди мөһим урын тотуын күрәбез. Альманахта катнашучыларның һәммәсе өчен уртак хис, уртак уйлар. Әлеге язмалардан без Казан педагогика институтының әдәби иҗат юлына аяк басучы яшьләр өчен ул унъеллыкларда никадәр кирәкле һәм кадерле уку йорты булганлыгын аңлыйбыз.

Марс Шабаев биредә үзе дә шигырьләр белән катнаша. «Шаян күзләр» дип исемләнгәне башлап язучы өчен шактый уңышлы тоела. Егет очраклы гына күренеп калган бер кызга гашыйк була. Шуннан соңгы көннәре аны очратырга теләп уза. Ниһаять, очрата, кыюлыгы җитеп, таныша да. Әмма бу очрашу аңа шатлык бирми.

Без таныштык.
Исеме – Халисә.
Гади генә итеп әйтеп куйды:
– Син булырсың «запас колесо»?!

Димәк, лирик герой теге кыз өчен яратышып йөри торган бишенче егет кенә булып чыга. Тегеләрнең берәрсе юлда төшеп калган очракта гына, «запас» булудан туктап, «төп тәгәрмәчләрнең» берсенә әверелүе мөмкин. Анда да дүртнең берсе булып кына. Әлбәттә, күңеле саф, матур идеаллар белән тулы кайсы яшь егетнең әнә шулай бишенче тәгәрмәч ролендә генә буласы килсен? Егет кеше бары тик беренче генә була ала. Ул нәтиҗә ясый:

Кыскасы шул:
Ул кемлеген ачты.
Сүз әйтергә аңа чиркәндем.
Телим, дуслар, кабат очрамавын
Шомырт кара күзле «иркәмнең».

Әлеге альманахта мондый яшьләргә хас табышлар тагын да очрап тора. Биредәге авторлар арасында С.Сафуанов, Х.Камалов, Ә.Заманов, Р.Шакиров, Г.Әнҗе, С.Поварисов, Р.Гарипов, Г.Мөхәммәтшинны күрәбез. Барысы да диярлек институтның татар теле һәм әдәбияты бүлеге студентлары. Үз иҗат җимешләре булган шигырьләрен, хикәя, очерк, мәкаләләрен урнаштырганнар. Арада «Төрле кешеләр» дигән пьеса да бар (Ә.Заманов әсәре). Сафуан Поварисов исә шигырьләре белән бергә А.Чеховның «Студентлар» дигән хикәясен дә тәрҗемә итеп биргән.

Күрәбез, бер үк елларда киләчәктә зур талантлар булып китәчәк күпме яшьләр укыган. С.Поварисов – фән докторы, Башкорт дәүләт университеты профессоры, классик әдибебез Г.Ибраһимовның тормыш юлын тасвирлауга багышланган трилогия иҗат итте; Х.Камалов – Татарстанның халык язучысы дәрәҗәсенә иреште, Ватан сугышы турында хакыйкатьне чагылдырган трилогия авторы булды; С.Сафуанов – әдәбият галиме, Башкорт педагогика институтында кафедра мөдире. Һәммәсе – сүз сәнгате, мәгариф, фән үсешенә зур өлеш керткән шәхесләр. Ә аннан соң бу эстафетаны Гөлшат Зәйнашева, Ләбиб Айтуганов, Роберт Әхмәтҗанов, Ренат Харис, Лена Шагыйрьҗан, Эльс Гаделов һ.б. дәвам итте.

Альманахның редколлегия составы да күрсәтелгән. Илленче еллар башында әдәби түгәрәктә җитәкчелек эшен кафедраның яшь укытучысы Мәдинә Җәләлиева башкара. Түгәрәккә «Яшь көч» дип исем дә бирәләр. Шул исемдәге дивар газетасы да булдырыла. Ул, биш-алты метр озынлыкта булып, ай саен чыгарыла. Анда урнаштырылган әдәби әсәрләр бизәлеше, эчтәлеге белән игътибарны җәлеп итә. Бигрәк тә сатира-юмор өлеше кызыклы. «Татарстан яшьләре» газетасының 1967 елгы 16 сентябрь санында, әлеге түгәрәккә багышлап, бер сәхифә биргәннәр. Аны М. Җәләлиеваның «Безнең түгәрәк» дигән мәкаләсе ача. Галимә иҗат коллективының үткәне, традицияләре, шул еллардагы эшчәнлеге белән таныштыра. Аннан соң алтмышынчы елларда укыган студентлар каләменнән төшкән әсәрләр тәкъдим ителә. Алар арасында Рафаэль Баяновның «Тукай шигырь укый», Нурулла Гаптуллинның «Рәйхан», Фәһим Миначевнең «Синең күзләрдән мин куркам...», Рәзит Сабитовның «Укытучыма» дигән әсәрләре бар.

1974 елда мин әлеге кафедрада укытучы булып эшли башладым. Беренче очрашуда ук остазым Мәдинә Шәйхи кызы әйтте:

– Мин әдәби түгәрәк эшен егерме еллап тартып килəм. Яңа сулыш кирәклеген сизәм. Әйдә, шушы эшне син алып кит әле...

Без, студентлар белән бергәләп, түгәрәкнең эшен колачлырак итеп оештырырга булдык. Иң әүвәл аны иҗат берләшмәсе дип атадык. Исемен дә «Илһам» дип үзгәрттек. Дивар газетабыз да шул исем белән атала башлады. Рафис Гыйззәтуллин, Зиннур Хөснетдинов, Марат Закиров кебек хәзер инде танылган язучылар нәкъ шул берләшмәдән үсеп чыкты.

2005 елда Казан педагогика университетына Татар гуманитар институтын куштылар. Ягъни, ике югары уку йортының берне ясадылар. Ул Татар гуманитар-педагогика университеты дип атала башлады. Ә гуманитар институтта «Дастан» исемле түгәрәк эшләп килгән икән. Әмма «Дастан» яңа шартларда яшәп китә алмады. Анда катнашучыларның байтагы «Илһам»га килеп кушылды. Миңа, ул вакыттагы татар әдәбияты кафедрасы мөдире буларак, әлеге талантлы яшьләрне бергә тупларлык җитәкче табарга кирәк иде. Ниһаять, аспирантлардан иҗатка омтылган, тынгысыз каләмле Рамил Ханнановны билгеләргә булдык. Ул, филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә алу өчен, диссертация яклады, кафедрада укытучы буларак та эшкә кереште. Бер үк вакытта «Илһам» иҗат берләшмәсенең эшен дә җанландырды. Ел саен «Илһамлы каләм» дигән иҗади конкурс оештырыла башлады. Анда, Татарстаннан тыш, башка республикалардан, өлкәләрдән дә өлкән сыйныф укучылары да катнашып китте. Апрель аенда аңа йомгак ясала, җиңүчеләргә бүләкләр тапшырыла, иң яхшы әсәрләрдән «Илһам канатында» дигән җыентык чыгарылу гамәлгә кертелде.

2010 елда чыкканына кереш сүзне Татарстанның беренче Президенты М.Ш.Шәймиев үзе язды. Һәрберебез үзе яшәгән чор өчен җаваплы. Иҗатта да шулай. Заманында Кол Гали, Мөхәммәдьяр, Г.Исхакый, Г.Ибраһимов, М.Җәлил, Ф.Кәримнәр булган. Алар үз чорларының бурычларын мөмкин булганча хәл иткән. Тарихта бөекләр булып калганнар. Әмма бүгенгене алар җырлый алмый, бу сезнең өлешкә төшә. Без, бүгенгене иҗат итеп, тарихны тудырабыз.

Фоат ГАЛИМУЛЛИН,
КФУ профессоры.

Тубыл шагыйрәсе

Татар әдәбияты кечкенә чишмә-инешләр, зур елгалар килеп кушылган диңгезне хәтерләтә. Әдәбиятның үсеш юлларын билгеләгән әдипләр мирасына үзешчән каләм әһелләренең иҗаты да кушылып, аны күпкырлы, бай һәм төрле итә. Соңгыларының халыкчанлык, гади язу стиле белән өретелгән әсәрләре теге яки бу төбәкнең төп әдәби мирасын формалаштыра һәм гомумтатар әдәбиятының уникаль, үзенчәлекле бер тармагы булып үсеп китә. Алар татар сүз сәнгатен шул төбәккә хас уникаль сыйфатларны чагылдырган әдәби үрнәкләр, үз төбәгенә хас образлы фикерләү хасияте белән баета.



Бу татарлар күпләп яшәгән чит төбәкләр өчен аеруча матур күренеш буларак бәяләнә. Мондый әсәрләр теге яки бу төбәккә хас проблемаларны күтәрә, шул җирлектәге халыкның көнкүрешен, яшәеш офыкларын, әйләнә-тирәгә мөнәсәбәтен, уй-хыялларын, менталитетын җиткерә. Моннан тыш үз яктагашларын гомумтатар сүз сәнгате белән бәйләп торуда да аларның роле, һичшиксез, зур. Күптән түгел кулыма кергән Себер төбәгенең үзешчән шагыйрәсе Фәхриҗамал Үтәшеваның китаплары да шушы яссылыкта бәяләнә ала.

«Очрашу» дип исемләнгән саллы җыентык авторның 1991 нче елдан бирле язылган шигырьләрен, публицистик язмаларын, истәлек-багышлауларын һәм хатларны берләштерә. Шигырьләренең язылу елы үзе үк авторның әдәбиятка милли күтәрелеш тәэсирендә килүе хакында сөйли. Әлеге күтәрелеш Тубыл районы Ләчек авылында туып-үсеп, күңеле һәрвакыт шигърияткә омтылган Фәхриҗамал Үтәшевага канатлар куя. Шушы чордан аның төбәктә татар телендә чыгып килүче «Яңарыш» газетасы белән даими иҗади элемтәләре башлана, шигырьләре газета битләрендә дөнья күрә, әкренләп алар җыентыкларга тупланып, укучыга барып ирешә тора, үзе актив җәмәгать эшлеклесе булып таныла.

Фәхриҗамал Үтәшеваның күп шигырьләре Себер татарларының язмышы, татар теле мәсьәләсе, Себер төбәге татар авылларының киләчәге кебек проблемалар тирәсенә туплана.

Сынса-сынган, өзелмәгән
Татарның бердәмлеге.
Буыннан буынга килгән
Ата-баба хөрлеге,

– дип язган шагыйрә Себер татарларының яшәеше өчен сызлана, татарларны бердәмлеккә өнди, хөрлекне, киләчәккә ышанычны югалтмаганда гына алга барырга мөмкин булуы турында сөйли. «Кыерсыткач туган телне / Абынабыз адым саен», дип, туган телдән читләшүнең сәбәпләрен эзли, яшьләрнең үз телләрен белмәве өчен борчыла, Себердәге татар авылларының бетүенә сыкрана. Аерым шигырьләрендә үзе өчен моның сәбәпләрен дә табарга омтыла, мисал өчен, «Каргалар» сатирик шигырендә аны бер-берсе белән мактанышa-мактаныша чәкәләшкән, һәркайсы үзенең өстенлеген раслаган ак һәм кара каргалар каршылыгы аркылы татарның бердәм булмавын аңлата.

Чапкан бире ят җәнлекләр
Артларына карамый.
«Ура» – диеп кычкырганнар
Бәла безгә янамый,

– дип, ул татарның үз эчендәге бәхәсләрнең яхшыга илтмәвен раслап куя.

Шагыйрәнең бер төркем шигырьләрендә туган як, туган җир мотивы калку чагылыш таба. «Шул якларда туган ягым», «Ләчегем», «Авылым җирләре», «Көзге уйлар», «Өй янымда», «Сердәш каен», «Ел төсләре», «Яз», «Җир анам» кебек гади, әмма тирән мәгънәгә ия шигырьләре авторның туган җиренә шигъри һәйкәле кебек кабул ителә. Себер табигате, шул төбәкнең татар авыллары сурәте авторны туган авылы, туган җире белән бәйләүче, үткәннәрне киләчәк белән тоташтыручы буын төсен ала. Түләнә, пайлан (пихта), косык (кедр) һ.б. Себер төбәге табигате белән бәйле образлар шундыйлардан. Кеше-табигать, туган җир янәшәлеген, бердәмлеген раслаган, табигать белән сөйләшү, диалог төсен алган мондый шигырьләрдә шагыйрәнең дөньяга карашы, эчке кичерешләре, яшәеш фәлсәфәсе аеруча калку ачыла. Ләчек, Вагай, Зәңгәр күл, Тайга кебек төшенчәләр, елга, күл, тау исемнәре үз төбәгенең географиясенә бәйле, әмма киң катлам татар укучысына таныш булмаган топослар гына түгел, лирик герой кичерешләрен, автор позициясен ачарга ярдәм итүче әдәби образлар булып калка, шагыйрә өчен изге төшенчәләр булып күтәрелә. Аерым берләре көчле позициягә – шигырь исеменә – чыгарылып, символик яссылыкта шул төбәктәге татарлар тарихын, язмышын ачуга да хезмәт итә башлый.

Күңел лирикасына мөнәсәбәтле аерым шигырьләр мәхәббәт мотивы тирәсенә туплана. Эчке монолог стилендә оештырылган «Син аңларсың», «Зәңгәр ерак, күксел томан», «Яшьлегемне эзләдем», «Син барында», «Синең сөю», «Сүнмәсен мәхәббәт нурлары», «Уйлар», «Хыянәт», «Нечкә сагыш», «Тартым», «Кагылма сөйгәннәр серенә», «Бергенәм» һ.б. шигырьләре хис-кичерешләрнең тирәнлеге, җыйнаклыгы, образлы булуы белән көчле.

Әле генә киек-казлар,
Узган иде биреп сәламен.
Кай арада үтеп язлар,
Көзләр элгән сары әләмен?..

Аларда хисләр палитрасы югалтулар аша табылган саф мәхәббәт тарихына бәйле шатлыктан югалту китергән әрнүгә кадәр тибрәлә. Беренче карашка гади, халыкчан стильдә язылган шигырьләрдә автор мәхәббәтне кеше тормышының иң төп терәге, яшәү мәгънәсе, теләсә кайсы авырлыктан тартып алырлык, егылганда торып басарга терәк булырлык көч итеп күтәрә.

Шагыйрә иҗатында Казанга багышланган шигырьләр дә күп. «Безнең өчен Казан бөек!», «Тукайга», «Татар каны аваз сала» һ.б. шигырьләре шундыйлардан. Үзенең «Авылларыбыз ятим калган. Ә без…» исемле мәкаләсендә «Ә инде әдәби телгә килгәндә, аңа карата булган урынсыз, мәгънәсез бәхәсләрдән туеп ук беткәнлектән, шуны гына әйтәсе килә. Әгәр без, себер татарлары, уртак татар әдәбиятыннан мәхрүм калсак, чын мәгънәсендә хәерче кавемнәргә керәп, кемнәрдән ярдәм көтәрбез икән», – дип, сорауны кабыргасы белән куйган Ф.Үтәшеваның шигырьләрендә дә Казан белән Себер бердәмлеге югары күтәрелә, аларда Казанны татарның Ватаны, татар шигъриятенең мәркәзе итеп данлау, аңа тартылу мотивы үзәктә тора. Бу мотив шагыйрәнең публицистик язмаларында да кызыл җеп булып сузыла һәм аны татар җанлы, милли мәсьәләләргә үтә сизгер каләм остасы итеп таныта.

Нурфия ЙОСЫПОВА,
КФУ профессоры.

«Аулак өй» серләре

Элекке елларда «Аулак өй»гә чакыру татар халкының бер матур йоласы булган. «Аулак өй» күбесенчә яшьләр тарафыннан көзен яки кышын берәр өйдә әти-әниләр каядыр кунакка киткән вакытта үткәрелгән.

Кичәгә яшь кызлар, гадәттә, күчтәнәчләр, төрле тәм-томнар алып килгән. Җыелган нигъмәттән кызлар коймак, ботка, кабартма, бәлеш һәм башка сый әзерләгән. Аулак өйгә килгән яшьләр бер-берсе белән аралашкан, бер-берсенең нәрсәгә сәләтле булуларын ачыклаган. Егет-кызлар, шул исәптән, кызыклы һәм җырлы-биюле уеннарда катнашканнар, милли уен коралларында уйнап җырлаганнар һәм биегәннәр. Егетләрнең гармун һәм курайда, ә кызларның думбра һәм кубызда татар халкының моңлы көйләрен башкарулары кичәләрнең ямьле мизгеле булган.

Аулак өй кичәләрендәге «Күз бәйләш», «Йөзек салу», «Көйсез кияү», «Йолдыз санау», «Күгәрчен ашату» кебек уеннар яшьләрнең бер-берсе белән яхшырак танышуында мөһим роль уйнаган. Уенда җиңелгәннәргә билгеле бер җәза бирелгән: җыр башкару, биеп күрсәтү, берәр төрле хайван тавышын чыгару, мич агарту, хуҗалыктагы терлекнең баш исәбен санау, чишмәдән су алып кайту... Шундый кичәләр яшь парларның гаилә коруларына да китергән.

Кызганыч ки, бүген татар халкында «Аулак өй» кичләре уздыру сирәк күренеш. Анысы да шәһәрләрдән ерак авылларда яисә милли бәйрәмнәр вакытында гына булырга мөмкин. Шуңа да илебезнең башкаласы Мәскәү кебек зур шәһәрдә бу татар йоласының заманчалашкан шәкелдә яшәве, сакланып килүе – искиткеч күренеш! Чөнки Мәскәүдә генә түгел, хәтта Казанның үзендә дә татарча «Аулак өй» кичәләрен кызыклы итеп уздыру серләре һәркемгә билгеле түгел шул. Мәскәүдәге «Татарларның һәм башка төрки халыкларның милли конгрессы» – борынгы йоланы кайтарган оешма. «Татар штабы» йортында еш кына шаулап-гөрләп «Аулак өй» кичләре уза. «Милли конгресс»ка килүче татарлар саны көннән-көн күбәя. Бигрәк тә алар арасында яшьләр саны арта баруы шатландыра.

«Татарларның һәм башка төрки халыкларының милли конгрессы» җитәкчесе Рөстәм Ямалеев әйтүенчә, штаб татар телен һәм мәдәниятен саклап калуны, шул исәптән Мәскәү шәһәрендә яшәүче татар һәм башкорт яшьләрендә туган телгә, халкына, милли гореф-гадәтләренә карата мәхәббәт уятуны бурыч итә. Әлбәттә, моны булдыру өчен яшьләргә хәзердән үк дөрес тәрбия биреп әзерләргә, алар белән татар халкы рухында аралашырга, тарихы белән таныштырырга, гореф-гадәтләрен һәм йолаларын аңлатырга, туган телнең матурлыгын һәм кыйммәтен җиткерергә кирәк! Нәкъ менә шундый чаралар уздыру, яшьләрне бергә җыеп, «Аулак өй» кичәләрен үткәрү «Татар штабына» бу максатка ирешергә ярдәм итә.

Мәскәү оешмасы уздыра торган «Аулак өй» мәҗлесләренең сере нәрсәдә икән соң? Бирегә килгән яшьләр берничә сәгатькә туган якларына кайтып килгән кебек була. Монда алар татар һәм башкорт активистлары белән таныша, үзләре өчен кызыклы мәгълүмат ала, туган телләрендә аралаша, милли ризыклар белән сыйлана, уеннарда катнаша һәм, Штабның матур гадәтенчә, гармунга татар җырларын башкаралар, матур бию көйләрен ишеткәч, рәхәтләнеп бииләр. Татар яшьләренең бик күбесе оешманың башка мәҗлесләренә дә килергә теләк белдерә, чөнки «Татар штабы»ндагы «Аулак өй»нең җылы мохите, сый-хөрмәте, мавыктыргыч уеннары, гитара һәм гармунга татар җырлары күңелгә бик якын булган үзенчәлекле кәеф тудыра һәм барлык кунакларны бер-берсе белән берләштерә, туганлаштыра сыман!

Лилия ГАЛИМОВА.

Атнаның сәяси мизгелләре

ЯҢА ЕЛНЫҢ СӘЯСИ ЧАЛЫМНАРЫ

Россия бүген хәрби реформа алдында тора. Аның иң мөһим юнәлешләре РФ Саклану министрлыгы коллегиясенең 21 декабрь көнне узган киңәйтелгән утырышында билгеләнде. Атом-төш өчлеген ныгыту, заманча һөҗүм кораллары (континентара оча торган «Сармат» ракетасы, «Циркон» ракеталары белән коралланган «Адмирал Горшков» фрегатын сафка кертү һ.б.) арсеналын киңәйтү дә – шулар рәтендәге адымнардан. РФ Кораллы көчләрен сан ягыннан 1,5 миллион кешегә (670 меңе – контракт буенча) җиткерү планлаштырыла. Хәрби хезмәткә чакыру яшен – 18дән 21гә кадәр, аның өске чиген 30 яшькә кадәр дә күтәрү күздә тотыла. Флотны исә алга таба «Борей-А» проектлы «Император Александр III» атом-төш крейсеры, 4 су асты көймәсе һәм 12 су өсте корабы белән тулыландыру да планга кертелгән. Реформа кысаларында шулай ук ике яңа хәрби округ булдыру һәм һава-десант көчләренең ике яңа дивизиясен формалаштыру каралган. Ә 2023 елга куелган төп бурыч – махсус хәрби операцияне ахырынача дәвам итү.

Соңгы айларда Россиянең төрле төбәкләрендәге объектларда шартлау һәм янгын чыгу очраклары ешаеп китте. Янгыннар, әйтик, Волгоградта (пластик тара җитештерү цехында), Красноярск каласында (сәүдә үзәгендә), Брянск өлкәсендә (дизель ягулыгы резервуарлары), Пермьдә (ТЭЦ-9 территориясендә) һәм Чуашстанда күзәтелде. Соңгысында инде янгын һәм шартлау Уренгой-Помары-Ужгород газ үткәргечендә килеп чыккан. Рәсми даирәләр казаның сәбәбен һәр очракта да көнкүреш кагыйдәләре үтәлмәве белән аңлата. Бәла-каза «Адмирал Кузнецов» крейсерында һәм башка хәрби объектларда да булып тора. Сәбәпләре исә аларда да шул ук – көнкүреш саксызлыгы. Хәлбуки, күптән түгел Россия парламенты диверсия гамәлләре кылган өчен җинаять җаваплылыгын арттыру турында закон кабул итте. Ә мондый борылыш инде әлеге казаларның ешаю сәбәпләренә дә күпмедер дәрәҗәдә ачыклык кертә.

Яңа елның сәяси чалымнары башка вакыйгаларда да шәйләнә. Әйтик, Россия Тышкы эшләр министрлыгы якын араларда тышкы сәясәтнең яңа концепциясен бәян итәргә җыена. Пентагон тиздән Украина кораллы көчләрен әзерләүнең киңәйтелгән программасын гамәлгә куймакчы. АКШның Алманиядәге хәрби объектларында һәр айда Украинаның 500 хәрбие әзерлек узачак. Запорожье өлкәсендә берничә эшелонлы оборона линиясе булдырылган. РФ Саклану министрлыгы Украинаның 1 гыйнварга кергәндә Макеевкада Россия хәрбиләрен кырып (соңгы мәгълүматлар буенча, 89 сугышчысын) юк итүенә үч рәвешендә, Краматорск каласындагы тулай торакларда Украинаның 600дән артык сугышчысын юк итүе турында белдерде. БМО КШ бүген, 13 гыйнварда, Япония рәислегендә, Украинага багышлап, «Украинада тынычлык вә иминлекне тәэмин итү» дигән тема буенча утырыш үткәрергә җыена.

Фоат УРАЗАЙ.

Әверелешләр

(Мөхәммәт Мирзага 70 яшь)

Җитмеш яшьлек юбилеена зур уңышлар белән килүче Мөхәммәт Мирза турында күп язганнар – мәртәбәле галимнәр дә, каләмдәшләре дә мөнәсәбәт белдереп калырга тырышкан. Каләм иясенең күләмле һәм формаларга бай шигърияте, чынлыкта да, әдәби тәнкыйтьтә киңколачлы яктыртылуга лаек, әмма, төрле катламнарга адреслап, юбилей уңаеннан язылган кечкенә күләмле мәкаләмдә аны иңли алмам. Уйладым-уйладым да күптомлыгының күңелемне тарткан тәүге китабына тукталдым. Илфак Ибраһимовның милләт яшәеше турындагы фикерләрен публицистик аһәңнәр ярдәмендә яңгыраткан шигырьләр белән ачылып китә ул.

Чорыбызның кайсы фәһемле шагыйрен генә укыма, татарның киләчәге өчен борчылу, аның зур фаҗигага илтүче бүгенге барышы турында уйланулары күзгә ташлана. Мөхәммәт Мирзада да шулай. Әдәби әзерлегеннән, белем дәрәҗәсеннән, сәяси-иҗтимагый фикерләре даирәсеннән чыгып, бер үк әсәрне төрле укучы төрлечә кабул итә. Беренче карашка шат ноталарда һәм күпмедер пафослырак та язылган «Идел-йорт» шигырен генә алыйк. «Иле, ирке булса, югалмас ул сынау тоткан тарих-заманда»,– дип белдерә анда шагыйрь. Берәү бу юлларны укыр да, Аллага шөкер, яшибез, дип куяр. Икенчесе, ә бармы соң Илем һәм Иркем, дигән сорау алдында калыр. Боларның бөтенләй юклыгын аңлаган миндәйләр дә табылыр. Хәер, кайбер алдагы әсәрләрендә шагыйрь бу хакта үзе дә әйткәләп уза:

«Тигезлек» дип,
«Хөррият» дип,
гәзитләргә язу яхшы,
аңлыйсыңдыр, сизәсеңдер:
карчыга бит – ике башлы».

Күңелемә метаморфозалар тасвиры якын. М.Мирзада алар шактый. Әверелешләр алымын кулланып иҗат ителгән үзенчәлекле әсәрләрдән «Ак Илем» әсирләндерде. Әдәби образны аерым төбәктә нефть чыгаруга бәйләп ачу, әлбәттә, шигырьне идея-тематик тарайта. Мин бу турыда уйламаска тырыштым. Башта әсәрне, «Ак Илем»не «Аппагым»га алмаштырып, хәтта сөекле яр сурәтен дә бу үрәвешчә тасвирларга мөмкин, дип укыдым. Аннан, ниндидер үзгәрешләр кертеп, күп нәрсәләрне шушы ук шигырьдә чагылдырырга була икән дип уйландым:

Ак идең, ак калырсыңмы,
Ак Илем – ак өметем?

Бу сорауны тарих дәвамында төрле сәяси хәлләргә тартып кертелгән татар халкына да биреп була. Аның җитәкчеләренә дә. Ничек чыгачак ул килеп туган ситуацияләрдән: каралыпмы, ата-бабалары кебек ак калыпмы? Бүгенге көндә бик актуаль яңгырый бу әсәр. Шагыйрь әлеге сорауга җавапны метаморфозалар ярдәмендә бирә:

– Ah!– диде. Болыт каралды,
Күк киде кара толып.

Автор өчен иң мөһиме – укучы күңелендәге әверелешләр. Ул аны әкрен генә аянычлы нәтиҗәләргә алып килә:

Илемнең сөттән ак йөзе
Караланып бара шул...

Их, нефть чыгарып кына, җирләрне пычратып кына каралмый шул Ил, дип уйлыйм. Чираттагы әсәрдән «Падишаһлар килгән-киткән...» строфасын укыганда да, шагыйрь язган соңгы җөмлә җанымны тырный. Әйе, падишаһлар килгән-киткән, аларның кылганнары халык тарихына йә ак, йә кара төсләрдә теркәлгән. Әнә шуңа күрә дә, М. Мирза әйтмешли, «Вакыт-тарих каршысында рәнҗеп тора халкым».

И.Ибраһимовның «Без исән!», «Тәңре ничек йөртә?», «Бөек күкнең күз алдында», «Тәрәзәмә кагылма, җил», «Ни күрер кызларым, улларым», «Мәскәүләрдән Казан күренә, диләр...», «Маңкорттыр без икебез дә», «Сорамачы, якташ» һ.б. шигырьләрендә дә бүгенгенең үтә кискен куелган сорауларына җаваплар бар.

Мирза әсәрләрен укыганда, автор аңында тышкы факторлар тәэсирендә туктаусыз рәвештә үзгәрешләр барганны күрәсең. Ул әхлакый-рухи сафлыкка омтыла һәм шәхеснең бу сыйфатын, беренче чиратта, тар даирәләр – әйтик, гаиләдәге, эштәге, сөйгән яр белән мөнәсәбәтләр кырында ачмый, ә югарырак биеклеккә – милли үзаң биеклегенә күтәрә.

Шагыйрь җәмгыятьтә дә фикер-карашларның статик түгеллеген күрсәтә. Бүген ак дип бәяләгәнебез иртәгә – кара, ә яман санаганыбыз тарих бизмәнендә уңай бәяләнергә мөмкинлеген аңлатырга омтылып яза һәм моны бигрәк тә сәяси юламаннарның, ил башлыкларының башына барып җитүен тели. «Коммунизм финишы» әсәрендә М.Мирза кайвакыт озак вакытлар гадел булып тоелган инануларның, кемнәрдер уйлап, көчләп, ышандырып тапкан кануннарның, күпләрнең озак еллар дәвамында хак дип санаган яшәү һәм уйлау рәвешенең бервакыт илне чиккә китереп терәргә мөмкин икәнлеген сөйли:

Юл тузан-
нарына батып,
тын кысылып
Килеп җиттек
Фи-и-ниш-ка...
Һичкем безне
Каршыламый,
Алкышламый.
Әлбәттә,
кемгә кирәк
Без
Бу кыяфәттә?

Бу дөньяда баштан ук туры юлны тапканнар да бар, әмма алар «эмансипация, имансызлар, исерекбашлар» илендә төрлечә кысрыклана (... Андрей Сахаровка). Аерым бер шәхескә мөнәсәбәттә язылган әсәр булуына карамастан, әлбәттә, туры сүзле акыл ияләрен, каләмдарларны да бердәй язмыш көткәнлеге турында уйлата ул укучыны. «Ниләр күрер газиз башлар?» соравын куйганда, шагыйрь үзенә дә ишарәлидер сыман.

Алда санап узылган шигырьләр янәшәсендә, М. Мирзаның «Өлкәннәр сүзе», «Бүген», «Ил карагы – кушавыз», «Кем иле?» һ.б. аерым шәхеснең, милләтнең, зур мәйданнарга таралып яткан Рәсәй халыкларының ышаныч һәм өмет кризисында язылган:

Кара төндәй билгесезлек
Өркетә дә өшетә...
(Керфек какмый төн уздырам)

Беренче томда лирик геройны киләчәккә бәйле билгесезлек чорнаган шигырьләр күп булуга карамастан, туксанынчы елларның көрәш мәйданы тудырган хыялларны, халыктагы гына түгел, хәтта парламентлардагы уңай якка үзгәрешләрне тасвирлаганнары да юк түгел. Шулардан «Маңкорттыр без икебез дә», стиль алымнары, чор рухын көчле ачуы белән, Такташларның, Туфаннарның кире кагучы һәм раслаучы пафоста язылган, яңалыкка, җиңүләргә әйдәгән күләмле әсәрләрен күңелгә китерә:

Бүген җенле мәгарәләрдән,
хәрабәләрдән,
чардуганнарны сытып
үтелгән каберлекләрдән,
ГУЛАГлардан,
җеназасыз, каберсез
күмелгән сазлыклардан
бихисап скелет-кешеләр күтәрелде,
күз ачып, дүрт тарафын карады,
алар аңлады.
Аңлады!

Мирзаның бу әсәрендә трагик, драматик, романтик, сатирик пафослар, төрлесе төрле үлчәмдә килеп, янгырашны үтә тәэсирле итә. Текстның нинди шартларда һәм нинди максатлардан язылганлыгы бигрәк тә соңгы юллардан ачык күренә:

Халыкка – азатлык, азатлык!
Аңа азатлык бик тә кирәк!

«Тарих тора» әсәрен укыганнан соң, гасырлар дәвамында илләр, халыклар, кавемнәр кичергән метаморфозаларның асыл сәбәпләренә ныграк төшенә башлыйсың:

Тарих тора патшаларның
сугыш уеннан.
Уеннан уймак чыгасы –
уеп куелынган.

Инкыйлаблар да, ил-ара сугышлар да җәмгыять халәтенә – диссонанс, аерым кеше җанына тынгысызлык алып килә.

шигърияте

Еш кына урта һәм түбән катламнар ил тормышында күрергә теләгән үзгәрешләр белән идарәчелек планнары капма-каршылыкка керә. Сугышлар Илбашларының амбицияләре сәбәпле кабынып киткәндә, гади бер кеше Ватан мәнфәгатьләрен ныграк аңлап фикер йөртә, хөкүмәтнең эш-гамәлләре деструктив характерга ия була. Үз гомерендә моны аңламый, күрми калган кеше юк. М.Мирза вакыт юнәлешләренең төрле һәм чиксез дәвамлылыгы аша ача аны. Димәк, бер үк нәрсәләр, эш-хәрәкәтләр кабатланган һәм, кызганыч ки, кабатланачак әле.

Киләчәккә оптимизм белән караткан «Каршылыйк» шигырендә М.Мирза, халыкның хак хөкеме кая илтер, дигән сорау куя һәм әсәрен шул сорауга җавап белән тәмамлый да:

Вакыт-бизмән
Көзгесендә
Ачык күрәм:
Шагыйрь – патша,
Патша – Алып,
Алып – шагыйрь
булыр көннәр
Килә безгә.

Шагыйрь, чынбарлык героикасын тасвирлаганда, милли проблемалар чишелешендә, халыкны мәйданнарга тартуда Сүзгә зур өмет баглый әле. Аның «Лирик мин»е шәхси мәнфәгатьләр колы булудан ерак, үз халкының алгарышын кайгырту биеклегенә күтәрелгән.

Татар иҗтимагый-сәяси шигъриятендә бабалар яшәгән заманнарны, данлыклы тарихи узганны ностальгия дәрәҗәсендә тасвирлауга зур мәйдан бирелгән. М.Мирзаның бу томлыгында исә үткән гасырларның шомлы елларын, караңгы сурәтләрен күз алдына торгызу зуррак урын алып тора («И туган тел», «Өлкәннәр сүзе», «Замана», «Булды, булды» һ.б.) Андый эчтәлектәге әсәрләрдә шагыйрь чорның,тирәлекнең халыкны артыннан иярткергә сәләтле талантларга мөнәсәбәтен күрсәтә, кайвакыт хөкүмәтнең, аерым бер җитәкченең үз-үзен саклау инстинктына бирелеп, кыю телле әһле каләмгә кылган кабахәтлекләрен, аны үз ягына аударуның юл-ысулларын да барлый:

Кан көндәше шагыйрьләрне
Һәр тиран үзенчә кырган:
Кайсы өзгән чабып башын,
Кайсы данга тончыктырган...
(Булды, булды...)

Маңкортлар аяк астында
Таптады сине, Тукай.
(Тукай – иман)

Кызык бит: бөтен ил белән сайлап куелганнар үзләренә көндәш, димәк, тиң (!) итеп, иң беренче чиратта, шагыйрьләрне саный. Алар да, милләтенең узганына, бүгенгесенә һәм киләчәгенә төкереп караган маңкортлар да нәкъ менә Сүз остасын халык күңеленнән алып атарга тырыша, аны яулаган биеклекләреннән түбәнгә тәгәрәтү уе белән яна.

Мирза иҗатындагы, үткәндәге ялган кыйммәтләргә кире кагып, яңаларын – халык алга куярдайларын раслау, бигрәк тә татарга бәйле гаделлек һәм хаклык эзләү автор шәхесен дә зурайта, үз милләте каршында мәртәбәле итә.

М.Мирза абстракт язмый. Тормыштан шәхси фикерләрен дәлилләрлек фактлар эзли, таба, татарның узганын укучы күз алдына аңына узарлык торгызып бастыра. Аның иҗатында зур көрәшләрдә җиңгәннән соң да икътисади авырлыклар кичергән халыкның газиз балалары, үсмерләре тасвиры да әледән-әле күренеп китә. Аларда кулланылган теге яки бу әдәби деталь кайвакыт сискәндереп җибәрә, укучыны үз эшләрен бәяләүгә, рухи сафлануга, әхлакый төзәлүгә этәрә:

Яздан көзгә, кардан карга
Барыбыз да яланаяк...
Ат та шул ук, йөгән дә шул –
Карамадан кәкре таяк.
Песи борчак, карга күзе,
Җитен-орлык, кәҗә сакал... /.../
Күпме кошның
Ояларын туздырдык та
Йонсыз, шыксыз, сукыр
Сабыйларын җиргә бәрдек!
Йа Ходам...
Кемнән шулай
Вәхшиләрчә үч алдык
Без –
Сугыштан аяксыз кайткан
Әткәйләрнең
Малайлары?..

Күренеп тора: М.Мирза яшьләрне дә, олыларны да уйлы яшәүгә, милләт дип, ил дип яшәүгә әйдәкли. Без имансыз үстек, дип белдерә аның көрәшләргә алгысынган герое «Без бабайсыз үстек» шигырендә.

Бүгенге көндә, әдәбият һәм мәгариф яшь буынны ничек кенә патриотик рухта, киләчәкне төзүче итеп тәрбияләүне алга куймасын, ил-җәмгыятьнең заманга хас күрсәтер зур уңышлары – таяныр җирлек юк. Мәдәни-икътисади артка китешне күрү безне алмаштырачак буынга сүзгә караганда ныграк тәэсир итә. Күпчелекнең мәнфәгатьләре тапталган, вак милләтләргә төкереп каралган чорда яшәсә дә, Мөхәммәт Мирза барыбер, Сүз көче белән, укучыда өметне саклап калырга омтыла:

Кара төндә,
Керфек какмый,
Яңа ай көткән кеше бар.
Өметләр белән,
Теләкләр белән,
Үзе өчен дә,
Иле өчен дә.
(Ай тотылган төндә)

М.Мирза безне, бу әсәре белән генә түгел, тулы иҗаты белән дә, язучы миссиясе турында уйларга да этәрә. Шуны күрсәтергә теләп, язмамда күбрәк милли гамьле, халыкны кайгыртулы уй өретелгән әсәрләргә тукталдым. Башка темаларга язылганнары арасында күңелемне гаять нык тибрәлдергәннәре, иң нечкә җирләренә кагылганнары күп булды, әмма, заманның иҗтимагый-сәяси торышына бәйле рәвештә, иң актуаль яңгырашлыларын халыкка тәкъдим итүне үземнең милли бурычым санадым.

Ә бит, бер карасаң, М.Мирзаның мәхәббәт темасына язылган әсәрләрендә дә әверелеш арты әверелеш, берсен-берсе алмаштырып килгән сурәтләр. Әнкәсенә багышланган күләмле әсәренең «Җаннарны ай җыя» өлешендә «бармаклары, бау шикелле, үрелгәннәр бер-берсенә» ди ул «төенчек кебек, кечерәеп калган» карчык турында, күңелләребездә өлкәнәеп барган әнкәләребезгә карата иң нечкә хисләрне кузгатып.

Томлыкта сагыш хисе калдыра торган шигырьләр байтак. М.Мирза бер әсәрендә бу хакта, китабым сагышлы, сагышлы шул, дип, үзе дә искәртә. Аның төрле чорда язылган китапларыннан, чыннан да, «сагышлы замананың сагышлы баласы» икәнлеге ачык күренеп тора.

Илфак каләмдәшем!
Аркалары белән әйләнеп яткан
Коелган тал яфраклары
күл өстендә...
Офык читендә болытларга
ут капкан:
әллә кояш баткан,
әллә таң аткан.
Бераздан шәфәкъ-кызыллык
югалыр эреп:
төнгәме, көнгәме? –

дип язасың, алдыбызга җан өшеткеч сораулар куясың. Көнгә булсын иде ул, бары тик көнгә! Якты көннәргә алып чыксын иде милләтебезнең бүгенге караңгы төннәре. Шуңа бик тә ышанасы килә.

Рифә РАХМАН.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

14 гыйнвар (шимбә). ***Җомәдел ахир аеның 22 нче көне. 22 нче Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында,1.14 сәгатьтә калка, 11.29 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 7.34 сәгать.***

Акыл җыю, белем алу, фәннәр өйрәнү көне. Юмарт булырга, ашау-эчүдә үзеңне чикләмәскә кирәк. Күбрәк аралашкан саен, яхшы тәэсирләр дә арта бара. Кан әйләнеше системасы, буыннар, умырткалык зәгыйфь.

Грипптан соң

Грипптан соң хәлсезләнгән организмны ныгыту өчен, эмальләнгән кәстрүлгә 1 әр аш кашыгы бал, какао порошогы, атланмай салып, кайнар сулы зуррак савытка утырталар һәм болгата-болгата эретәләр. Көненә 4 тапкыр, ашар алдыннан, 1 әр чәй кашыгы кабалар.

15 гыйнвар (якшәмбе). ***Җомәдел ахир аеның 23 нче көне. 23 нче Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында,2.42 сәгатьтә калка,11.37 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 7.37 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Тәвәккәл адымнар ясау хупланмый. Арып-талганчы эшләргә киңәш ителми. Дару үләннәре белән дәвалану уңай нәтиҗә бирә. Иҗат белән шөгыльләнү өчен яхшы вакыт.

Сырганак сихәте

Ашказанында җәрәхәт булганда, мондый өстәмә дәва чарасыннан файдаланып карарга мөмкин. Ашарга 15 минут кала 1 аш кашыгы сырганак мае эчәләр дә, 1-2 минут уң якта, 1-2 минут аркада, 1-2 минут сул якта, аннары корсакка капланып яталар – ашказанын бөтен яктан "майлап" чыгалар. Беренче 3 көндә сару кайнарга мөмкин, шунлыктан майга сода эремәсе (ярты стакан суга чирек чәй кашыгы аш содасы) кушып эчәргә кирәк. Болай дәваланганда, диета тоту һәм һичшиксез табиб белән киңәшү зарур.

16 гыйнвар (дүшәмбе). ***Җомәдел ахир аеның 24 нче көне. 24 нче Ай тәүлеге. Ай Чаян йолдызлыгында, 11.42 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 7.39 сәгать.***

Артык активлык күрсәтү хупланмый. Ялгыз калып уйлану өчен уңай вакыт. Эчке тавышка колак салу файдалы. Бизләр системасы, кан тамырлары, тире, эчәклек зәгыйфь. Күзне арытмаска кирәк.

Кайда нинди витамин бар (1)

А витамины кабак, кишер, кәбестә, салат, яшел тәмләткеч үләннәр, бәрәңге, өрек, бавыр, бөер, диңгез балыгы, йомырка сарысы, атланмай, сөт өсте, әче сөт ризыкларында күп. В1 витамины солы, арпа, фасоль, бәрәңге, бавыр, бөер, чикләвек, чүпрә, кукуруз, карабодай, шыттырылган бодайда бар. В2 витаминына кәбестә, яшел борчак, алма, помидор, шалкан, солы, сыра чүпрәсе, порей суганы, бодай, сыер ите, бавыр, әче сөт ризыклары бай. В3 витамины чыганаклары – чүпрә, ит, бавыр, бөер, әче сөт ризыклары, карабодай, бодай, солы, кукуруз, арыш, гөмбә.

17 гыйнвар (сишәмбе). ***Җомәдел ахир аеның 25 нче көне. 25 нче Ай тәүлеге.***

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

Ай Чаян йолдызлыгында, 4.16 сәгатьтә калка, 12.01 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 7.42 сәгать.

Акыл җыю көне. Интуициягә таянырга була. Күргән төшләр рас килә. Сизү әгъзалары, баш, колак, кан тамырлары зәгыйфь. Энергияне юк-барга сарыф итәргә ярамый. Ач тору файдалы.

Кайда нинди витамин бар (2)

B5, B6, B9 һәм B12 витаминнарына йомырка сарысы, бавыр, бөер, әче сөт ризыклары, үсемлекләрнең яшел өлешләре, арахис, ярмалар, әфлисун, кавын, балык бай. C витаминын даими куллану зарур, ул цитрус җимешләрендә, кызыл төстәге җиләк-җимешләрдә, чәчәк кәбестәдә, яшел борчак, фасоль, тормада күп. D витаминының төп чыганаклары – йомырка, сөт, атланмай, бавыр, балык. E витаминына бөртеклеләр, үсемлек майлары, йомырка, салат-латук, бавыр бай. F витамины балык мае, зәйтүн мае, кипкән җиләк-җимештә күп. H витамины бавыр, гөмбә, шоколад, чикләвек, сөт, йомырка сарысында бар. K витаминына диңгез кәбестәсе, яшел чәй, шпинат, башлы суган, ясмык бай.

18 гыйнвар (чәршәмбе). ***Җөмәдел ахир аеның 26 нчы көне. 26 нчы Ай тәүлеге. Ай Укчы йолдызлыгында,5.49 сәгатьтә калка, 12.23 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 7.45 сәгать.***

Һөнәрләре вәсвәсәләргә бай көн. Әйләнә-тирә дөньяны кабул итү кискенләшә, тәэсирләнүчәнлек арта, чит кеше йогынтысына бирешүчәнлек көчәя. Килешүләр төзү уңышлы. Нерв системасы, аяк зәгыйфь. Балык, мүк җиләге, сөт ризыклары ашау файдалы.

19 гыйнвар (пәнҗешәмбе). ***Җөмәдел ахир аеның 27 нче көне.27 нче Ай тәүлеге. Ай Укчы йолдызлыгында, 7.18 сәгатьтә калка, 13.01 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 7.49 сәгать.***

Бу көннәрдә организм хәлсез, шуныктан күбрәк йоклау файдалы. Нерв системасы, сизү әгъзалары зәгыйфь. Кан һәм лимфа авырулары кискенләшергә мөмкин. Кан басымын контрольдә тоту сорала.

20 гыйнвар (җомга). ***Җөмәдел ахир аеның 28 нче көне.28 нче Ай тәүлеге. Ай Кәҗәмөгез йолдызлыгында,8.30 сәгатьтә калка, 14.02 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 7.52 сәгать.***

Айның иң яхшы көннәреннән берсе. Энергетикасы бик уңай. Көтелмәгән очрашулар берсеннән-берсе кызыклырак булачак. Хисләр тирәнәеләнә, аралашу теләге уяна. Сизү әгъзалары, аеруча күзләр зәгыйфь. Кан басымын контрольдә тоту зарур. Яңа Ай туарга ике генә көн калып бара, карангы, Айсыз төннәр күңелгә шом сала. Организмны чистарту, ач тору уңай нәтиҗә бирә.

Алма бәлеше

1 әр стакан он, манный, шикәр, 1300 г алма, 100 г атланмай, 1 чәй кашыгы камыр көпшәкләндергеч, ванилин кирәк. Он, шикәр, манный, камыр көпшәкләндергечне кушып болгаталар, алмаларның кабыгын чистартып, эре угычтан уалар. Табаны майлап, 1 стакан коры камырны, өстенә алманың өчтән берен җәяләр. Аннары тагын 1 стакан камырны, өстенә алманы, аннары тагын камыр, тагын алма җәяләр дә, ванилин сибеп, өстенә туңган атланмайны эре угычтан уалар.180 градуслы газ мичендә 45 минут пешерәләр. Суынгач кына кисәргә кирәк.

Алдашу һәм вәгъдә

Хәзерге заманда хәйлә-ялган, әйткән сүзендә тора алмау бик күпләр өчен гадәти бернәрсәгә әйләнеп бара. Дөнья мәшәкатенә чумып тормыш куучыларның ул хакта уйларга вакытлары да, теләкләре дә юк.

Безнең арада ялган шулкадәр күбәйде, хәтта, «Аз-маз ялганнан берни дә булмый, ансыз тормыш бармый», – дип уйлыйбыз. Телевизорны ачсаң – хәйлә-юмалау, интернет челтәрләреннән дә ялган чишмә суыдай агыла. Әйе, сирәк-мирәк дөрес хәбәрләр дә күренгәли арада, әмма хаклыкка караганда, ялганы күбрәк шул.

Әгәр игътибар итсәгез, замана аферистлары нинди генә яңа алымнар уйлап тапмыйлар. Әз генә акча бирәсең дә, тиз арада миллионерга әйләнәсең имеш. Күпме алданса да, табигате белән беркатлы шул кеше, барыбер, ышана. Ахыр чиктә ачыклана: баксаң, алай җиңел генә баеп булмый икән бит. Тик моны аңлаганда соң була инде.

Ә шулай да ялганның шундый үзенчәлекле ягы бар. Иртәме-соңмы, барыбер, ачыклана ул. Юкка гына халык: «Ялганның гомере кыска», – дип әйтмәгән.

Динебез дә әйткән сүзләребезгә игътибарлы булырга һәм дөресен генә сөйләргә куша. Ялган кешенең тормышын пычрата һәм башкалар алдында аның абруен төшерә, ахыр чиктә, җәһәннәмгә керүенә бер сәбәп була. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә «Дөреслектә, хакны сөйләү тәкъвалыкка илтә, ә тәкъвалык җәннәткә китерә һәм, дөреслектә, кеше һәрвакыт чынын сөйләсә, аны Аллаһының хозурында иң дөресен сөйләүче итеп язарлар. Дөреслектә, ялган гөнаһка илтә, ә гөнаһ җәһәннәмгә китерә, кеше һәрвакыт ялганласа, Аллаһының хозурында аны үтә ялганчы буларак язарлар», – дип әйтеп калдырган (Бохари һәм Мөслим риваяте).

Кызганыч, акча беренче урынга куелган бу заманда кешеләр хәйлә-ялган кулланып, бик тиз генә баемакчы була. Сыйфатсыз товарларын, бәлә торып, «бик яхшы» дип ялганлый-ялганлый, ничек тә сатарга тырыша.

Ризык, кием-салым, йорт кирәк-ярагын гына түгел, даруларны да «бар чирдән дәвалый», дип алдалап сатучылар табыла. Кешегә аның файдасы бармы-юкмы, монысы аларны кызыксындырмый, иң мөһиме, сатылсын да, акча гына керсен. Бәлки, кеше үзенең соңгы акчасын биреп аладыр, бәлки ул мохтаҗлар рәтеннәндер?.. Анысында һич эшләре юк, чөнки табыш күзләрен томалаган. Бу уңайдан, Пәйгамбәребез салләллаhу галәйhи вә сәлләмнең: «Вәгъдә (сатучының



ялган вәгъдәсе күз алдында тотыла) товарның сатылуына булыша, ләкин табыштан бәрәкәтне югалта», – дигән хәдисен китерү дөрес булыр (Бохари риваяте, 2087).

Сәүдәбез барсын дип, берәр кимчелеге булган яки брак товардан тизрәк котылыр өчен, ялганлап-хәйләләп сатарга тырышабыз һәм соңыннан: «Булдырдым бит, табыш керде, акчалы булдым», – дип сөенәбез. Әмма бу сөенечебез кыска гомерле булачак. Чөнки алдау гөнаһы аркасында сәүдәбездән бәрәкәт китә. Бу табыштан кергән акчаның бәрәкәте булмаячак. Акча дигәнең ялган, гөнаһлы юл белән ничек тиз керсә, шулай ук җиңел генә чыгып та китәчәк, аның файдасын күрми дә, сизми дә калачакбыз. Йә, безне алдалап, ул акчаны алып китәчәкләр, яки кинәт кенә авырый башлап, шул гөнаһлы кәсептән кергән акчабыз дәвахәнә юлында йөреп чыгып бетәчәк. Җитмәсә әле, әҗәткә дә кереп, ул байлыкның бәхетен дә тоймый калачакбыз.

Бу тормышта ялганнан читтә тору, дөресен генә сөйләү ничек кенә авыр булса да, үзебезне үзгәртергә тырышыйга кирәк. Без үзгәрмәсәк, җәмгыятебез ничек үзгәрсен соң?! Безне алдалаганнарын бер дә яратмыйбыз. Ә үзебезгә ялганнарга туры килсә: «Хәзер дөньясы шундый инде аның», – дип, акланырга сәбәбен табабыз. Безне алдалаган кешегә һич тә: «Заманасы шундый аның, алдала, әйдә, алдала», – дип әйтмибез бит. Җиле үзебезгә килеп тигәндә генә, «алдаларга ярамый» дигән хакыйкатьне бик тиз искә төшерәбез.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтик: үзебездә Раббыбызның ризалыгына ирештерә һәм җәннәткә илтә торган дөреслекне сөйләү гадәтен булдырырга тырышу зарур. Гөнаһка батып җәһәннәмгә илтә торган ялганнан ерак торыйк. «Аллаһ каршында күңелем чиста булсын. Аның алдында җавап торарга җиңелрәк булыр», – дип уйлап, ялганнан чистарыныйк. Җәмгыятьтәге хәйлә-ялганны, алдашуны бетерү өчен, иң элек, үз уебызны, үз телебезне, үз гамәлебезне ялганнан саклаудан башлыйк.

Коръәни Кәримдә дә: «Адәмнәрнең уң ягында (савапларын) һәм сул ягында (гөнаһларын) гамәлләрен язып баручы ике фәрештә бар. Кешенең авызыннан чыккан бер генә сүз дә Күзәтүче тарафыннан язылмыйча калмый», – диелгән («Каф» сүрәсе, 17-18 нче аятьләр).

Бездән үрнәк алып, якыннарыбыз үзгәрер, тора-бара, җәмгыять тә әз генә генә булса да ялганчылардан чистарыныр иде.

Алдау-хәйләдән ерак булып, әйткән сүзебездә тору, биргән вәгъдәләребезне үтәү – кешелекле сыйфатларының иң югары күрсәткече, дип әйтсәк, бер дә ялгыш булмас. Абруйны арттыра һәм халык арасында «ышанычлы кеше» булырга ярдәм итә торган сыйфатларның да берсе әле ул. Бигрәк тә, килешүне үтәмәгән, әйткән сүзендә тора алмаган кешеләр арта барган безнең чорда бу турыда искә төшереп китү үтә мөһим.

Аллаһ Тәгалә Коръәни Кәримдә: «Вәгъдәләрегезне үтәгез, чөнки вәгъдә ителгән нәрсә өчен соралачаксыз», – дип әйтә («Исра» сүрәсе, 34 нче аять). Икенче бер аятьтә Раббыбыз әйткән сүздә торырга, килешүләрне үтәргә әмер итә: «И-и, иман китерүчеләр, вәгъдәләрегезне үтәгез!» («Маидә» сүрәсе, 1 нче аять). Бу аятьләр мөселман кешесенең үзе әйткән сүзләргә, биргән вәгъдәләренә бик җитди карарга тиешлеген ассызыклый. Шуңа да берәр кешегә нидер эшләргә вәгъдә итсәк, ничек кенә булса да аны үтәргә тырышыйк. Әгәр авырып китсәк яки башка җитди сәбәпләр булса, ул вакытта гафу сорап, хәлне аңлатырга кирәк. Алайса, әйткән сүзләребезгә бик җиңел карый башладык. Шушы срокка бетерәм, дип антлар бирә-бирә кайберәүләр эшкә тотына, тик эшнең нәтиҗәсе дә, шалтыратып кисәтү дә юк, үзең элемтәгә чыгарга теләсәң, телефонны да алмый интектерәләр.

Тагын бер мисал китерәсем килә: әҗәткә акча биреп торганда, «бер айга гына» дип ышандыра-ышандыра алучылар бер ай үткәч юкка чыгалар. Акча да юк, шалтыратып гафу үтенеп, «кичектереп торыйк әле, мөмкинлегем юк бит...» дип, вәгъдәсен ни өчен үтәмәгәнлеген аңлату да юк. Әгәр кайчан кайтарасың, дип шылтыратып сорасаң, шундый коры, дорфа сөйләшә, әйтерсең, аның кесәсенә кереп, акчасын алмакчы буласың.

Сәүдә эшендә дә мондый хәлләр еш очрый. Берәр сатучы белән товарны төгәл вакытка китерергә дип, килешү төзисең, әмма ул вакытына китерми, товар син сораган кадәре дә булмаска мөмкин, ә кайвакыт сыйфаты да син таләп иткәнчә түгел. Килешүләрне үтәү мәсьәләсенә шундый җиңел карый башладык ки, бернинди җаваплылык та юк сыман. Әмма шул хакта да уйлансак иде: кеше арасында исемебезгә тап төшеп, ышанычны югалтып кына калмыйбыз бит. Иң мөһиме, биргән вәгъдәләребез өчен Аллаһ Тәгалә каршында җавап тотачакбыз.

Шуңа да, кардәшләрем, дустыбызга яки танышыбызга вәгъдә бирер алдыннан төптән уйлыйк: моны эшли аламмы, билгеләнгән вакытка килеп җитәмме, эшне төгәл билгеләнгән вакытка тәмам итәргә өлгерәмме? Көчебездән килмәсә, җаебызга туры килеп бетмәсә, вәгъдәләр бирергә ашыкмыйк. Халкыбызда да шундый әйтем бар: «Вәгъдә кылсаң, вафа кыл», ягъни вәгъдә бирсәң, әйткән сүзеңдә тор, бурычыңны үтә. Сүз тотмас кешеләрдән булмыйк, андый сыйфаттан ераклашыйк, шул вакытта халык арасында «ышанычлы кеше» дигән яхшы атыбыз булыр.

Коръәни Кәримнең «Саф» сүрәсендәге 2-3 нче аятьләрдә, «И иман китерүчеләр! Ни өчен сез эшләмәгәнне сөйлисез? Сез сөйләп эшләмәгән нәрсә Аллаһның ачуын китерә», – дип әйтелгән. Бу сүзләрне онытмыйк, һәрчак истә тотыйк.

Аллаh Тәгалә ныклы иман биреп, сөйләшкән сүзләребез хаклыкка туры килсә, ялганнан ерак булып, ике дөнья бәхетенә ирешергә насыйп әйләсә иде.

Раил ФӘЙЗРАХМАН,
Балык Бистәсе районының Тәберде Чаллысы мәчете мөгаллиме.
(«Догалы өй»).

Бик еракта идек без...

Туган якның кадерен читкә киткәч беләсең икән. Үзем күргәннәрдән чыгып әйтәм моны. Узган гасырның җитмешенче еллар уртасында, институтны тәмамлагач, бергә укыган дустым белән Себергә – Красноярск ягына ук киттек. Дөнья күрәсебез килә! Безне еракка очырган теләк шул иде. Бар да кызыклы иде монда. Әмма тора-бара үземә нәрсәдер җитмәвен тоя башладым. Озын сүзнең кыскасы дигәндәй, милләттәшләрем, татарча сөйләшергә беркемем дә юк иде биредә. Иптәшем дә, тиз генә өйләнде дә шәһәр читендәге шәхси йортларның берсендә яши башлады. Тулай торакта ялгыз калдым.

Бергә укыган якташым янына ял көннәрендә барам. Шулай берсендә, дуслардан кайтып килгәндә, иске микрорайондагы ике катлы бер йортта, гармун уйнауларын ишеттем. Татар көенә охшатып, тукталып тыңлап тордым. Икенче каттагы балкон ишеге ачык – шуннан ишетелә иде гармун тавышы. Әйе, безнең татар көен яңгырата иде анда кемдер. Икенче катка менеп ишекләрен шакыдым...

Гармун уйнаучы хатын-кыз – Эльмира исемле татар апасы булып чыкты. Татар булуына бик сөенеп кыенсынуларымны да оныттым. Бу якка ул ире белән килеп чыккан. Эльмира апа үзе Кузбасстан, әтисе шахтада эшләгән. Атасы дөнья куйгач, аның гармунын истәлеккә алган булган. Музыка коралында уйный белмим, шул әтием искә төшкәндә шыңгыштып алам инде, диде ул. Көйләрен белмәсә белмәс, татарча сөйләшүгә дә бик җиткән миңа. Берничә тапкыр кердем мин аларга. Ире дә чакыра: – Мин бит үзем дә туган шәһәрем Новокузнецкины бик сагынам, аңлыйм сезне! – диде әнә.

Әмма аның хәмер капкач дуамаллана торган гадәте бар икән шул. Берсендә шулай, үзебезнең телдә сөйләшеп утырганда, исереп кайтып керде дә, сез минем турыда әллә ниләр быгырдыйсыз, дип җәнҗал куптарды. Мин чыгып киттем. Инде йорттан чыгып урамга борылганда артымда нәрсәнендер шап итеп җиргә төшүе ишетелде. Борылып карасам, теге гармун ята. Мин аптырап калдым. Көй чыганагының ни гаебе булды икән? Нишләтергә инде аны хәзер? Хуҗаларына алып менүдә мәгънә юк. Җитмәсә, агач корпусы берничә урында чатнаган үзенең. Монда калдырсаң чүпкә атачаклар аны! Үземнеке булмаса да жәл иде Кузбасс истәлеге.

Шулчак минем дус яшәгән йортның хуҗасы Гриша дәдәй искә төште. Ул бит оста кеше. Агачтан әллә ниләр ясый. Хатыны Анна түти горурланып күрсәтте безгә аның кыйган әйберләрен. Өй җиһазларының барысын да – кашыктан алып караватка кадерлесен уйган ул. Минем якташка әнә җыйнак кына ипи савыты да бүләк итте. Арыш башакларын уеп матурлаган иде савытны. Гриша дәдәй төзәтмәсме икән дип уйлап, гарипләнгән гармунны шуларга алып бардым. Эшләп карармын диде, карышмады. Күп тә үтмәде якташым мине үзләренә чакырды, гармуныңны ясадык, диде.

Матур килеп чыккан иде көй чыганагы, гел менә өр-яңадан җыйган диярсең! Останы мактап, инде уйнап та күрсәт дип үтендек без. Ул кул гына болгады. Анысы миннән булмый диде дә, гармунны минем яндагы урындыкка куйды. Өй хуҗабикәсе Анна түти чәй әзерләгән иде, гәпләшеп чәй эчеп алдык. Сүзебез Казан турында барды, әлбәттә. Моңарчы сүзсез утырган хуҗабыз чәен эчеп бетергәч, йомрысын этеп куйды да, телгә килде:

– Җырлыйммы хәзер?

– Әйдә! Әйдә! Җырла Гриша дәдәй! – диештек без аңа.

Минем менә бу «Әйдә» дигән сүзем татарча килеп чыктымы, ул миңа аерым карап алды. Өстәл янында җайлап утырды да:

– Җырлыйм? – дип кабат сорады.

Без аны тагын кыстадык та тынып калдык. Һәм ул:

– Бик еракта идек без... – дип сузып җибәрде. Һәм шунда ук өзелде дә.

Әстагы, чынмы бу?! Без текәлеп аңа карап бактык.

Нибары бер җөмлә әйтә алды ул, әмма татарча һәм аны да шундый моңлы итеп сузды. Без шаккатып тынып тордык, бер сүз дәшә алмадык. Хуҗа кеше татар кешесе икән бит! Ул кинәт кенә торды да өйдән чыгып китте.

Ерак Себердә һич уйламаганда милли җыр сүзләрен ишетеп таң калдым мин. Бер генә мизгелгә йөрәген ачып күрсәтте безгә милләттәшебез, ник моңарчы ачылмаган ул? Ничек кенә кызыксынсам да, Гриша дәдәй белән ул көнне сөйләшеп булмады.

– Берүк кыстамагыз аны, аның йөрәгенә кан сава! – диде хуҗабикә.

Әйе, якташ булып чыкты ул безнең. Исеме Габдерәүф икән. Моны инде миңа Анна түти юлда сөйләде. Гармунны хуҗаларына ничек тапшырабыз дигәч, ярдәмгә алынган иде. Иске микрорайонга сөйләшә-сөйләшә бардык. Шунда бар да аңлашылды.

Габдерәүф абыйның язмышын сөйләде ул миңа. Гриша дәдәй сугышта әсирлеккә эләккән булган. Инде сугыш бетеп азат ителгәч тә, аны озак кына тинтерәткәннәр, аннары туры Себергә китергәннәр. Монда НКВД тоткыннарын шактый күп туплаганнар. Менә шушында алар икенче тапкыр коллык газапларын күргән. Биредәге хәрби предприятиене һәм каланың үзен дә алар төзегән. Ниһаять, ирек бирелгәч, туган ягына кайтып киткән, әмма аннан тиз борылган. Аны авылында әсир, хыянәтче, дип кимсеткәннәр һәм ул Себергә кире әйләнеп килгән. «Өйләнешкәч, туганнарың белән танышыйк, дип туган ягына кайтып килергә чакырдым. Әмма карышты, аннары хат язып салган иде дә, җавабын укыгач, кайгыга батты. Төнлә шул хатны тотып елап ятты. Җавапны апасы язган икән. Синең аркада әни кайгырудан башын күтәрә алмады, нишләсәләр дә, синең малаең әсирлектә булган, дип кыерсытканнар аны. Шул кайгырудан гүргә керде дип язган... Бу хатны алгач озак интекте ул. Йөрәгенә кан сауды. Менә шул яраткан эше коткарды. Балалар тугач кына, йөзе чын-чынлап яктырды», – дип сөйләде хатыны.

Ә гармунны кыю Анна түти үзе кертеп чыкты. Барысын аңлаткач, рәхмәт укыдылар, диде ул.

Гаиләдә савыт-саба шалтырамый тормый инде, дип чакырсалар да, Эльмира апаларга бүтән кермәдем. Габдерәүф абыйларга исә еш йөрдем. Йөрәк ярасына кагылмыйм дип, туган як белән бәйле сүз кузгатмадым, билгеле.

Гәрчә аның турында күп уйландым. Кеше ничек кенә кыйналмаган, ә менә күңелендә милли моң сакланган, онытылмаган. Искиткеч көчкә ия икән безнең татар моңы!

Милли моң димәктән, җырларыбызны бүтән якташларым да егылып тыңлый иде. Әйе, яши торгач, үзебезнең шәһәрдән гайре Красноярскида яшәүче милләттәшләрем белән дә таныштым мин. Ялга кайтканда яисә командировкага барганда, аларга Казаннан татар җырлары яздырылган пластинкалар алып килә идем. Шуларга сөенүләрен күрсәгез иде! Араларында нинди генә һөнәр ияләре булмасын, Илһам Шакиров һәм Әлфия Авзалова җырларын елый-елый тыңлыйлар иде. Атаклы җырчыларыбызның пластинкалары кулдан-кулга йөреп туза һәм мин аларны тагын алып килә идем...

Әллә соң без шундый нечкә күңелле халыкмы? Татар җырлары читтә аеруча тәэсирле икән. Милли моңыбызның серле көчен Себердә үз күзләрем белән күрдем...

Ильяс САЛИХҖАН.

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

13 гыйнвар – «Зәңгәр шәл» (К.Тинчурин).
14 гыйнвар – Шәрык клубында – «Бичара кыз» (Г.Ильяси). Кече залда – Буа Татар дәүләт драма театрының «Дәрвиш» спектакле. Зур залда – «Сәфәр» (А.Шакиров).
15 гыйнвар – Шәрык клубында – Театр оркестры концерты. Кече залда – Буа Татар дәүләт драма театрының «Дәрвиш» спектакле. Зур залда – «Җанкисәккәем» (Т.Миңнуллин).
16 гыйнвар – Кече залда – Буа Татар дәүләт драма театрының «Дәрвиш» спектакле.
17 гыйнвар – «Хуш, авылым» (А.Җаббаров).
18 гыйнвар – «Җәйнең бер көнендә» (Й.Фоссе).
19 гыйнвар – «Бабайлар чуагы» (И.Зәйниев).
20 гыйнвар – Шәрык клубында – «Гөлҗамал» (Н.Исәнбәт). Зур залда – «Тормышмы бу?» (Г.Исхакый).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

13 гыйнвар – «Син бит минем бергенәм» (И.Мәхмүтова).
14 гыйнвар – «Назлы кияү» (К.Тинчурин).
15 гыйнвар – «Эх, алмагачлары!» (Ш.Фәрхетдинов).
17 гыйнвар – «Полиционер» (И.Зәйниев).
18 гыйнвар – «Күрәсем килгән иде...» (И.Мәхмүтова).
19 гыйнвар – «Төш» (Т.Миңнуллин).
20 гыйнвар – «Чулпан» (Ш.Хөсәенов).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

13 гыйнвар – «Тимур һәм комета» (П.Коротыч).
15 гыйнвар – «Ромео һәм Джульетта» (У.Шекспир).
18 гыйнвар – «Ләйлә вә Мәҗнүн» (Н.Ганҗәви, Ю.Тупикина инсценировкасы).
19 гыйнвар – «Тапшырыл...ган хатлар» (Г.Кутуй).
20 гыйнвар – «Рөстәм маҗаралары» (Аталы-уллы Гадел һәм Рөстәм Кутуйлар).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

13 гыйнвар – «Ночь перед Рождеством» (Н.Гоголь).
14 гыйнвар – зур залда – «Щелкунчик» (Э.Т.А.Гофман). Кече залда – «Сертотмас үрдәк» (А.Алиш).
15 гыйнвар – Зур залда – «Подарки Деда Мороза» (Н.Абрамцева). Кече залда – «Әлфия» (И.Зәйниев).
17 гыйнвар – «Один день из жизни улитки» (Ольга һәм Юрий Устюговлар).
19 гыйнвар – «Сказка о царе Салтане» (А.Пушкин).
20 гыйнвар – 11.00 – «Сказка о царе Салтане» (А.Пушкин). 19.00 – «Ханума» (А.Цагарели).

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

14 гыйнвар – 14.00 – «Щелкунчик» балеты (П.Чайковский). 18.00 – «Лебединое озеро» балеты (П.Чайковский),
15 гыйнвар – 14.00 – «Спящая красавица» балеты (П.Чайковский), 18.00 – «Щелкунчик» балеты (П.Чайковский).

С.СӘЙДӘШЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ЗУР КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

14 гыйнвар – Композитор Кан Ханьчжонның әсәрләреннән концерт.

Мәңгелек туңлык мәкере

АКШ геология хезмәте Арктика төбәкләрендәге мәңгелек туңлыкка яшерелгән куркынычны ачыклаган. Анда 1656 мең тонна терекөмеш бар икән. Туңлыкта төрле патоген микроорганизмнар да күп, аларның күбесе әле фәнгә бөтенләй мәгълүм түгел. Боулдердагы Кар һәм боз милли үзәге белгече Кевин Шефер фикеренчә, глобаль җылыну шартларында терекөмешнең, боз әсирлегеннән котылып, табигатьне һәм кешелекне агулау куркынычы зур. Тикшеренү барышында геологлар Алясканың төрле районнарыннан боз үрнәкләре бораулап алган, алардагы терекөмеш микъдарын ачыклаган. АКШта, Канадада, Евразия территориясендә башка галимнәр үткәргән тикшеренү нәтиҗәләрен берләштергәч, Төньяк ярымшардагы терекөмеш күләме турында шактый бай мәгълүмат җыелган. Ул анда соңгы бозлык чорыннан бирле тупланган. Мең еллар буе атмосферадагы агулы матдә, туфрактагы органика белән кушылып, мәңгелек туңлыкта утыра барган. Глобаль җылыну нәтиҗәсендә туңлык әкренләп эри: белгечләр әйтүенчә, 100 елдан әлеге катлам кимендә өчтән бергә кимиячәк. Агулы металл океан һәм елгаларга агарга, яңгыр сулары белән туфракка һәм чишмәләргә сеңәргә, зуррак җан ияләре туклана торган микроорганизмнарда тупланырга мөмкин. Моның ачык мисалы – терекөмешле балык. Галимнәр әйтүенчә, кеше организмына балыктагы органик терекөмешнең 80 проценты керә, шунлыктан, мәсәлән, йөкле хатыннарга балыкны күп ашамаска киңәш итәләр. Балыкта тупланган әлеге агулы металлның 75 процентка якыны – аеруча куркыныч метилтерекөмеш кушылмасы, ул бик каты агуларга мөмкин.

(“Die Presse”).

Паста порошокны җиңгән

1892 елда Нью-Лондонда дантист булып эшләүче Вашингтон Шеффилд теш пастасы өчен тюбик уйлап тапкан. Моңа кадәр тешне нигездә кәгазь пакетларга тутырып сатылган порошок белән чистартканнар.1873 елда Нью-Йорк аптекаре Колгейт пыяла банкаларга тутырылган сыек теш пастасы сата башлаган үзе, әмма аңа ихтыяҗ зур булмаган. 40 яшьлек Шеффилд хәтта бераз вакытка табиблек һөнәрен калдырып торган һәм аккургаштан, рәссамнар буяуларын саклый торган көпшәне бераз камилләштереп, куллану өчен күпкә уңайрак булган тюбик ясаган. Тик ул үзенең ачышын рәсми теркәтмәгән, ә Колгейт юридик яктан көчлерәк булган һәм тюбикка тиз арада патент алып куйган, 1896 елдан теш пастасын күпләп җитештерүне җайга салган. Тюбиклардагы сыек паста Америка һәм Европада тиз арада популярлашкан. Бераздан аккургашны алюминийга, аннары исә арзанлы пластикка алыштырганнар. Советлар Берлегендә теш пастасы 1950 елларда гына күренә башлаган, шуңа кадәр гел теш порошогы кулланылган. Хәзер кеше елына 8-10 тюбик паста бетерә. Күп кенә илләрдә паста тюбикларын туплаучылар да бар, аларны туботелист дип йөртәләр. XX гасыр башындагы тюбиклар хәзер бик кыйммәт бәяләнә.

(“Interesnik.com”).

Японча татар теле дәреслеге

Япониядә яшәүче татар кызы, социология фәннәре докторы Мидзуки Сакурама (кыз фамилиясе Накамура) үзенең дусты, татар теле буенча халыкара олимпиада җиңүчесе Юто Хишияма белән бергә японча сөйләшүчеләр өчен дөньяда беренче татар теле дәреслеген язып бастырган. Аның буенча телнең төп лексикасын һәм грамматикасын өйрәнеп була. Кулланмадагы 20 дәрестә 1200 ләп сүз бар. Мидзуки әйтүенчә, ул 2017 елда, Япониядә үз ана телен өйрәнү өчен кирәкле бер генә әсбап та таба алмаганга, дәреслек язарга карар кылган һәм укытучылары белән дусларына шул чакта ук вәгъдә биргән булган. Татар, япон, рус, үзбәк телләрендә сөйләшүче Мидзукиның әбисенең әти-әнисе Япониягә Башкортстанның Илеш районыннан Октябрь инкыйлабыннан соң күченгән.

(“Tatar-inform.ru”).

Аһәңсаз бүләк көтә

Якташыбыз София Гобәйдуллинаның Андрис Нельсонс җитәкчелегендәге Гевандхаус оркестры башкаруында “Der Zorn Gottes” әсәре “Иң яхшы заманча классик композиция” номинациясендә Американың музыка өлкәсендәге иң атаклы “Грэмми” премиясенә тәкъдим ителгән. Әлеге бүләккә төрле елларда Фрэнк Синатра, The Beatles, The Rolling Stones, Стинг, Элвис Пресли, Джон Леннон, Тина Тернер, Джордж Бенсон, Би Би Кинг, Боб Дилан, Уитни Хьюстон һәм Мадонна лаек булган. Музыкаль премияне тапшыру тантанасы 5 февральдә Лос-Анджелеста инде 65 нче тапкыр үткәреләчәк. София Әсгать кызы Гобәйдуллина - йөздән артык симфония, солистлар, хор һәм оркестр, инструменталь ансамбльләр, театр һәм кино өчен музыкаль әсәрләр авторы, бик дәрәҗәле премияләр лауреаты. Ул 1931 елның 24 октябрендә Чистайда туган. Әтисе – татар, инженер-геодезист булып эшләгән, әнисе рус милләтеннән, укытучы булган. Алар төпчек кызларына Сания дип исем кушкан. Кызга 7 ай чагында гаилә Казанга күченгән. Апалары Вера һәм Ида белән Сания бик тату, зыялы гаиләдә үскән, бабалары мулла булган. Казанның Тельман урамындагы Сания балачакта яшәгән йортта хәзер София Гобәйдуллинаның Заманча музыка үзәге урнашкан(София исемен ул 39 яшендә чукындырылганда алган). Беренче ире – шагыйрь Марк Ляндо. 1959 елда туган кызлары Надеждәны, Мәскәүдә тормыш шартлары начар булганга күрә, Казандагы әби-бабасына җибәргәннәр: үлеп сагыну, эш хакына шәхси бәхетеңне корбан итү темасы шул вакыттан бирле композитор музыкасында төп темаларның берсенә әйләнгән. Шактый вакыт бергә яшәгәннән соң, Марк белән аерылышканнар. Икенче ире – пианист һәм музыка галиме Петр Мещанинов белән 1991 елда язылышканнар һәм шул вакытта бөтенләйгә Германиягә күченгәннәр. 2004 елда бердәнбер кызы Надежда лейкемиядән дөнья куйган. Әбиләренең юанычына, аның Илья һәм Александр исемле ике улы, Денис һәм Екатерина исемле оныклары калган. 2006 елда ире дә бакыйлыкка күчкән. София Гобәйдуллина Гамбург янындагы Аппен коммунасында яши һәм һаман да илһамланып иҗат итә.

(“Die Presse”).



Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

16 гыйнвар
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Оныта алмыйм...»
5.50, 7.00, 18.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «ҖЫЛЫ ЭЗЛИ ҖАННАР». 12+
10.00, 23.00 «ОТРЯД». 16+
11.00 «Татар халык җырлары».
11.30 «Заман көзгесе». 6+
12.00, 22.10 «ЮГАЛГАН ХӘТИРӘЛӘР». 12+
13.00 «Семь дней». 12+
14.00 Документальный фильм. 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә».
16.00 «Переведи!» 6+
16.30 «Татарлар». 12+
18.00 «Таяну ноктасы». 16+
19.00 Хоккей. «Ак Барс» - «Адмирал». 6+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.50 «Соотечественники». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

6.00, 13.05 «Манзара». 6+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
8.40, 23.05 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 0.15 «Татар халык җырлары». 6+
12.05, 18.20, 21.25 «КАЙДА СИН?» 12+
15.30, 20.30 «Заман көзгесе». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
19.05, 22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

1.00, 14.35 «Вместе по России». 12+
2.00, 3.00, 7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
8.30, 23.00 «ТРЮКАЧ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ДЕНЬГИ». 12+
11.30 «НА КРЫЛЬЯХ». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.55 «ПРОПАВШИЙ ЖЕНИХ». 12+
15.00 «Земля людей». 12+
15.30 «Война и мир Александра I. Благословенный старец. Кто он?» 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
21.00 «Время».
21.45 «НУЛЕВОЙ ПАЦИЕНТ». 16+
22.35 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «СКЛИФОСОВСКИЙ». 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.20, 10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Невский ковчег. Теория невозможного. Алексей Толстой.
7.35 «Новые люди Переславля и окрестностей».
8.30, 16.35 «РОЖДЕННАЯ РЕВОЛЮЦИЕЙ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10, 23.50 XX век. «Театральные встречи. В гостях у Театра имени Моссовета».
12.20, 22.15 «МИХАЙЛО ЛОМОНОСОВ».
13.35 «Уфа. Особняк Елены Поносовой-Молло».
14.05 Линия жизни. Дмитрий Лысенков.
15.05 Новости. Подробно. АРТ.
15.20 «Восточный экспресс. Поезд, изменивший историю».
16.20 Цвет времени. Анри Матисс.
18.10 Мастера мировой концертной сцены.
19.00 «Константин Станиславский. После «Моей жизни в искусстве».
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 «Оттаявший мир».
21.35 «Сати. Нескучная классика...»

«НТВ»

5.25 «ПЯТЬ МИНУТ ТИШИНЫ». 12+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «БЕЗСОНОВЪ». 16+
22.00, 0.00 «ЧУЖАЯ СТАЯ». 16+

Сишәмбе

17 гыйнвар
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Оныта алмыйм...»
5.50, 7.00, 18.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «ҖЫЛЫ ЭЗЛИ ҖАННАР». 12+
10.00, 23.00 «ОТРЯД». 16+
11.00 «Азбука долголетия». 6+
11.15 «Память сердца». 12+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ЮГАЛГАН ХӘТИРӘЛӘР». 12+
13.00 «Татар халык җырлары».
13.30 «Юлчы». 6+
14.00 «Путь». 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
15.15 «Тәмлә».
16.00 «Ватандашлар». 12+
18.00 «Таяну ноктасы». 16+
19.00 Гала-матч хоккейного турнира «Kazan-Cup». 6+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.50 «Видеоспорт». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.05 «Манзара». 6+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
8.40, 23.05 «Җырлыйк әле!» 6+
9.40 «Татар халык җырлары». 6+
10.30, 20.30 «Халкым минем». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 21.25 «КАЙДА СИН?» 12+
15.30, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
19.05, 22.10 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+

«ЭФИР»

1.30, 14.35 «Вместе по России». 12+
2.00, 3.00, 7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
8.30, 23.00 «ТРЮКАЧ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ДЕНЬГИ». 12+
11.30 «НА КРЫЛЬЯХ». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.55 «ПРОПАВШИЙ ЖЕНИХ». 12+
15.00 «Земля людей». 12+
15.30 «Убийство Романовых. Факты и мифы». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
21.00 «Время».
21.45 «НУЛЕВОЙ ПАЦИЕНТ». 16+
22.40 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «СКЛИФОСОВСКИЙ». 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.20, 10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Купола под водой».
8.25, 16.35 «РОЖДЕННАЯ РЕВОЛЮЦИЕЙ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10, 23.50 «Ты шагай, Спартакиада!»
11.50 «Одинцово. Васильевский замок».
12.20, 22.15 «МИХАЙЛО ЛОМОНОСОВ».
13.35 «Игра в бисер» Виктор Гюго. «Последний день приговоренного к смерти».
14.15 «Алексей Ляпунов. Лицо дворянского происхождения».
15.05 Новости. Подробно. Книги.
15.20 «Эрмитаж».
15.50 «Сати. Нескучная классика...»
18.10 Мастера мировой концертной сцены.
19.00 «Константин Станиславский. После «Моей жизни в искусстве».
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 Искусственный отбор.
21.30 «Белая студия».

«НТВ»

5.20 «ПЯТЬ МИНУТ ТИШИНЫ». 12+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «БЕЗСОНОВЪ». 16+
22.00, 0.00 «ЧУЖАЯ СТАЯ». 16+

Чәршәмбе

18 гыйнвар

Телевизор караучылар игътибарына! Чәршәмбе, 18 гыйнвар көнне, профилактика чаралары үткәрү сәбәпле, «Татарстан - Яңа гасыр» һәм "ТНВ-Планета" телеканалларында 2.00 сәгатьтән 9.00 сәгатькә кадәр тапшырулар трансляцияләнми.

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

9.00, 17.00 «ҖЫЛЫ ЭЗЛИ ҖАННАР». 12+
10.00, 23.30 «ОТРЯД». 16+
11.00, 0.45 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.40 «ЮГАЛГАН ХӘТИРӘЛӘР». 12+
13.00 «Җырлыйк әле!» 6+
14.00 «Если хочешь быть здоровым». 12+
14.15 «Туган авылым». 6+
14.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
14.45 «Оныта алмыйм...»
15.15 «Бергәләп өйрәник».
16.00 «Переведи!» 6+
18.00 «Таяну ноктасы». 16+
18.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
19.00 Хоккей. «Ак Барс» - «Салават Юлаев». 6+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «Спортивная среда». 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

9.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
9.40, 23.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
10.40 «Туган авылым». 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 21.25 «КАЙДА СИН?» 12+
13.05 «СӨЮ КӨТӘ ЙӨРӘК». 12+
15.30, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
19.05 «Әйдә, дустым, уйнат гармуныңны». Фән Вәлиәхмәтов концерты. 6+
20.30 «Юлчы». 6+
22.05 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+

«ЭФИР»

1.30, 14.35 «Вместе по России». 12+
2.00, 3.00, 7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
8.30 «ТРЮКАЧ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «ДЕНЬГИ». 12+
11.30 «НА КРЫЛЬЯХ». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «КЛЮЧИ». 12+
15.00 «Земля людей». 12+
15.30 «Блокада снится ночами». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
20.00 «МОСКОВСКАЯ БОРЗАЯ. ПРОДОЛЖЕНИЕ». 16+
23.00 «АКВАТОРИЯ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
21.00 «Время».
21.45 «НУЛЕВОЙ ПАЦИЕНТ». 16+
22.40 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «СКЛИФОСОВСКИЙ». 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
10.15 «Наблюдатель».
11.10, 23.50 XX век. «Все песни в гости... Поёт и рассказывает Людмила Зыкина».
11.50 «Крым. Мыс Плака».
12.20, 22.15 «МИХАЙЛО ЛОМОНОСОВ».
13.35 Искусственный отбор.
14.20 «Борис Раушенбах. Логическое и непостижимое».
15.05 Новости. Подробно. Кино.
15.20 «Библейский сюжет».
15.50 «Белая студия».
16.35 «РОЖДЕННАЯ РЕВОЛЮЦИЕЙ».
18.00 Мастера мировой концертной сцены.
19.00 «Константин Станиславский. После «Моей жизни в искусстве».
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 Абсолютный слух.
21.30 Власть факта. «Иезуиты: слово и дело».

«НТВ»

5.25 «ПЯТЬ МИНУТ ТИШИНЫ». 12+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «БЕЗСОНОВЪ». 16+
22.00, 0.00 «ЧУЖАЯ СТАЯ». 16+

Пәнҗешәмбе

19 гыйнвар
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «ҖЫЛЫ ЭЗЛИ ҖАННАР». 12+
10.00, 23.00 «ОТРЯД». 16+
11.00, 0.40 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ЮГАЛГАН ХӘТИРӘЛӘР». 12+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Туган авылым». 6+
14.15 «Рыцари вечности». 12+
14.45 «Оныта алмыйм...»
15.15 «Шома бас» һәм «Алты хәреф».
16.00 «Казаннан - казанга». 12+
18.00 «Юлчы». 6+
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
21.00 «Ватандашлар». 12+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.50 «Видеоспорт». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.05 «Манзара». 6+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
8.40, 23.05 «Кәмит Җәвит». 16+
9.40 «Кунак БИТ Шоу». 12+
10.40 «Туган авылым». 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 21.25 «КАЙДА СИН?» 12+
15.30 «Таяну ноктасы». 16+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
19.05, 22.05 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Әниемнең җылы кочагы». 6+

«ЭФИР»

1.20, 14.35 «Вместе по России». 12+
2.00, 3.00, 7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
8.30, 23.00 «АКВАТОРИЯ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «МОСКОВСКАЯ БОРЗАЯ. ПРОДОЛЖЕНИЕ». 16+
11.30 «НА КРЫЛЬЯХ». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «КЛЮЧИ». 12+
15.00 «Земля людей». 12+
15.30 «Моя блокада». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
21.00 «Время».
21.45 «НУЛЕВОЙ ПАЦИЕНТ». 16+
22.40 «Большая игра». 16+
0.00 «КРАТКИЙ КУРС СЧАСТЛИВОЙ ЖИЗНИ». 18+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «СКЛИФОСОВСКИЙ». 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 8.20, 10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
6.35 Лето Господне.
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Оттаявший мир».
8.25 Цвет времени. Уильям Тёрнер.
8.35, 16.30 «РОЖДЕННАЯ РЕВОЛЮЦИЕЙ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10, 23.50 XX век. «Встреча в Концертной студии «Останкино». Ваш собеседник писатель Александр Панченко».
12.10 Цвет времени. Жан Этьен Лиотар. «Прекрасная шоколадница».
12.20, 22.15 «МИХАЙЛО ЛОМОНОСОВ».
13.30 Абсолютный слух.
14.15 «Леонид Канторович».
15.05 Новости. Подробно. Театр.
15.20 Моя любовь - Россия! «Вкус осетинских пирогов».
15.45 «2 Верник 2».
18.10 Мастера мировой концертной сцены.
19.00 «Константин Станиславский. После «Моей жизни в искусстве».
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 «Дело Деточкина».
21.30 «Энигма. Ильдар Абдразаков».
23.20 Цвет времени. Василий Поленов. «Московский дворик».

«НТВ»
5.25 «ПЯТЬ МИНУТ ТИШИНЫ. ВОЗВРАЩЕНИЕ». 12+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «БЕЗСОНОВЪ». 16+
22.00, 0.00 «ЧУЖАЯ СТАЯ». 16+

Җомга

20 гыйнвар
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35, 14.45 «Оныта алмыйм...»
5.50, 7.00, 18.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «ҖЫЛЫ ЭЗЛИ ҖАННАР». 12+
10.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
11.00 «Нәсыйхәт». 6+
11.30 «Татарлар». 12+
12.00 «Ком сәгате». 12+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 6+
14.15 «Здоровая семья: мама, папа и я». 6+
15.15 «Тизрәк! Алга! Җитезрәк!» һәм «Алты хәреф».
16.00 «Звёзды из Завтра-2022». 6+
16.30 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Татар халык җырлары».
19.00 Хоккей. «Ак Барс» - «Авангард». 6+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «КВН РТ-2023». 12+
23.10 «ПОСЛЕДНЯЯ РОЛЬ РИТЫ». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
4.15 «Кәмит Җәвит». 16+
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.05 «Манзара». 6+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
8.40, 23.05 «Ком сәгате». 12+
9.40, 15.30, 0.15 «Нәсыйхәт». 6+
10.30 «Казаннан казанга». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 21.25 «КАЙДА СИН?» 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30, 0.40 «Калеб». 6+
19.15 Концерт. 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.30 «Заман көзгесе». 6+
21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+

«ЭФИР»
1.20 «Вместе по России». 12+
2.00, 3.00, 7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
8.30, 23.00 «АКВАТОРИЯ». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «МОСКОВСКАЯ БОРЗАЯ. ПРОДОЛЖЕНИЕ». 16+
11.30 «НА КРЫЛЬЯХ». 12+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.45 «ПОМЕНЯТЬСЯ МЕСТАМИ». 16+
15.00 «Земля людей». 12+
15.30 «Блокада. День 901-й». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.30 «Fam TV». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.45 «Голос. Дети».
23.15 «ZОЛУШКА». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.15 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.30 «ЭКИПАЖ». 6+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 8.15, 10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Верея. Возвращение к себе».
8.20 «РОЖДЕННАЯ РЕВОЛЮЦИЕЙ».
10.20 «ЛЮБИМАЯ ДЕВУШКА».
11.50 «Шаг в вечность».
12.20, 22.15 «МИХАЙЛО ЛОМОНОСОВ».
13.35 Власть факта. «Иезуиты: слово и дело».
14.15 «Илья Мечников».
15.05 Письма из провинции.
15.35 «Энигма. Ильдар Абдразаков».
16.15 «Шри-Ланка. Маунт Лавиния».
16.50 «Царская ложа».
17.30 Мастера мировой концертной сцены.
19.00 «Константин Станиславский. После «Моей жизни в искусстве».
19.45 Линия жизни. Анатолий Сагалевич.
20.40 Искатели. «Талисман Мессинга».
21.25 «2 Верник 2».
23.50 «БУМАЖНАЯ ЛУНА».

«НТВ»
5.20 «ПЯТЬ МИНУТ ТИШИНЫ. ВОЗВРАЩЕНИЕ». 12+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим». 6+
9.25, 10.35 «Следствие вели...» 16+
11.00 «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «ДНК». 16+
17.55 «Жди меня». 12+
20.00 «БЕЗСОНОВЪ». 16+
22.00 «ЧУЖАЯ СТАЯ». 16+
23.55 «Своя правда». 16+

Шимбә

21 гыйнвар
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...»
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
7.00 «Sиңа Миннән Sәлам». 6+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00 «Туган авылым». 6+
11.30 «Казаннан - казанга». 12+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 12+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
13.30 Спектакль «Бәби». 12+
15.15 «Тыңла әле мине...» Марат Мухин хитлары. 6+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Tatarstan today. Открытый миру». 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
22.00 «КунакБит- шоу». 12+
23.00 «КТО ЕСТЬ КТО?» 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00 «Йөрәктән-йөрәккә». Нәҗип Җиһанов турында телесчерк. 6+
7.00, 15.00 «Sиңа Миннән Sәлам». 6+
9.00 «Кәмит Җәвит». 16+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 6+
13.00 «Туган авылым». 6+
13.20 Спектакль «Бәби». 12+
17.10 «Казаннан казанга». 12+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Гомер чишмәм». Рәсим Низамов концерты. 6+
23.00 «Йөзек кашы». 12+

«ЭФИР»
5.00, 0.45 «Вместе по России». 12+
5.30 «Репортажи из будущего». 12+
6.15 «Загадки цивилизации. Русская версия». 12+
7.00 «Белка и Стрелка. Тайны космоса».
8.00 «Первые в мире». 12+
8.15 «ЖИЗНЕННЫЕ ОБСТОЯТЕЛЬСТВА». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «УГОНЯЯ ЛОШАДЕЙ». 16+
15.15 «АННА. ЖЕНА ЕГЕРЯ». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «НОВАЯ ЖИЗНЬ АМАНДЫ». 16+
23.00 «ИНДИЙСКОЕ ЛЕТО». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.00 «Умницы и умники». 12+
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 18.00 Новости.
10.15 «ПроУют».
11.10 «Поехали!» 12+
12.15 К 80-летию прорыва блокады Ленинграда. «Ладога. Нити жизни». 12+
13.15 «ЛАДОГА». 16+
17.10 «Угадай мелодию». 12+
18.20 «Горячий лед». Фигурное катание.
21.00 «Время».
21.35 «Сегодня вечером». 16+
23.15 «ТРОЕ». 16+

«РОССИЯ»
5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.40 «Доктор Мясников». 12+
12.45 «ТЕОРЕМА ПИФАГОРА». 16+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «МЕСТО СИЛЫ». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Библейский сюжет».
7.05 Мультфильмы.
8.30 «ПУТЕШЕСТВИЕ МИССИС ШЕЛТОН».
10.05 «Передвижники. Николай Ге».
10.40 «ОПАСНЫЕ ГАСТРОЛИ».
12.05 «Эрмитаж».
12.35 Человеческий фактор. «Сельские подмостки».
13.05 Черные дыры. Белые пятна.
13.45 «Эффект бабочки».
14.15 «Эйнштейны от природы».
15.10 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
16.00 «Твербуль, или Пушкинская верста».
16.40 «ИСПЫТАТЕЛЬНЫЙ СРОК».
18.15 «Музей Прадо. Коллекция чудес».
19.50 «ПОСЛЕДНЕЕ МЕТРО».
22.00 «Агора».
23.00 «СЕМЕЙНЫЕ ЦЕННОСТИ АДДАМСОВ».

«НТВ»
4.50 «СТАЖЁРЫ». 16+
7.25 «Смотр».
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «Поедем, поедим!»
9.20 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.00 Научное расследование Сергея Малозёмова. 12+
15.00 «Своя игра».
16.20 «ЧП. Расследование». 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
19.00 «Центральное телевидение».
20.20 «Ты не поверишь!» 16+
21.20 «Секрет на миллион. «ДНК Анны Казючиц». 16+
23.25 «Международная пилорама». 16+

Якшәмбе

22 гыйнвар
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...»
6.00 «Болгар радиосы» бәйрәм концерты. 6+
8.00 «Адымнар». 12+
8.30 Мультфильмы. 6+
8.45 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы». 12+
10.15 «Ачыктан - ачык». 12+
11.00 «Туган авылым». 6+
11.20 «Синең өчен». Зәйнәб Фәрхетдинова. 6+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество». 12+
13.00 «Әйләнә дөнья». Ришат Фазлыйәхмәтов концерты. 6+
15.00 «Әниемнең җылы кочагы». 6+
16.00 «Ком сәгате». 12+
17.00 «Видеоспорт». 12+
17.30 «Соотечественники». 12+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». 12+
20.00 «Заман көзгесе». 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты. 6+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
23.00 «ЭБИГЕЙЛ». 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30 «Нәсыйхәт». 6+
6.00 «Заман көзгесе». 6+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
7.00 «Адымнар». 12+
7.30 «Узып барышлый». Гөлнара Сабирова җырларыннан концерт. 6+
9.30, 15.30 «Йөрәктән-йөрәккә». 6+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.45 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05, 0.40 «Яшьләр тукталышы». 12+
13.00 «Туган авылым». 6+
13.20 «Яшәү- мизгел». Нәфкать Нигъмәтуллин концерты. 6+
16.20, 21.10 «Әниемнең җылы кочагы». 6+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05 «Ком сәгате». 12+
20.00 «Семь дней». 12+
22.00 «Риваять» этно төркеменең юбилей кичәсе. 6+

«ЭФИР»
5.00 «Вместе по России». 12+
5.30 «Репортажи из будущего». 12+
6.15 «Загадки цивилизации. Русская версия». 12+
7.00 «Белка и Стрелка. Тайны космоса».
8.00, 15.00 «Первые в мире». 12+
8.15 «АННА. ЖЕНА ЕГЕРЯ». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «НОВАЯ ЖИЗНЬ АМАНДЫ». 16+
15.15 «ЖИЗНЕННЫЕ ОБСТОЯТЕЛЬСТВА». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «УГОНЯЯ ЛОШАДЕЙ». 16+
23.15 «СТАЛЬНАЯ БАБОЧКА». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.10, 6.10 «ГУСАРСКАЯ БАЛЛАДА». 12+
6.00, 10.00, 12.00, 18.00 Новости.
6.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.40 «Часовой». 12+
8.15 «Здоровье». 16+
9.20 «Мечталлион». 12+
9.40 «Непутевые заметки». 12+
10.15 «Жизнь своих». 12+
11.10 «Повара на колесах». 12+
12.15 «Видели видео?»
14.00 «БРОНЕНОСЕЦ «ПОТЕМКИН». 12+
15.45 Александр Ширвиндт. «Две бесконечности». 16+
17.00, 19.00 «Горячий лед». Фигурное катание.
21.00 «Время».
22.35 «КОНТЕЙНЕР». 16+
23.35 Подкаст.лаб. 16+

«РОССИЯ»
6.15 «ЖЕНА ПО СОВМЕСТИТЕЛЬСТВУ». 16+
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00 Вести.
11.40 «Большие перемены».
12.45 «ТЕОРЕМА ПИФАГОРА». 16+
18.00 «Песни от всей души». 12+
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Твербуль, или Пушкинская верста».
7.20 Мультфильмы.
8.35 «ИСПЫТАТЕЛЬНЫЙ СРОК».
10.10 Тайны старого чердака. «Что из этого получилось?»
10.40 Звезды русского авангарда. «Сергей Михайлович Эйзенштейн - архитектор кино».
11.05 «АЛЕКСАНДР НЕВСКИЙ».
12.55 Невский ковчег. Теория невозможного. Корнелиус Крюйс.
13.25 «Игра в бисер» «Поэзия Владимира Высоцкого».
14.05 «Эйнштейны от природы».
15.00 «ПОХИТИТЕЛЬ БАЙКОВ».
16.30 Больше, чем любовь.
17.15 «Пешком...»
17.45 «Замуж за монстра. История мадам Поннари».
18.35 «Романтика романса».
19.30 Новости культуры.
20.10 «ОПАСНЫЕ ГАСТРОЛИ».
21.40 Закрытие I Международного конкурса вокалистов и концертмейстеров Хиблы Герзмава.
23.10 «ДЕТЕКТИВНАЯ ИСТОРИЯ».

«НТВ»
4.50 «СТАЖЁРЫ». 16+
6.30 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
11.55 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.05 «Однажды...» 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации». 16+
19.00 Итоги недели.
20.20 «Звезды сошлись». 16+
21.50 «Основано на реальных событиях». «Шура показывает зубы». 16+

БАБАЙ ЗЫЯНЫ

Мөслим районындагы Б. авылының иң өлкән кешеләреннән булган Зөфәр һәм Нәфисә инде (кайбер исем-фамилияләр үзгәртелде) 59 ел бергә гомер кичерәләр. Заманында хуҗабикә фермада сыер савучы, ир-ат шофер, күбрәк, сөт ташу машинасын йөртүче булып эшләгән. Хәзер инде өлкән яшьләрдә булган өч уллары, бер кызлары бар. Чит төбәкләрдә яшәүче балалары Мөслим районындагы төп нигезне онытмыйлар. 85 яшендәге карт 3 нче төркем инвалид булганга, алар янына социаль хезмәткәр Флүзә дә килеп йөри, соңгы вакытта рәсми эшеннән чыкканга күрә, үзара килешү буенча гына ярдәм итә ул.

26-28 август көннәрендә картларның йорты гөрләп тора. Әлмәт районыннан ире, малае белән кызлары Гөлнара, Чаллыдан уллары Илсур белән Илнар кайта, бар да хуҗалык эшләре белән кайнаша, ирләр, мәсәлән, газ казаны урнаштыру белән мәшгуль була. Кунаклар берәмләп таралыша, 28 август кичендә соңгысы Илсур китеп бара, өйдә тыныч, картлар исән-сау була.

Ул көнне төштән соң аларга Флүзә дә кереп чыга, Нәфисә карчык белән кухня стенасына обой ябыштыру турында сөйләшәләр. Ике-өч көн узгач, аңа шушы очрашуыбыз соңгысы булды, дип рәсми күрсәтмә бирергә туры килә. Чөнки исән-сау килеш йөреп торган 80 яшьлек карчык юкка чыга.

29 августта Галләмовлар йортына керүче-чыгучы булмаганга охшый. Ә икенче көнне Флүзә килә, гадәттә, төнгә каршы гына бикләнә торган ябык капкага юлыга, өй телефоны алучы да булмый, шактый гына шакыганнан соң, күрәсең, ишегалдындагы этләр өрүен ишетеп, аны Зөфәр карт каршы ала. Бабай аңа хәләл җефетенең өйдә кунмавын, каядыр китүен әйтә. Өйдә шикләнердәй сәбәп күренми, бар да тәртиптә була, бары тик ханымны Нәфисә карчык каравытындагы урын-җирнең җыелмаган булуы гына сәерсендерә. Шулай да тынычланмый ул. Кичкә таба өй телефонына туктаусыз шалтырата, берсендә хуҗаның: «Өйдә юк», – дип әйтүеннән башка мәгълүмат ала алмый. Шуннан соң кызлары Гөлнара, уллары Илсурга да хәбәр итә. Шөбһәгә төшкән Гөлнара ире белән авылга килә, аталары эндәшмичә өйдә утыра, алар караңгыда фонарьлар яндырып бакчаларны урап, мунча һәм башка корылмаларны карап чыгалар. Бары тик сарайга кермиләр... Иртүк эшкә барасылары булганга, Түбән Мактамага кайтып китәләр.

Җәйнең соңгы көне иртәсендә бу хакта хәбәр алгач та, Илсур Чаллыдан Мөслимгә таба чыгып китә. Сарман тирәсендә чакта аңа тагын Флүзә шалтырата, кайчан килеп җитәчәген белешә, әмма аяныч хәбәрне җиткерергә ашыкмый. Илсур юл уңаенда әнисенең үле гәүдәсе сарайда табылуы турында башкалардан ишетә. Ул кайтып туктаганда, полиция дә килеп җитмәгән була, фаҗигале өй тирәсендә берничә кеше, башлыча, хатын-кызлар гына тора.

...Авылда ыгы-зыгы 31 август иртәсендә Зөфәр картның күршесе Саҗидә янына килүеннән башланып китә. Иң әүвәл хатынының өйдә булмавы, аерылышырга йөрүе, аннан соң полициядән килеп алып китүдән куркуы турында сөйләнә ул. Курше ханым ошбу сөйләшүнең кыскача эчтәлеген авыл җирлеге башлыгы И.Гыйльфановага җиткерә. Илгизә шул ук Флүзәгә шалтыратып белешергә керешә, әлеге вакыйга белән таныш социаль хезмәткәр аның янына килеп җитә.

Ике хатын-кыз З.Галләмовны Саҗидә ханым белән күршесе капка төбендә очраталар. Өч хатын-кыз шунда ук эзләргә тотына, өйләренә дә кереп чыккач, ишегалдындагы бабайның: «Сарайда сыер үләксәләре, мәетләр бар», – дигәне колакка чалына, Илгизә белән Саҗидә аның ишеген ача һәм сул якта тартмалар, такта кисәкләре астындагы зур полиэтилен капчыкны күрәләр, аның эчендә кеше гәүдәсе булуын шәйләп тетрәнеп китәләр. Замана хатыннары сарай эченә үзләре дә керми, тиз арада килеп туктаган Илсурны да кертмиләр, полицияне көтәләр.

Оператив-тикшерү төркеме кухнядагы раковина тартмасында, йокы бүлмәсе бусагасында, зал идәненә һәм башка урыннарда кан таплары күрә, кан эзләре булган чүкеч тә игътибардан читтә калмый, бабайның киемнәрен дә салдырып алалар, чөнки алар да канга буялган була.

Суд-медицина экспертизасы 1942 елгы әбинең асфиксия, ягъни һава (кислород) җитмәүдән, буылудан берничә минут эчендә үлүен күрсәтә. Эксперт моны кул белән яисә җеп кебек әйберләр кулланып буу түгел, ә бәлки авыр, тупас корал белән муенга нибары бер мәртәбә сугып андагы күп кенә әгъзалар, кан тамыры, сулыш юлына зарар килү нәтиҗәсе дип аңлата. Шунысын да искәртик, әбинең исән-сау калу мөмкинлеге бөтенләй булмый, аның башына 9 тапкыр сугу аркасында үлемгә китерерлек авыр җәрәхәтләр ясалган була. Аннан кала, гәүдәнең башка өлешләрендә тагын 7 бәрелгән урын куренеп тора.

Фаҗига балаларын, туганнарын гына түгел, бөтен авыл халкын тетрәндерә. Барысы да гаиләне уңай бәяли, картлар сабыр холыклы, тәртипле иде, диләр. Гаиләдә булгач, низагсыз гына булмыйдыр, якыннан аралашучылар аларның да вак-төяк мәсьәләләр аркасында әрләшүләрен, ул гына да түгел, 80-85 яшьләрендәге кешеләрнең бәйрәмнәрдә бер-ике чәркә тотып куюын да әйтәләр. Соңгысы өлкәннәр өчен сәер булса да, эчкечеләр дигән сүз түгел бу. Хәлсез картның кимендә 17 тапкыр сугып карчыгын һәлак итүенә ышанырлык та түгел кебек. Ләкин тикшерү барышында күрсәтмә бирүчеләрнең берсе дә моның Зөфәр карт эше икәненә шикләнми. Кызы Гөлнара, мәсәлән, эти беркайчан да усал, явыз булмады дип, моны карт булганга күрә акылы тайпылу нәтиҗәсе дип фаразлый. Йорт эшләрендә булыша алмаган өчен, Нәфисә карчык туктаусыз тиргәп, кимсетеп торганга, бабайның түземлеге «шартлаган» дип кискенрәк сөйләүче дә бар.

Вакыйга урынында тикшерү чаралары барганда, Зөфәр Галләмов өендә утыра. Полиция хезмәткәрләренә киемендәге кан тапларының каян килүен аңлатып бирә алмый. Мөслим полициясенә алып баргач, кызы алдында тикшерү комитетының Минзәлә районара бүлегеннән Данияр Мөхәммәдиевка шул көнне үк шактый тулы татарча күрсәтмә бирә. Сөйләвенә караганда, 29 август кичендә ике чәркә аракы эчә, хак булса, хәләл җефете дә берне каплап куя. Соңгысын шик астына алырга сәбәп бар, чөнки химик экспертиза мәрхүмә канында этил спирты табылмады дип белдерә. Карт үзара ызгыш купкач, кухнядагы чүкечне алып муенына бер тапкыр суктым да, йокларга кереп киттем, иртүк торгач аның җансыз икәнен күрдем, сарайга өстерәп алып кереп капчыкка салдым да өстенә тартмалар ыргыттым, өйдәге кан эзләрен сөртеп чыктым ди. Куркытыр өчен генә сугуын да, ярдәм күрсәтмәвен дә әйтә ул, низаг чыгу сәбәбен хәтерләми, ләкин соңгы вакытта миңа гел кычкырды, аңа бернәрсә дә ошамый иде, мине яратмый башлады дип сөйли.

Бабай зиһенендәге кимчелекләрне тикшерүче дә сизми калмый, ләкин кеше үтерү очрагы буенча җинаять эше кузгатыла, картлыкка ташлама ясамый торган законнар нигезендә гаепләнүче сак астына ябыла. Әлбәттә ки, психиатрик экспертиза билгеләнә, аның нәтиҗәләре исә октябрь ае азагында гына, ягъни 85 яшьлек кеше ике айга якын тикшерү изоляторында утыргач кына мәгълүм була һәм ул Казандагы Бехтерев исемендәге психиатрия сырхауханәсенә күчерелә. Аңлашыла ки, З.Галләмов рухи актан авыру булганга, үз гамәлләрен аңларлык түгел дип табыла. Ошбу тайпылышларның төп сәбәбе баш миендәге кан тамырлары чире һәм, күрәсең, үзенең ике чәркә аракы эчүен исәпкә алып, алкогольгә бәйлелек күрсәтелә, ул әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч тудыручы зат, шуңа күрә мәҗбүри дәвалануга мохтаҗ дип белдерелә. Бу инде, Мөслим район суды карары белән, З.Галләмов колониягә утыртылмый, сырхауханәгә яткырыла дигән сүз.

Наил ВАХИТОВ.

Бер елда 82 китап

2022 елда Татарстан Диния нәзарәтенең «Хозур» нәшрияты 160 меңнән артык гомуми тираж белән 82 исемдәге китап бастырды.

Нәшрият эшчәнлеге Диния нәзарәтенең традицион ислам кыйммәтләрен пропагандалау өлкәсендәге эшчәнлегенең өстенлекле юнәлешләреннән берсе булып тора. 2022 елда мөселманнар арасында дини гыйлем тарату, милли мәдәниятне, гореф-гадәтләрне һәм өммәтнең интеллектуаль мөмкинлекләрен үстерүнең мөһим бер юлы буларак укуга кызыксынуны арттыру максатыннан, нәшрият тарафыннан 82 төрле китап, шул исәптән, татар дини мирасына караган 18 басма дөнья күрде. Аларның гомуми тиражы 160 500 данә тәшкил итә.

Шунысы игътибарга лаек, аларның яртысыннан артыгы – яңадан нәшер ителгән күренекле әсәрләр, алар мөселманнар арасында үз популярлыгын югалтмыйча, укучылар өчен һаман кызыклы булып кала бирә. Мондый китапларга «Зубдату-ль-Бухари», «Клад для маленьких мусульман», рус һәм татар телләрендә «Намаз уку тәртибе» һәм «Гыйбадәт Исламия», «Девяносто девять вопросов о Рае», «Семьдесят пять вопросов об Аде», «Ислам дине нигезләре» һәм башкаларны кертергә мөмкин.

Шул ук вакытта 2022 елда «Хозур» нәшрият йорты уникаль басмалар да нәшер итте. Алар арасында татар дини мирасына караган хезмәтләрнең тәрҗемәләре (шул исәптә Муса Бигиев, Мөхәммәд-Закир Чистави һ.б.), шулай ук хәзерге заман авторларның китаплары (мисал өчен, Рөстәм хәзрәт Хәйруллинның «Уроки семьи», «Основы Ислама: руководство для начинающих», «Побуждение к скорейшему занятию борьбой») да бар. Укучыларның аерым кызыксынуын татар һәм классик ислам дини мирасына караган хезмәтләрнең репринт басмалары җәлеп итте, алар арасында – Коръәннең 1803 елда чыккан «Казан басмасы» китабы, бөек татар галиме Шәйхелислам Хәмидинең «Мәкаләт әл-Бүләга» ике томлыгы һ.б.

«Хозур» нәшрият йорты китапларының кәгазь вариантын гына түгел, электрон версиясен дә сатып алырга мөмкин.

Моннан тыш, 2021 елдан бирле «Хозур» нәшрият йорты китапларын илнең зур сәүдә онлайн-мәйданчыкларында сатып алырга да мөмкинлек туды. «Хозур» нәшриятында дөнья күргән мөселман әдәбияты маркетплейсларда да, шулай китап интернет-кибетләрендә дә сатыла.

«Хозур» нәшрият йортында 9 ел эчендә гарәп, рус, татар һәм иске татар телләрендә җәмгысы 860 мең данәдән артык дини, тарихи, фәнни әдәбият дөнья күрде. Һәр басма Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Эксперт советы тарафыннан мәҗбүри тикшерү аша узган.

Эльмира СИРАҖИ.

Тукай геройларының мәңгелек көче

Казан дәүләт рус яшь тамашачысы театрында олуг шагыйребез Габдулла Тукай әсәрләре буенча гадәти булмаган спектакль куелды. Башта театрга килгән тамашачы бер декорациясез шәп-шәрә сәхнә күреп бераз каефсезләнде. Балаларга Яңа ел бүләге шушы шыксыз сәхнәме, дип үзара сөйләшеп тә алдылар. Ут сүнгәч исә, барысы да тын калды, чөнки Казанда мондый тамаша куйганнары юк иде әле.

Сәхнә бизәлешләре тоташ видеопроекция ярдәмендә иҗат ителгән. Гүя экраннан матур мультфильм карап утырасың, актерлар исә – шул мультфильмның геройлары. «Книга силы» («Китап көче») спектаклен кую бер дә җиңел булмаган, чөнки актерларны сәхнәдәге рәсемнәргә яраклашып кыймылдарга, биергә, йөгерергә һәм башкача хәрәкәтләнергә өйрәтү шактый вакытны алган. Өстәвенә, тамаша мюзикл жанрында иҗат ителгән. Рольләрдә исә – гап-гади драма артистлары. Шулай да «Китап көче» спектакле карап туйгысыз матур, килешле, замана баласының игътибарын җәлеп итәрлек үзенчәлекле килеп чыккан.

Тамаша өчен пьесаны һәм җыр сүзләрен олуг Тукаебызның «Мияубикә», «Сөткә төшкән тычкан», «Шүрәле», «Су анасы», «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» әсәрләрен берләштереп, драматург Андрей Лысяков иҗат иткән. А.Лысяков Казанда Президент чыршысының сценарием язган шәхес буларак та билгеле. «Китап көче» – иҗатында дүртенче мюзикл. Видеобизәлешләрне Альберт Мәхмүтов һәм «Взмах» студиясе, музыканы Тимур Вәлиев иҗат иткән. Режиссеры – Диана Сафәрова.

Фойеда Тукайның төрле елларда нәшер ителгән китаплары, әсәрләренең кульязмалары, фотосурәтләреннән эчтәлекле экспозиция тәкъдим ителгән. Быел «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасының язылуына 115 ел тула. Шагыйрь табадан төшкән яңа әсәрен беренчеләрдән булып нәкъ менә Купеческое собрание залында, хәзерге Островский урамындагы Яшь тамашачы театры бинасында укыган. Анда катнашкан Ф.Әмирханның түбәндәге сүзләре тарихка кереп калган: «Тукаев бу әсәрен ислахчыларның соңгы әдәбият кичәләрендә укыганда, халык, җөмлә тәмам

булганын да көтә алмыйча, сами ми бер көлкегә тотылып, бөтен залны тутырып кул чабалар һәм, укучыны бүлеп, әллә никадәр вакытлар туктап торырга мәҗбүр итәләр иде. Вакыйган да, бу әсәр татар әдәбиятында шигырь белән язылган көлкеләрнең иң мөкәммәл вә максудына иң муафикъ чыккаНЫДЫр. Тукаев монда Печән базары мәгыйшәтенең иң садә вә иң горфи генә эшләрен дә шулкадәр көлкеле итеп тасвир итә ки, укучы ихтыярын кулыннан җибәрә», – дип язган ул «Әл-Ислах»тагы рецензиясендә. Сирәк фотоларны, кульязмаларны берләштереп, күргәзмәне театр бинасыннан каршыда гына урнашкан Татар китабы йорты хезмәткәрләре оештырган.

Хәзер исә йөз дә фәлән ел элек булган вакыйгалар кабатланып, тамашачы «Кисекбаш» геройлары белән бергә көлә, күңел ача.

Яшерен-батырын түгел, музыкада, хореограф Мария һәм Марсель Нуриевләр куйган биюләрдә, Наилә Рәхмәтуллина иҗат иткән костюмнарда миллилек чамалы. Шулай да, спектакль – Шүрәле, Су анасы, Мияубикә, Кисекбаш, Кәҗә белән Сарык һ.б. образлар аша Тукай иҗаты белән танышырга бер мөмкинлек. Сәхнәдә мультфильм итеп эшләнгән үткән гасыр башы Казан күренешләре, андагы трамвайлар, сәүдәгәрләр «Гариф Бәхтиев», «Ефим Смоленцев» йортларын билгеләгән язма такталар, Кабан күле күренеше, Иске Татар бистәсендәге һөнәрчеләрне күрү нәни тамашачыларның әти-әниләренә дә кызык. Калфак, түбәтәй кигән геройларның аратирә «Коза апа», «Баран абый» дип эндәшүләреннән дә күңелгә җылы кереп китә.

Спектакльдә тамырлар мәсьәләсе күтәрелүе йөрәккә сары май булып ятты. Тамырларны барлау һәммә кешегә лязем, дигән фикер яңгырады. Баш герой малайга бөтен каршылыкларны җиңәргә үз-үзенә ышану хисе һәм тамырлардан килгән көч ярдәм итә.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Мәдәни җомга

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кульязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк,
г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2

E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта: www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга. Бу санның чыгу көне 13.01.2023

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2550 данә

Заказ 2600

16+